ТАБЫН ХАКЫ

Бәйрәмгә акчаны кызганмаска гадәтләнгән халык быел ни эшләр?

> 7

ӨЙДӘ КӨТӘЛӘР!

«ВТ» журналисты сөйгәннәрен махсус операциягә озаткан ханымнар белән сөйләште

> 17

КИТАП СҮЗЕ

Ландыш Әбүдәрова белән язучы һәм укучы мөнәсәбәте турында әңгәмә

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 174 (28947) | Җомга | 25 ноябрь | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

vk.com

НӘРСӘ БУЛДЫ СИҢА, КҮҢЕЛ?

ЯҢА ЕЛНЫ КӨТКӘНДӘ

Адәм баласының югалтканны сагына торган гадәте бар. Безнең дә бүген гомер буе озата барыр төсле тоелган күңел һәм җан тынычлыгыбызны юксынып яшәгән көннәребез. Яңа елга да үзгә кәеф белән керәбез быел. Арабызда хәтта купшы чыршы, салют, җыр-биюле тамаша кебек традицион бәйрәм чараларыннан баш тартырга әзер булучылар да бар. Икенче берәүләр исә Яңа елны, балалар хакына булса да, элеккечә үк каршылау яклы. Ил-көнгә сынау килгән чорда бәйрәм итү урынлымы-юкмы? «ВТ» хәбәрчесе, шушы сорауга җавап эзләп, бәйрәм кәефенең ни дәрәҗәдә булуын ачыкларга тырышты.

> 6

Ишетми калмагыз

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов «2023 елга һәм пландагы 2024–2025 елларга республика бюджеты турында»гы Законга кул куйды. Документны Дәүләт Советы 18 ноябрьдә кабул итте. Закон нигезендә, 2023 елга бюджет кереме – 343,9 миллиард сум, чыгымы 371 миллиард сум күләмендә фаразлана. Бюджет дефициты – 27,1 миллиард сум. 2024 елга бюджет кереме – 367,4 миллиард сум, чыгымы – 394,6 миллиард сум, дефицит 27,2 миллиард сум күләмендә булыр дип көтелә. 2025 елга бюджет кереме – 366,9 миллиард сум, чыгымы – 394,3 миллиард сум, дефицит 27,3 миллиард сум күләмендә күздә тотылган.
Шул ук вакытта Дәүләт Думасы 2023 елга һәм пландагы 2024–2025 елларга федераль бюджет турында закон кабул иткән. 2023 елга Россия бюджеты кереме – 26,13 триллион сум, чыгымы 29,056 триллион сум күләмендә расланган. 2024 елда бюджет кереме – 27,24 триллион сум, 2025 елда – 27,98 триллион сум. Чыгымнар исә 29,43 триллион һәм 29,24 триллион сум күләмендә каралган.

Дәүләт Думасы Россиядә ЛГБТны (гадәти булмаган җенси мөнәсәбәтләрне) пропагандалауны тыю турында закон проектын соңгы укылышта кабул иткән. Депутатлар балалар, шулай ук зурлар арасында мондый мөнәсәбәтләрне алга сөрүче материалларны тыюны күздә тоткан законны бертавыштан хуплаган.
Шулай ук педофилия һәм җенесне алыштыруны пропагандалауга да тыю кертелгән. Штраф – 10 миллион сумга кадәр.

Быел 10 ай эчендә Татарстанда 799 туберкулез очрагы ачыкланган. Бу – узган елның шушы ук чорындагыга караганда 7 процентка күбрәк (744 булган). Роспотребнадзорның Татарстан буенча идарәсе хәбәренә караганда, республикада барлыгы 1581 сырхау туберкулез буенча учетта тора. Шуларның 33 проценты тирә-юньгә микобактерияләр бүлеп чыгара, ягъни актив формада чирли. 8,6 меңнән артыграк кеше сырхаулар белән элемтәдә тора. Шуның 9ы, вакытында тикшеренмәү һәм профилактик даруларны тиешенчә эчмәү сәбәпле, авыру йоктырган. Ел башыннан бирле 14 яшькә кадәрге 20 бала һәм 15–18 яшьлек 7 үсмер чир иярткән. Балигъ булмаганнар арасында чирләү очраклары узган елдагы белән чагыштырганда 17,4 процентка арткан.

Бу көннәрдә Татарстанда явым-төшемле һава саклынып кала. Юлларда – бозлавык. Синоптиклар әйтүенчә, шимбә – 26 ноябрьдә, аз гына кар көтелә. Кайбер районнарда – томан. Көндез һава температурасы –1…–6, төнге сәгатьләрдә –3…–8 градус. Якшәмбе – 27 ноябрьдә явым-төшем булмый диярлек. Көндез термометрның тере көмеш баганасы –5…–10 градуска, төнлә –7…–12 градуска кадәр төшәчәк.
Гидрометеоүзәкнең башлангыч фаразына караганда, киләсе атна башында республика антициклон йогынтысында калачак. Явым-төшем ихтималы аз. Һава температурасы тагын да төшәчәк.

Районнарда ни хәлләр?

Саба

Шәмәрдәндә яшәүче Тайфә әби Лотфуллина 102 яшен тутырды. «Аллага шөкер, бүген биш вакыт намазымны калдырмыйм, газета-журналлар да укыйм. Кешене хөсетлек чире картайта, бервакытта да башкаларда булганнан көнләшмәдем, кулымнан килгәнчә ярдәмләшеп яшәдем», – ди Тайфә әби. Аңа гомер юлында язмыш сынауларын күп кичерергә туры килсә дә, әбекәй, зарлану-сыктауны белмичә, тормыш юлын зур сабырлык белән үтә. Арча районы Ашабаш авылында туган кыз сугыш вакытында кырчылык бригадиры булып эшли. Сугыштан яраланып кайткан Сеҗе авылы егете Хәбри белән гаилә корып, 8 бала тәрбияләп үстерәләр. Ил-көнгә иминлек, балаларына, 14 оныгы, 20 оныкчыгына хәер-дога кылып яши.
(«Саба таңнары»)

Тукай

Иске Абдул авылында татарның танылган көрәшчесе Раббани Шәриповка һәйкәл ачтылар. Тантанада Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, республиканың Көрәш федерациясе президиумы рәисе Марат Әхмәтов, Тукай районы башлыгы Фаил Камаев катнашты. Тантана алдыннан алар, Раббани Шәрипов яшәгән йортка барып, аның хәлләрен белештеләр. Түбән Суыксу авылында исә Раббани Шәрипов хөрмәтенә балалар һәм үсмерләр арасында инде 12 нче мәртәбә көрәш турниры узды. Раббани Шәрипов – герой шагыйрь Муса Җәлил истәлегенә «Ватаным Татарстан» газетасы гамәлгә куйган бәйгенең өч мәртәбә (1969, 1971, 1973 нче еллар) җиңүчесе.
(«Якты юл»)

Питрәч

Россия җырчысы Дима Билан, Питрәч авылында бабасының йортын сатып алып, аны яңартырга җыенган. «Ләкин Дима уйга калды әле... Мин аңа, Дима, синең монда тынгылык бирмәячәкләр бит, дигән идем. Ә ул, әйе, гаиләмне тынычлыкта калдырасы иде шул, дип куйды», – дигән аның күршесе Любовь Маркова. Танылган җырчы 9 ноябрьдә туган авылында булып киткән. Соңыннан ул социаль челтәрләрдәге битләрендә туган йортыннан видео да урнаштырган. «Питрәчтә, балачагымның бер өлеше хатирәләрен саклаучы бабам йортында булдым. Таныш кешеләрне күрүемә бик сөендем! Бу йорт миңа галәмәт зур булып тоела иде. Бирдә бик күп карлыган куагы үсә иде. Бер почмакта – мичкә. Җәен суы җылына, шунда коенабыз. Кыслага охшаш ниндидер «җанварлар» белән... Әмма моңа исебез дә китми иде», – дигән Билан.
(«Татар-информ»)

Бөгелмә

Районның хатын-кызлар берлеге «Яңа ел уенчыгы» акциясен башлап җибәргән. Алар Бөгелмә халкын балалар паркындагы чыршыны бергәләп бизәргә чакыра. Теләгән һәркем үз куллары белән уенчык ясый ала. Шуннан соң ул ике ай дәвамында паркка килгән кунакларны сөендереп торачак. Акция бер ай дәвам итәчәк.
(«Бөгелмә-информ»)

ТӨРЛЕЛЕКТӘ – БЕРДӘМЛЕК

Дин, мәдәният һәм сәясәтне нәрсә берләштерә? «Валдай» халыкара дискуссия клубы конференциясендә шул сорауга җавап эзләделәр. Белгечләр уртак фикергә килде сыман. Өчесе дә уртак кыйммәтләр өчен хезмәт итә. Хәзерге киеренке чорда аеруча.

tatarstan.ru

Казан «Валдай» халыкара дискуссия клубының «Дини күптөрлелек һәм милли бердәмлек» темасына конференциясен кабул итте. Фикер алышуга Россия һәм чит илләрдән дин әһелләре, фәлсәфәчеләр, дин белгечләре, социологлар, галимнәр җыелды. Аларны Россиянең, аерым алганда Татарстанның, күпмилләтле һәм күпконфессияле дәүләт төзүдәге тәҗрибәсе кызыксындырган.

Катнашучыларга видеоэлемтә аша Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та хәер-фатиха бирде.

– Конференциядә телгә алыначак темалар – дини күптөрлелек һәм милли бердәмлек – Татарстан өчен бик якын. Бездә 170тән артык милләт вәкиле яши, киләсе елны республикада Милли традицияләр һәм мәдәниятләр елы дип игълан иттек. Сезнең абруйлы фикерләрегез һәм форумда яңгыраган киңәшләр безнең барыбызга да файдалы булыр дип ышанам, – диде Рөстәм Миңнеханов. Ул искәрткәнчә, Татарстан, күпмилләтле Россиянең аерылгысыз өлеше буларак, традицион кыйммәтләрне саклау мәсьәләсенә җитди игътибар бирә.

Шунысын да искә төшереп китәргә кирәк: быел Татарстан Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгын билгеләп үтә. Аны федераль дәрәҗәдә уздыру максаты куелган иде. Бу да илдәге диннәр арасында мөнәсәбәтләрнең ни хәлдә булуын күрсәтә инде. Президент Администрациясе җитәкчесе Әсгать Сәфәров ассызыклаганча, бу тарихи вакыйга Россиядә көнбатыш һәм көнчыгыш традицияләренең кисешүенә этәргеч бирде. «Моңарчы күрелмәгән чикләүләр басымы чорында дин һәм милләтара тынычлыкны һәм татулыкны ныгыту бурычлары беренче урынга чыга. Төрлелек безнең өстенлегебез булып тора», – диде ул.

Пленар утырышта катнашкан белгечләр нык дәүләт төзүдә диннәрнең роле турында фикер алышты.

Мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин әйтүенчә, традицион диннәр алга сөргән кыйммәтләр барлык халыклар өчен дә уртак.

– Аларны уртак тамырлар берләштерә. Барысында да тыйнаклык, әхлак төшенчәләре телгә алына, – диде ул. – Күп гасырлар бер җирдә яшәгән, гаилә, милли һәм дини традицияләрне хуплаган буыннар арасында бәйләнеш булганда, кешедә үз Ватанына карата күп хисләр туа. Беренче чиратта, бу – аның язмышы өчен җаваплылык.

Казан һәм Татарстан митрополиты Кирилл да традицион кыйммәтләрнең әһәмиятен ассызыклады. Аларга кешелек үсеше дә турыдан-туры бәйле.

– Ватанга мәхәббәт, тынычлыкка һәм татулыкка омтылу, ата-бабаларыбыз тарихына һәм истәлегенә хөрмәт, традицион гаилә кыйммәтләре, хезмәт сөючәнлек һәм риясызлык – болар барысы да күпмилләтле Россия халкын аерып торган сыйфатлар. Алар традицион диннәр катнашында формалашкан, – диде митрополит. – Казан – зур гаилә. Без монда бергә кайнашабыз. Ул – православие шәһәре дә, ислам каласы да. Карашларыбызны саклыйбыз һәм бер-беребез белән тату яшибез.

Иң мөһиме – рухи бердәмлек. Татарстанның Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев әнә шуңа игътибар итте. Бу җәһәттән Татарстанның мактанырлык нәтиҗәләре бар. Әмма, Дәүләт Киңәшчесе әйтмешли, гамәл кылырга вакыт җиткән.

Минтимер Шәймиев сүзләренчә, Татарстан халыкларының бердәмлеген саклап калу эше мөселманнар һәм православие вәкилләре өчен изге саналган урыннарны, дини объектларны яңарту ярдәмендә алып барылган. Җәмгыять өчен тышкы үзгәрешләр генә кирәк димәгән бит. Минтимер Шәймиев әйтмешли, иң мөһиме: йөрәктәгесен үзгәртә алганнар.

Минтимер Шәймиев бу җәһәттән Казанның 1000 еллыгы алдыннан булган бер вакыйганы искә алды.

– Ул елны уңыш бик мул булды. Мәдәни мирас корылмаларын төзекләндерү максаты да куелды. Хуҗалык җитәкчеләренә мөрәҗәгать иттек. Алар, фондны булдыру өчен 2 центнер ашлык сатып, шуның акчасын объектларны торгызуга күчерергә ризалашты. 32 млрд сум җыйдык! Бу «Яңарыш» фонды өчен нигез булды, – диде Дәүләт Киңәшчесе. – Без матди мирасны яңадан халыкка кайтарабыз һәм шул ук вакытта рухи яктан байыйбыз.

Сүз уңаеннан, 1986 елда Татарстанда 18 мәчет һәм 15 православие гыйбадәтханәсе булса, хәзерге көндә ислам дине тарафдарлары өчен 1500 һәм православие динен тотучыларга 500ләп корылма бар.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Икенче туган көн

Республика клиник хастаханәсе табиблары йөрәге туктаган 66 яшьлек ир-атның гомерен саклап калган. Бирегә йөрәк табибына күренергә дип килгән ир-атка, бераз соңга калу сәбәпле, автобус тукталышыннан хастаханәгә кадәр йөгерергә туры килә. Табибка керергә чират көтеп утырганда хәле авырая башлый.

Кардиолог Александр Гусев белән кан тамыры хирургы Георгий Скрябин тиз арада ярдәмгә ашыга. Табиблар аның йөрәгенә кардиовертер-дефибриллятор җиһазы урнаштыра. «Өянәкләр кабатлана калса, әлеге җиһаз йөрәкне автомат рәвештә эшләтеп җибәрәчәк. Әле ярый бу хәл хастаханәдә килеп чыккан. Йөрәге үзе генә булганда туктаса, аны коткарып калу мөмкин булмас иде», – дип хәбәр итәләр Республика клиник хастаханәсенең матбугат үзәгеннән.

Әлеге хастаханә табиблары тарафыннан могҗизалы рәвештә саклап калынган гомерләрнең беренчесе генә түгел бу. Хәтерләсәгез, быелның апрель аенда да алар берничә минут эчендә ике тапкыр йөрәге туктаган ир-атны коткарган иде.

Сүз уңаеннан, узган ел Республика клиник хастаханәсенең стационар бүлегендә 50 меңнән артык кеше дәваланган. Ел дәвамында 11 мең операция ясалган. Бу 2020 ел белән чагыштырганда 2 мең операциягә күбрәк. Узган ел бирегә һава транспорты белән 163 авыру китерелгән.

Җитсә җитә акча да

Татарстанда хезмәт хаклары арткан. Рәсми мәгълүматларга караганда, бүген республикада уртача айлык хезмәт хакы 50 мең сумга җиткән. Анысы да монысы, эштән канәгать булу өчен татарстанлыларга 45 мең сум да җитә, ди.

Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы халыкның күпме акча алып эшләвен әйткән. «Статистика мәгълүматларына караганда, быел гыйнвар – август айларында Татарстанда уртача хезмәт хакы 49989 сум тәшкил иткән. Узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, күрсәткеч 17,3 процентка арткан», – дип белдергәннәр министрлыкта.

Хезмәт базарында кайсы һөнәр ияләренә кытлык зур булу да билгеле. Бер эшсезгә алты вакансия туры килә, ди белгечләр. Барыннан да бигрәк, транспорт йөртүчеләр җитми. Бүген хезмәт базарында шундый 1,6 мең урын буш тора. Йөртүчеләргә 39500 сум хезмәт хакы вәгъдә иткәннәр. Шулай ук, эш бирүчеләргә инженерлар (хезмәт хакы – 36800 сум), табиблар (36800), пешекчеләр (24500 сум), электр һәм газ белән эретеп ябыштыручылар (39900 сум) бик кирәк. Кондукторлар һәм шәфкать туташлары да җитми икән. Республика күләмендә 53 мең эш урыны буш тора. Эш эзләүчеләргә тәкъдимнәр төзелеш, транспорт, мәгариф һәм белем бирү, сәламәтлек саклау кебек тармакларда күбрәк.

Үз эшеңнән канәгать булу өчен күпме акча алып эшләргә кирәк? Интернет-порталларның берсе әнә шул сорауга җавап табарга тырышкан. Баксаң, Татарстанда яшәүчеләргә моның өчен уртача 44900 сум да җитә икән. Күрше Башкортстанда яшәүчеләргә эшне яратып башкару өчен ай саен уртача 48 мең сум акча кирәк. Идел буе федераль округына керүче төбәкләр арасында беренче өлкәкә Түбән Новгород та эләккән. Биредә яшәүчеләр ай саен уртача 42300 сум акча алып эшләргә хыялллана. Самара һәм Пермь өлкәләре халкына да 40 мең сумнан күбрәк хезмәт хакы яхшырак. Оренбург, Ульяновск, Пенза, Саратов өлкәләре, Удмуртия һәм Чувашия республикаларында яшәүчеләр исә иң югары чикне 38 мең сум дип билгеләгән. Иң тыйнак төбәкләр – Мордовия (36800 сум), Киров өлкәсе (36200 сум) һәм Мари Иле (35500 сум).

КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен хезмәт ветераны **Моратов** Яшәр Габдулла улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Казан дәүләт архитектура-төзелеш университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Цифрлы нигезгә корылган юл төзү технологияләре» кафедрасы профессоры **Гатиятуллин** Мөхәммәт Хәбибулла улы, «Татарстан Республикасы Адвокатлар палатасы» дәүләтнеке булмаган коммерциячел булмаган оешмасы президенты **Дмитриевская** Людмила Митрофановна, Татарстан Республикасының мәдәни-рухи мирасын саклауга һәм баетуга зур өлеш кертүе өчен «В.И. Качалов исемендәге Казан академия рус зур драма театры» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе директоры – сәнгать җитәкчесе **Славутский** Александр Яковлевич **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

УКЫГАНЫМ – СИНЕҢ ӨЧЕН...

Энә дә – бүләк, дөя дә – бүләк, ди халык. Ә менә укытучыларга иң яхшы бүләк нәрсә икәнен беләсезме? Белмәсәгез белегез: көндәлектәге «дүртле», «бишле»ләрдән дә яхшысы юк! Без әйтмәдек, түрәләр әйтте. «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында коррупциягә каршы көрәш турында сөйләштеләр. Яңа ел алдыннан искәртеп куюлары, күрәсең.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Мәктәпләр, балалар бакчалары акча җыймыйча яши аламы? Бу сорауга төгәл җавап юктыр. Кайбер әти-әниләр бүләккә дә, чиста суга да, ремонтка да ике дә уйламыйча акча тапшыра, икенчеләре үз баласына эш дәфтәрләре сатып алырга да каршы. Әнә шуннан башлана да инде… Быелның тугыз аена алынган мәгълүматларга караганда, Татарстан мәктәпләре һәм балалар бакчаларында әти-әниләрдән законсыз акча җыюга бәйле 103 шикаять теркәлгән. Урынга барып тикшерүләр нәтиҗәсендә, 21 хезмәткәр дисциплинар җаваплылыкка тартылган. «Акча җыю очраклары нигездә ремонт ясау, эш дәфтәрләре, уку-язу кирәк-яраклары сатып алуга бәйле», – дип аңлатты матбугат очрашуында Татарстан мәгариф һәм фән министры урынбасары – мәгариф өлкәсендә күзәтчелек һәм контроль департаменты җитәкчесе Рәмис Мөҗипов.

«Эш дәфтәрләре дәрес өчен кирәк бит, мәктәпләрне аның белән ник дәүләт тәэмин итми?» дигән сорауга да җавабы бар урынбасарның. «Эш дәфтәрләре уку-язу алымнарын тагын да яхшыртырга ярдәм итүче өстәмә әдәбият булып санала. Ул әти-әниләр ризалыгы белән генә сатып алынырга мөмкин. Мәктәпләр уку әсбаплары белән йөз процент тәэмин ителгән», – диде ул.

«Бездән акча талыйлар», – дип чаң сугучы әти-әниләр Казанда һәм Чаллыда күбрәк. Хәер, бу аңлашыла да. Зур шәһәрләрдә балалар саны да бермә-бер күп. Ә менә күзәтүче органнарга килеп ирешкән мөрәҗәгатьләрне теге яки бу төбәктәге укучылар санына бүлеп караганда, «кара исемлек»кә Әтнә, Югары Ослан, Питрәч һәм Балык Бистәсе эләккән. «Сүз тикшерү барышында расланган очраклар түгел, ә статистика мәгълүматлары турында бара», – дип тә искәртте Рәмис Мөҗипов. Аның каравы Балтач, Зәй, Мөслим, Теләче һәм Яңа Чишмә районнарында яшәүче әти-әниләрнең күңеле тыныч. Биредә мәктәп һәм балалар бакчаларында законсыз акча җыюга бәйле мөрәҗәгатьләр гомумән дә юк. Әти-әниләр белән эшли беләләр, ахры.

Ике арада уртак тел табып була, әлбәттә. Моны Татарстан Президентының коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенең оештыру бүлеге мөдире Алексей Панкратов та ассызыклады. «Мәктәпләрдә акча җыю республикада озак вакыт кискен проблема булып торды. Әлеге юнәлештә кабул ителгән чаралар вазгыятьне җиңеләйтте. Без хәзер әти-әниләрдән килеп ирешкән шикаятьләр саны кимүен күзәтәбез. Өстәвенә укытучылар һәм тәрбиячеләр акча җыю эшеннән читләштерелде», – диде Алексей Панкратов.

Хәер, акча кайда да тынгылык бирми. Республика көллиятләре һәм югары уку йортларының – үз «чир»е. Биредә урындагы затларның үз мәнфәгатьләрен башкалардан өстен кую очраклары күп, ди белгечләр. «Хезмәткәрләр үзләренә файда алу өчен, туганнарын эшкә ала, аларга яхшы хезмәт хакы билгели, өстәмә премия түли», – дип сөйләде Рәмис Мөҗипов. Ел башыннан бирле шундый 69 очрак ачыкланган. Нәтиҗәдә 7 кеше, шул исәптән 2 җитәкче эшеннән алынган. Кайберәүләр булмаган студентларга стипендия түләп булса да, әзме-күпме акча эшләп калмакчы. Чүпрәлеләге уку йортларының берсендә, мәсәлән, директорны, аның урынбасарын һәм тагын берничә хезмәткәрне студентлар исемлегенә өстәп куйганнар.

«Без әти-әниләрдән акча җыюга каршы, – диде Рәмис Мөҗипов. – Хәтта бүләккә дә. Укытучыга иң зур бүләк ул – укучыларының яхшы билгеләре. Әлбәттә, балалар Укытучы көне, Яңа ел, 8 Март кебек бәйрәмнәр турында белергә, укытучыны хөрмәт итеп, аны котларга тиеш. Тик әти-әниләрдән акча җыю бәрабәренә түгел».

Матбугат очрашуында тикшерүчеләр тарафыннан әнә күзе аша үткән тагын бер тармак – авыл хуҗалыгы. Ни хикмәт, сала турында сүз чыккач, сөйләрлек сүз күп булмады.

– Бездә республиканың кайсы районнарында коррупция очраклары күбрәк булуына бәйле статистика юк, – диде Татарстан авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының беренче урынбасары Наил Залаков. – Вазгыять төрле булырга мөмкин. Безнең өчен авыл хуҗалыгына бүлеп бирелгән акчаның тиешенчә тотылуы мөһим. Җир файда китерергә тиеш. Әлеге юнәлештә зур эш башкарыла.

Аерым очракларга Алексей Панкратов кына тукталды. Аның фикеренчә, авыл хуҗалыгы үсешенә бүлеп бирелгән акчаны контрольдә тоту аеруча зур җаваплылык таләп итә. Быел төрле субсидия, грантларны тиешенчә файдаланмау очраклары Арча, Биектау, Спас, Азнакай, Мөслим кебек районнарда ачыкланган. Спаста, мәсәлән, фермер сөт җитештерүне үстерүгә дип бирелгән субсидияне кесәсенә салып куймакчы булган. Азнакайда берәү җиһаз сатып алуга дип откан грант акчасына үзенә өр-яңа машина алып кайткан. Укытучылар һәм тәрбиячеләр генә «иномарка»ларга кызыга башламасын. Булыр аннары хәлләр...

Эльвира ВӘЛИЕВА

Әйтеп кенә бактым

Ышан син, бар...

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Бер таныш белән хатыннарны рәхәтләнеп «чәйнәдек» әле. Моның хатыны ял йортына киткән булган. Вакытлыча ялгыз калган ирләр берәр «этлек» эшләү турында уйламый калмый бит инде (үзем ул исәпкә кермим). Хатыннары, йә ирләре ял йортына киткәннәр турында нинди генә мәзәкләр, гыйбрәтле хәлләр юк.

Әлеге танышым да миңа бер гыйбрәт сөйләде. Кыскасы, хатыны югында моның, йомшак кына, образлы итеп әйткәндә, «уҗымга чыгып керәсе» килгән. Өенә бер «Мәфтуха» алып кайткан бу. Сөяркәсен озатып җибәрүе генә булган, хатыны кайтып төшкән. «Бер көн алдан кайтты, хет шалтыратып әйтеп тә куймады, ышан син хатыннарга», – ди бу.

– Ярый әле өстегезгә кайтып кермәгән, – дип тынычландырган булам.

– Спитсиәлне эшләгән инде ул моны, мине тикшермәкче булган. Иренә ышанмагач, нигә яшәргә кирәк?! Юк-бардан да гаиләләр таркалырга мужет, әйе бит?! – дип гел акланырга маташа бу. «Үзеңне бел!» – диясе килгән иде дә танышыма, үпкәләр дип шикләндем.

Мәзәккә тартым бу хәлнең искә төшүе Германия канцлеры Олаф Шольцның Польша җиренә ракета төшү уңаеннан әйткән сүзләренә бәйле. Ракетаның кайсы як тарафыннан җибәрелүе тикшерелде, аның Россиянеке түгеллеге расланды. Әмма федераль канцлер башкача уйлый. Янәсе, Россия Украинага кермәгән булса, ракета Польша җиренә барып төшмәс иде.

Танышымны Шольц белән чагыштырмыйм, әмма акланулары бертөрлерәк булуы кызык. Ягъни ирнең хыянәт итүендә ялдан иртәрәк кайткан хатын гаепле булып чыга. Канцлерның әйткәннәрен сүзен-сүзгә диярлек Бөекбритания Премьер-министры Риши Сунакның кабатлавы да кызык бит. Алдан сөйләшеп куйганнар диярсең. Ышан син аларга.

Зур ызгышлар вакытында мәгълүмат сугышының яңа көч алуы табигый инде ул. Бу сугыш еш кына «үзеңне бел!» дигән принципка нигезләнә һәм мөмкин булган бөтен ысул-алымнар кулланыла. Кайчак кайда ялган, кайда хаклык икәнен дә бутарга мөмкин. Мәсәлән, интернет сайтларында Олаф Шольцның бабасы Фриц фон Шольц эсэсчы булган дигән мәгълүматлар пәйда булды һәм «алма агачыннан ерак төшми» дип тә яздылар.

Фон Шольцның безгә каршы Украина, Ростов өлкәсендә, Кубань һәм Кавказда сугышканлыгы турында хәбәрләр дә бар. Бу мәгълүматлар ни дәрәҗәдә дөрестер, кистереп әйтеп булмый. Әле бит «бала атасы өчен җавап бирми» дигән сүзләр дә бар. Ә менә Бундестагта, ягъни федераль парламентта Олаф Шольцның Россиягә карата әйтелгән һәр чыгышын кул чаба-чаба хуплаулары хак. Ә канцлер нацизмда, фашизмда нәкъ менә Россияне гаепли. Зур корбаннар биреп, фашизмга каршы көрәшкән безнең илдә фашизм туа һәм яши аламы соң ул?

Канцлерның буталуы, әлбәттә, аклану өчен, нәкъ минем танышым кебек дип әйтмәкче булам. Алай ук түбәнгә төшмәскә иде, канцлер әфәнде! Моннан соң да ышан син, бар...

БЭНКМАН-ФРИД – БИТЛЕК КИГӘН ИБЛИСМЕ,

ЯКИ НИЧЕК ИТЕП ЮЕШ БОРЫН МАЛАЙЛАР ДӨНЬЯНЫ ТҮНТӘРӘЛӘР?



pixabay.com

Бу авторның сишәмбе-чәршәмбе саннарында алып барган күзәтүләре белән танышучыларның күзләренә FTX криптобиржасының санаулы сәгатьләр эчендә түнтәрелеп, дистәләгән миллиард доллар акчаның «оф» итүгә сүнгән шәм ялкыны кебек юкка чыгуы чагылмый калмагандыр. Аңлыйм: ул яңалыкны укыганда, берәүнең дә күзенә яшь килмәде, йөрәкләре дә дерт итеп китмәде... Ә бит чынлыкта дөнья финанс системасында бик караңгы эпоха башланып килә һәм ул алдагы берничә елда безнең барыбызның да матди хәленә нык тәэсир итәчәк. Аның йогынтысы американнар Россиягә каршы керткән санкцияләргә караганда көчлерәк булыр, дип уйлыйм.

Россия күпме югалтты әле? 300 миллиард доллар тирәсе дәүләт резервларын һәм триллион долларлап артык олигархлар акчасын. FTX түнтәрелгәндә дә россиялеләр югалттылар, биржага акча тыгучылар арасында алар дүртенче урында тора, диделәр. Ничә миллиард доллар икәне безгә билгесез. Акча безнең кесәдән төшеп калмагач, кайгырмыйбыз, әмма ил икътисадына инвестицияләнергә мөмкин булган миллиардлар яисә миллионнар югалды. Вазгыятьнең куркыныч ягы анда да түгел хәтта. Башында Сэм Бэнкман-Фрид исемле, борын асты да кибеп бетмәгән малай торган биржаның түнтәрелүе криптодөньяда чылбыр реакциясе китереп чыгарып ята. Genesis дип аталган криптофирма, әҗәткә миллиард доллар бирүчеләр табылмаса, банкротлыкка чыгачагы белән куркыта. Үз тегермәннәрендә миллиардларны әйләндерүче тагын берничә криптобизнес түнтәрелеп килә. 2008 елгы кризисны алдан фаразлаган Нуриэль Рубини «Binance» фирмасының озакламый табутка кереп ятачагын әйтә. Бу атамаларның күпчелек укучыларга берни дә аңлатмавын беләм мин. Махсус өйрәнмәсәм, үземнең дә ис китмәс иде. «Binance» турында шуны гына әйтәм: аның хуҗасы Чанпэн Чжао – чыгышы белән кытайлы булган Канада гражданины – 65 миллиард долларлык капиталы белән дөньяның иң бай кешеләре исемлегендә – 19 нчы урында. Бизнесы җимерелсә, ул ыштансыз калачак. Аңа акча биргән бик күп миллиардерлар һәм миллионерлар суган суы суырачак. Ә Җир шарының бөтен байлыгы – олигархлар кулында. Безнең кебек гади халык бик аз гына байлыктан файдалана. Юк, юк, миллиардерларның кара ипи ашауга күчүенә бер дә кайгырмыйбыз без. Әмма алар бөлгәндә, бөтен Җир халкын финанс цунамие каплый, өскә калкып чыгу кыен була. Кешеләр эшсез калалар, кредитлары түләнми, йортлары сатыла... Менә шул эпоха башланып килә һәм мин сезгә аның ничек башлануын FTX мисалында кыскача гына сөйләргә телим.

Криптовалюталар турында ишеткәнегез бардыр инде. Арагызда, шуларны сатып алып, җиңел генә баерга теләүчеләр дә булмый калмас. Һәрхәлдә, «Фейсбук»та вакытында биткоин сатып алмый калуына ачы үкенеч белдергән татар яшьләрен бер генә тапкыр күрмәдем. Кызыкмаслык түгел дә шул: 2010 ел башында 0,003 долларга тиң булган биткоин ел ахырында 0,30 долларга кадәр үсә. Табыш – 9900 процент. Я әйтегез әле, кайсы банк депозиты бер елга шуның кадәр процент бирә? 2011 елда биткоин тагын 1473 процент үсти әле. Аның 60 мең долларга җиткән чаклары булды. Кыскасы, вакытында 3 долларга биткоин сатып алсаң, бәясе югары ноктага җиткәндә, синең 40–60 миллион доллар байлыгың булыр иде. Кызыктырамы? Кызыктыра торгандыр шул. Вәләкин биткоин гел үсеп кенә тормый, түнтәрелә дә. 2014 елда ул бәясенең 58 процентын югалтты, 2018дә 73 процент минуска китте. Быел биткоинның югалтулары – 65 процент. Ел ахырына кадәрниләр буласын белмибез. Бер генә нәрсәне әйтә алабыз: байлык андый темплар белән үсә икән, ул чын түгел. Ничек кабарган булса, аннан да тизрәк шиңәчәк.

Криптовалюталар шулай зур темплар белән үскәндә, криптобиржаларның ничек баюын күз алдына китерә аласыздыр. Боларда бик җиңел генә йөз миллиардлаган долларлар әйләнә. Кешеләр, табышка кызыгып, шуларга акча тыгалар. Башында Остап Бендерны көнләштерерлек махинацияләр остасы Сэм Бэнкман-Фрид дигән адәм торган FTX – шундый биржаларның берсе, уңышлысы иде.

Биржасы түнтәрелеп, мошенник икәне киң катлауга мәгълүм булгач, Бэнкман-Фрид турында «BlockFi» директорларының берсе: «Сэм Бэнкман-Фрид – ботаник битлеге кигән иблис иде», – язып чыкты. Бизнесы югары үрләгәндә, аңа башкачарак бәя бирделәр: вундеркинд, иң яшь даһи дигән исемнәр белән макталды. Менә бу юлларны укучылар кайсыгыз берничә дистә миллиард долларлык кердит алып, аны җилгә очыра ала? Берегездән дә булмый. Икенче өлеше – җилгә очыру дигәне барыбызныкы да җиңел барып чыгар иде, ә менә зур әҗәтләрне безгә беркем дә бирмәячәк. Бэнкман-Фридның әти-әнисе – Американың финанс җинаятьләренә каршы көрәш өлкәсендәге әйдәп баручы юристлар, партнершасының (алар хатын дип тә, сөяркә дип тә әйтмиләр, партнерша диләр, Сэмның андый партнер һәм партнершалары берәү генә түгел, алар унлап кеше бер гаилә кебек бергә яши) әтисе – Биржалар һәм кыйммәтле кәгазьләр буенча Америка комиссиясенең (SEC) элекке җитәкчесе, финанс иерархиясендә өченче дәрәҗәдәге кеше. Вундеркинд, менә шуларга аркаланып, бизнес башлап җибәрә, үзенә берни дә булмас дип ышана. Әмма бу юлларның авторы Сэмны «иблис иде» дигән бәядән коткара, ул иблиснең җирдәге илчесе белән (бар шундый кеше Җир шарында бүген, ул ил җитәкчеләрен үз кубызына биетә) тыгыз элемтәдә тора, шуның кушканнарын үти дип саный. Бэнкман-Фрид артында торучыларның протекциясенә таянып, криптобиржа оештыра, токеннар (криптовалюталарны бәяли торган берәмлекләр) чыгара, аның токеннарының байтагын «Binance» сатып ала. Шул токеннар бәясенә гигант кредитлар алып, башка компанияләрне үзенеке итә. Бизнесы кабаруын дәвам иткән булыр иде, бәлки, әмма ул хакимияттәге элемтәләрен файдаланып, «Binance»га каршы законнар чыгартмакчы була. Аның бу гамәле кытайларның («Binance» – асылда чиннар бизнесы) җен ачуын чыгара. Алар «Твиттер»да: «Син нәрсә, егет, шулай эшлиләрмени, алайса без синең токеннарыңны сатабыз», – дигән эчтәлектә твит эләләр. Куркып калган Сэм аларга килешү тәкъдим итмәкче була, әмма инде токеннар сатуга чыгарылган һәм FTX биржасы түнеп бара, токеннарының бәясе 99 процентка төшә. Чиннарның да котын ала бу хәл, әмма кире чигенергә соң була. Яңа туган баланы берничек тә ана карынына кире этеп кертеп булмый бит. Менә шулай итеп криптокризис дигән сабый мәйданга чыга һәм бик күп биржаларны тәртеп егарга әзерләнә. FTX биржасына кризис идарәчесе билгеләнәр, әмма ул документлар белән танышкач: «Мондый хәлне беркайчан да күргәнем юк иде әле», – ди. Автор инде үзенә билгеләнгән мәйданнан чыгып киткән икән, югыйсә Бэнкман-Фридның Американың идарәче катлавын ничек итеп сатып алуы турында озак сөйли алыр иде. Барыбыз да: «Мондый хәлне беркайчан да күргәнем юк иде әле», – дип әйтә торган вакыйгалар тезмәсе башланып килә.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

2 декабрьдә сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Гөлгенә ШИҺАПОВА** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Юл акчасы ни өчен түләнми?

Миңа 83 яшь. Ике ел инде юл акчасы түләмиләр. Сәламәтлегем юк. Күптән түгел генә Баулыга күзлек сатып алырга бардым. Таксида бардым, такси белән кайттым. 600 сум акча китте. Аз акча түгел бит. Ни өчен юл акчасы түләмиләр икән?

Хакимә МАНСУРОВА.
Баулы районы Мортаза авылы

Республика матди ярдәм күрсәтү үзәгенең Баулы районындагы бүлеге җитәкчесе Ләйсән Могътәсимова:
– Юл акчасы пенсионерның айлык кереме 20 мең сумнан артмаган очракта түләнә. Шулай ук пенсионер исемендәге милек тә исәпкә алына. Әйтик, аның исеменә язылган йорт тирәсендәге җир кишәрлегенең мәйданы 10 сутыйдан артмаска тиеш. Бу очракка килгәндә, 2020 елдан бирле Хакимә апа исеменә язылган җир кишәрлегенең мәйданы 45 сутыйны тәшкил итә. Күргәнегезчә, бу билгеләнгән нормадан күбрәк. Шуңа да Хакимә апага юл акчасы түләнми.

P.S. Сораулар калса, тулырак мәгълүматны 8 (800) 000 000 номеры буенча Россия Пенсия фондының ярдәм «кайнар линия»сенә шалтыратып белешергә мөмкин.

Укытучыларга кире кайтарыламы?

Авылда яшәүче укытучыларга газ керткән өчен түләгән акча тулысынча кире кайтарыла, дип ишеттек. Бу чыннан да шулаймы? Йорт электр белән җылытылган очракта аның өчен түләнгән акча кире кайтарылмыймы?

Исемем редакция өчен генә

Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының матбугат хезмәте җитәкчесе Рафаил Гыйниятуллин:
– Авыл җирендә яшәүче укытучыларга газ кертү һәм газ җиһазларын сатып алу өчен махсус субсидия каралмаган.

Сорауның икенче өлешенә килгәндә, бу турыда Татарстан Министрлар Кабинетының «Авыл җирендә, шәһәр тибындагы бистәләрдә эшләүче һәм яшәүче аерым категориядәге кешеләргә торак һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында»гы 192 номерлы карарда язылган. Әлеге документ нигезендә, авылларда һәм шәһәр тибындагы бистәләрдә яшәүче укытучылар өчен торак, җылылык һәм ут өчен тотылган чыгымнарны тулы күләмдә компенсацияләү каралган.

Ничек отышлы булыр?

Узган ел йорт салу өчен 30 елга 9,7 процентлы ипотека алган идек. Алдан түләп, вакытын 20 елга калдырдык. Рефинанслау ясатырга тели идек, файдасы булырмы икән? Ставканы ничә процентка киметкәндә, отышлы булачак?

ЗӘРИНӘ. Казан

Дамир Сафиуллин, риэлтор:
– Сезнең очракта рефинанслауны бөтенләй ясап булмый. Ипотекага фатир яки йорт алучылар өчен мондый мөмкинлек бар, ә менә йорт салучылар өчен, кызганыч, юк. Өстәвенә ставкалар да югары.

Намазым кала, нишләргә?

Аякларым авырту сәбәпле, намаз укый алмыйм. Тәһарәт ала алмыйм чөнки. Намазларым кала, шуңа бик борчылам. Миңа нишләргә икән?

ГАЛИМӘ әбиегез. Әлмәт

«Әл-Мәрҗани» мәчете имамы Ансар хәзрәт Мифтяхов:
– Мондый чакта, бәдрәфтә ихтыяҗын үтәгәннән соң, истинҗә кылса (ал һәм арт юлны су белән юып чистарту), шуннан соң тәяммум алса (җир затыннан булган матдәгә учлар белән сугып битне, аннан, янә сугып, терсәкләргә кадәр кулларны сыпыру), шул да җитә. Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән сынау икән, истинҗә һәм тәяммум аша да тәһарәт кабул кылыныр. Гел укымаганчы, намазын тәяммум алып, вакытында укый алса, хәерлерәк. Аллаһы Тәгалә тәненә, авыруларына шифа биреп, намаз гыйбадәтен үз вакытында үтәргә җиңеллеген насыйп кылсын иде!

Фельдшер кирәк

Авылыбызда иң кирәкле кеше – фельдшер юк. Ни сәбәпле икән? Белешә алмассызмы?

Ләйсән МИНГАРИПОВА.
Балык Бистәсе районы Күгәрчен авылы

Күгәрчен авыл җирлеге башлыгы Альберт Сафин:
– Элекке фельдшерыбыз күченеп китте, аннан алдагысы – лаеклы ялда. Бераз гына сабыр итегез, яңа фельдшер табылыр. Бу турыда сөйләшүләр алып барабыз инде, мәсьәләне тиз арада хәл итәргә тырышырбыз.

Пособие түләнәчәкме?

Киләсе ел башыннан универсаль пособие гамәлгә керә икән. Хәзерге вакытта мин 1 яшьлек балам өчен пособие алам, киләсе елдан ул миңа түләнми башлаячакмы?

АЛСУ. Чаллы

Әлеге сорауга җавапны Россия Хезмәт министрлыгының телеграм-каналындагы аңлатмаларга нигезләнеп бирәбез. Әгәр бала 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туган икән, гаиләнең универсаль пособиегә күчү мөмкинлеге дә, түләүләрне элеккеге кагыйдәләр нигезендә алу мөмкинлеге дә бар. Бала 2022 елның декабрь аенда туса да, аңа 3 яшь тулганчы түләүләрне элеккеге кагыйдәләр нигезендә алырга мөмкин.

Лилия ГЫЙМАЗОВА әзерләде

Укучы сүзе

«ЖУРНАЛИСТ АЛЬБЕРТ ШАКИРОВ: «БУ – БЕЗНЕҢ УРТАК СЫНАУ» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗ

Мин журналист Альберт Шакировның тапшыруларын бик яратып карыйм, саф татарча сөйләме йөрәккә сары май кебек. Төпле, мәгънәле интервью-фараз. Телевидениедә шундый халыкчан журналист булу куандыра. Уңышлар сезгә, Альберт әфәнде! Юлыгыздан тайпылмагыз.

Елена ИЛЬИНА

«МОДА» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗ

Совет чорында халык хәерче булды, диләр. Шөкер, мондый иске ертык чалбар-күлмәк кимәдек. Бу кызга карасаң, җәлләп елыйсы килә. Әтисенең күлмәген, иске чалбар кигән, мескен, дип.

Альбина ГАЙНУЛЛИНА

***

Никадәр алама киенә аласың, шулкадәр «модный» буласыңдыр инде… Ертык чалбар, сүтелеп киткән свитер. Әле аны олы яшьтәгеләр дә кия бит.

Чулпан ҺАДИЕВА

«ӨЧЕСЕ ӨЧ ТӨРЛЕ» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗ

Яннарында эшләүче шәфкать туташлары кая карый икән?..

Лениза МОСТАФИНА

***

Сөбханалла, өчесе дә чибәрләр, буйлары да бер тигез, дигәндәй. Нигә игезәкләргә генә өйләнергә аларга? Кияүгә чыга алмаган кызлар күп бит. Никах сәгатьләре килеп җитмәгәндер.

Мәгъфирә ЗАКИРОВА

«ҮЗГӘРӘБЕЗ ТҮГЕЛМЕ?» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗ

Кызым 8 сыйныфта укый, беренче сыйныфтан ук соры күлмәк, ак яки кара алъяпкыч кияләр. Әтнә районында бу. Аллаһка шөкер, дип куанып туя алмыйм. Үзем 2 сыйныфка кадәр шулай ук форма кидем. Аннан «кем ничек киенә» форматына күчтек. 9 сыйныфта бер төстәге өс, кара төстәге сарафан кидек. Сарафанны исә кемнең ниндиен алырга мөмкинлеге бар, шундыйны кия иде. Безнең киемнәрдә гаилә хәле кычкырып тора иде.

Рамилә АБДУЛЛИНА

***

Без ак алъяпкыч, күрән күлмәк киеп укыдык. Барлык укучылар да бер төсле булгач, үзе бер күңелле иде. «Ак алъяпкычларда ак канат, күңел оча гүя акчарлак» дип җырга салынган юллар әле дә йөрәк түрендә саклана. Укытучы белән укучы аерылып тора иде, безне мәктәп шулай тәрбияләде. Мин үзем әнә шундый форма яклы.

Раилә БАРИЕВА

«ӘНИ БУЛУ КОТКАРА» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗ

Казандагы түләүле клиникаларның күбесендә яшь кенә табибларның да кандидат исеме бар. Ә элегрәк ул исемне алу өчен байтак тәҗрибә тупларга кирәк иде. Ничек ышанырга инде аларга?

Дания ГАЛИЕВА

***

Күбесе бик әйбәт бела, чөнки үзләре теләп укыган балалар.

Фәния СӘЛАХОВА

НӘРСӘ БУЛДЫ СИҢА, КҮҢЕЛ?

Нияз Рахманның шәхси архивыннан

БӘЙРӘМ ЧАРАЛАРЫН ЗУРЛАП УЗДЫРЫРГА КИРӘКМЕ?*

Юк, кирәкми. Мондый вакытта бәйрәм кәефе булмый	35.65 %
Миңа барыбер. Башка илләрны да зурлап бәйрәм итмибез	34.78 %
Бәйрәмсез булмас. Балалар көтә бит	23.91 %
Әйе, кирәк. Бәйрәм безгә өмет бүләк итә	5.65 %

* «ВТ»ның «ВКонтакте»дагы төркемендә уздырылган сораштыру нәтиҗәсе

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Бирәүдә бар, икенчедә юк

Сентябрь ахырында, Россиядә өлешчә мобилизация башлангач, ил төбәкләре бер-бер артлы быел аларда Яңа ел чаралары уздырылмаячагын хәбәр итә башлады. Кайберләрендә алардан тулысынча баш тартсалар, икенче берләре балалар өчен билгеләнгән бәйрәм чараларын гына уздырмакчы. Әйтик, Псков өлкәсе губернаторы бу карарын фронтта да, ил икътисадында да хәлләрнең мөшкел булуы белән аңлатты. «Мондый вакытта салютлар атырып, җырлап-биеп йөрү урынсыз», – дип белдерде ул. Аның бу фикерен Башкортстан Республикасы башлыгы Радий Хәбиров та куәтләде. Бөтен булган чараларны мобилизацияләнүчеләргә һәм икътисадка ярдәм итүгә тотарга кушты ул.

Төбәк җитәкчеләре арасында халыкны бәйрәмнән тулысынча мәхрүм итәргә теләмәүчеләр дә бар. Мәскәү мэры Сергей Собянин, мәсәлән, зур салют, концерт-тамашалар уздырылмаса да, шәһәрнең бәйрәмчә бизәләчәген белдерде. Благовещенск, Иркутск, Хабаровск, Орел өлкәләрендә дә шәһәрне бәйрәмчә бизәү белән генә чикләнмәкчеләр.

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов исә республиканың бәйрәм чараларыннан баш тартмаячагын белдерде. «Яңа ел – иң беренче чиратта балаларыбызның бәйрәме. Нишләп әле без аларны бу шатлыктан мәхрүм итәргә тиеш? Без махсус хәрби операциягә ярдәм итүгә бик күп көч куябыз, әмма тормыш дәвам итә», – дип белдерде Президент Хөкүмәт йортында узган киңәшмәдә.

Боегудан файда юк

Күңелең тыныч булмаганда, бәйрәм рухы турында сүз дә була алмый. Татарстанның атказанган артисты Миләүшә Шәйхетдинова шул фикердә.

– Әлегә бернинди бәйрәм кәефе юк миндә. Хәтта шушы тәрәзә артындагы бозлы яңгырга да эч поша. Быел миңа 50 яшь тулды. Юбилеемны зурлап уздырмадым. Дуслар белән җыелыштык та әти исемендәге клуб ачтык. Күңел халәтем, ниндидер купшы бәйрәм ясап, уйнап-көлеп йөрерлек түгел. Шул ук вакытта мин балалар янына дәрескә йөрим. Мин аларга моңсу кәефемне күрсәтмим. Балалар белән дәрестә шаярып-көлеп, уйнап аралашам. Чөнки алар – балалар. Зурлар аларга борчуын күрсәтергә тиеш түгел. Шуңа күрә Яңа ел чаралары турында фикер йөрткәндә дә балалар турында онытмаска кирәк. Ничек кенә булса да, алар өчен бәйрәм ясарга кирәк. Алар бит Кыш бабайны, чыршыны, Яңа ел могҗизасын ел буе көтә, – дип белдерде ул «ВТ» хәбәрчесенә.

Миләүшә Шәйхетдинова сүзләренә караганда, өлешчә мобилизация башлангач, театрларга йөрүчеләр саны кимегән булган. Хәзер тамашачы акрынлап кабат яраткан спектакльләренә йөри башлаган. «Кеше бит театрга онытылырга, күңелен бушатырга килә. Соңгы арада халык күбрәк комедияләргә өстенлек бирә. Бераз онытыласы, бер утырып көләсе килә, диючеләр күп. Кайберәүләр драма әсәрләрен караганда туйганчы елап бушана», – ди ул.

Татарстанның атказанган артисты, юморист Данир Сабиров та тамашачы кәефенең бераз уңай якка үзгәрә башлавын әйтә. Өлешчә мобилизация башланган чорда халыкта концерт кайгысы түгел иде, билгеле. Әмма хәзер вазгыять бераз үзгәрә башлаган. Киресенчә, концерттан соң артист янына килеп: «Ниһаять, дөньяларны онытып, бер рәхәтләнеп көлдем», – дип рәхмәт әйтүчеләр дә күп икән.

– Яңа ел турында уйламаган әле. Тормыш дәвам итә. Бәйрәм чараларыннан баш тартып, кайгыга батып утыру да дөрес түгел. Бөек Ватан сугышы вакытында да Яңа елны үзләренчә бәйрәм иткәннәр. Халыкның кәефен, рухын күтәрү өчен, концертлар да куйганнар, Сабан туйларын да уздырганнар. Без бу очракта ничек кенә тырышсак та, берни үзгәртә алмыйбыз. Яхшыны уйлап, яхшыга юрарга кирәк. Халыкка да, егетләребезгә дә кулдан килгәнчә ярдәм итәр чак, – ди артист. Хәтерләсәгез, Данир Сабиров иҗат төркеме белән бергә мобилизациядә катнашучы егетләргә ярдәм фондына акчалата ярдәм күчереп, носилкалар тегүдә катнашканнар иде.

Кирәк кенә түгел, бик кирәк

Кыш бабай Актаныштa яшәүче 4 яшьлек Ясминәнең иң зур хыялын чынга ашырган инде. Ике атна хәбәре булмаган, мобилизациягә эләккән әтисе бу көннәрдә элемтәгә чыккан. Кызчыкның әнисе Гүзәл Шәфидуллина сүзләренә караганда, әтисе белән сөйләшкәч, Ясминәне алыштырып куйганнар диярсең – очып кына йөри, моңарчы күңелсезләнеп, гел әтисен сорап торган баланың кәефе күтәрелгән, Яңа елга да әзерләнәсе килә башлаган.

– Балаң булгач, Яңа ел кәефен теләмәсәң дә булдырырга туры килә. Сабый бу бәйрәмне көтеп ала бит. Өйне кайчан бизибез инде, дигәч, гирлянда ише кирәк-ярак алып куйдык менә. Әле күптән түгел генә районда, зурлап, Әниләр көнен уздырдылар. Анда мобилизациягә эләгүчеләрнең гаиләләрен чакырдылар. Кызым белән анда рәхәтләнеп ял итеп кайттык. Мондый чаралар да, Яңа ел чаралары да кирәк кенә түгел, бик кирәк. Безгә аз булса да онытылырга, күңелне күтәрергә ярдәм итә алар, – ди әңгәмәдәшем.

Гүзәл Шәфидуллинаның фикерен республиканың бер районындагы балалар бакчасында эшләүче тәрбияче дә куәтләде. Исемен күрсәтмәвебезне үтенде ул. Тәрбияче сүзләренә караганда, аларның төркемендәге 6 яшьлек кызга вакытыннан алда «олыгаерга» туры килгән. Әтисе махсус операциягә киткәч, тулысынча үзгәргән ул.

– Баланы алыштырып куйганнар диярсең. Әтисе киткәч, бик нык борчылды, боекты, безнең белән дә гел шул турыда гына сөйләште. Утырып елап алган чаклары да күп булды. Сабыйга карап үзегебез әзелә инде. Үзебезчә тынычландырырга тырыштык, әтиең кайта, дип әйтә килдек. Ходай рәхмәте, берничә көн элек баланың әтисе хәл белергә кайтып китте. Бик күп күчтәнәч, бүләкләр белән кайткан. Ул көнне кызыбыз бакчага кош тоткандай килеп керде. Әле дә сөенеп йөри. Шул балага авырлык килмәсен дип, 23 февральне дә, «әти» сүзен телгә алмыйча, үзебезнең малайлар арасында эстафета рәвешендә генә уздырырга дип уйлаштык. Яңа ел бәйрәмен исә елдагыча матур итеп, җиренә җиткереп үткәрәчәкбез, – дип сөйләде тәрбияче.

Мамадыш районы Көек Ерыкса урта мәктәбендә озак еллар буе балаларга белем бирүче Гөлназ Гәрәева да балаларны Яңа ел бәйрәменнән мәхрүм итмәү яклы.

– Сабый балалар Кыш бабай бүләге көтә, Яңа ел тамашасында катнашу теләге белән яна. Шулай булгач, бәйрәмнәрне алар өчен булса да уздыру кирәк. Артык пафоссыз, артык чыгымнарсыз. Бигрәк тә әтиләре мобилизациядә, хәрби операциядә булган балаларны сөендерергә кирәк. Аларның болай да күңеле китек, әтиләрен юксыналар. Әйе, быел инде, ни дисәк тә, бер борчусыз, гамьсез бәйрәм итү булмаячак. Көн саен эндәә утыргандай, балаларының исәнлеген теләүче әти-әниләр, тормыш иптәше имин була күрсен дип куркып торучы яшь ханымнар өчен генә түгел, илдәге һәркем өчен борчулы көннәр бит. Аллаһы Тәгалә илләргә иминлек насыйп итсен, – ди ул.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Белгеч фикере

Килеп туган вазгыятьтә балаларның психик халәтен саклау, Яңа елның сабыйлар тормышында тоткан урыны турында педагог-психолог, балалар психологы **Регина ФӘХРИСЛАМОВА** белән сөйләштек.

– Без Яңа ел рухына мохтаҗмы?

– Иң могҗизалы бәйрәм бу. Бигрәк тә балалар өчен. Бүгенге вазгыятьтә аеруча тансык һәм кирәк ул. Яңа ел алды шаукымы, бәйрәм алды ыгы-зыгысы, бәйрәм чаралары тормышыбыздагы киеренкелекне аз булса да киметер иде. Кеше ахыргача алҗып, эштән чыгып бетмәсен өчен, тормыштагы авыр чорда вакытлыча булса да иркен суларга мөмкинлек биргән чаралар да булырга тиеш. Аларны артык зурдан купмыйча, акчаны янга калдырып, күңел өчен генә үткәрергә дә мөмкин бит.

– Яшерен-батырын түгел, ил-көндәге вакыйгалар аркасында, үз-үзеңне кулда тоту, тынычлык саклау бик кыен. Янибыздагы балалар боларның барысын да күреп, сизеп тора. Мондый шартларда аларның психикасын ничек сакларга?

– Дөрестән дә, балалар бар нәрсәне губка кебек сеңдерә. Бала кечерәк булган саен, аның кәефе ата-анага шулкадәр бәйлерәк. Шуңа күрә баланың ныгымаган психикасын саклауны үзеңнән башларга кирәк. Ни өчен шулай уйлавыгызны, эшләвегезне анализлап, башка хаталар ясамас өчен, үзегез өчен нәтиҗәләр чыгарыгыз. Әгәр дөньядагы, илдәге куркыныч турыдан-туры сезгә, сезнең якыннарыгызга янамый икән, начар хәбәрләр җиткереп торучы тискәре мәгълүмат чараларыннан (социаль челтәрләр, гайбәт һ.б.) ерак торыгыз. Балаларыгызны да шулардан саклагыз. Дөрес, без тормышыбызны бөтен начар, тетрәндергеч әйбердән чистартып бетерә алмыйбыз. Вакыты ул түгел. Күңел төшенкелегенә бирелгән вакытлар да еш булачак. Иң мөһиме шул: ул озакка сузылмасын һәм даими күренешкә әверелмәсен. Ул очракта инде кичекмәстән психотерапевтка мөрәҗәгать итәргә кирәк.

– Балага әтисенең махсус операциягә китүен ничек аңлатырга?

– Булдыра алган кадәр дөресен сөйләргә кирәк. Чынбарлыкны бозып күрсәтүдән файда юк. Дөрес, монда баланың яшен дә исәпкә алырга кирәк. Әгәр бала бакча яшендә икән, аңа: «Әтиең – безнең яклаучыбыз, безнең герой, ул безне начар кешеләрдән сакларга китте», – дип әйтергә мөмкин. Иң мөһиме, бала әнисенең, якыннарының юкка гына борчылмавын белергә тиеш. Сез кичергән хисләрне ул да кичерә бит. Кешелекнең ни өчен бәргәләнүен аңламаса, анда невроз, психосоматикага бәйле авырулар пәйда булырга мөмкин. Мәктәптә, өлкән сыйныфта укучы балалар белән бу очракта зурларча сөйләшеп, вазгыятьнең асылын ничек бар – шулай җиткерергә кирәк. Боларны сөйләгәч, бала кызып китәргә, үпкәләргә, ярсырга мөмкин. Бу – нормаль күренеш. Аны тыярга кирәкми. Вакытында чыгарылмаган хис-тойгылар киләчәктә җитди авырулар рәвешендә бәреп чыгарга мөмкин.

– Соңгы арада, әтисе махсус операциягә киткәч, бала үзгәрде, боекты, үз эченә бикләнде ише сүзләрне еш ишетергә туры килә. Андый хәлдәге балага ничек ярдәм итәргә? Баладагы тагын нинди билгеләр сагайтырга тиеш?

– Мондый хәл күзәтелә икән, димәк, әтисенең мобилизациягә эләгүе балага бик зур психологик яра салган дигән сүз. Андый хәлдә бала уеннан тәм тапмаска, көчсезләнергә, элегрәк җиңеллек белән башкарган эшләрне дә авырдан эшли башларга, кирәк чакта да ярдәм сорамый торганга әверелергә мөмкин. Баланың аз хәрәкәтләнүе, тынгысыз йоклавы, өстән-өстән генә сулавы да шик уятырга тиеш. Балага җылы сүзегезне кызганмагыз. «Мин – синең янда», «курыкма, бар да яхшы» кебек сүзләрне ешрак кабатлагыз. Әнинең җылы кочагы да – иң яхшы дәва.

КӘЕФЕНӘ КҮРӘ КЕСӘСЕ

ЯҢА ЕЛНЫ ТЫЙНАК КЫНА ҮТКӘРЕРГӘ ТУРЫ КИЛМӘГӘЕ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Юрганыңа карап, аягыңны суз икән. Быел бигрәк тә. Бәяләр әледән-әле үзгәреп торганда, керем-чыгымнарны да, итәк-чабуларны да җыеп тотасы. Ә алда – могҗиза вәгъдә иткән Яңа ел бәйрәме. «Кешечә булсын», – дип тырыша бит күбебез. Шулай да аналитиклар Россия халкының акчаны сак тотуын искәртә. Бәйрәмнәр җитәрәк бигрәк тә. Статистикага мөрәҗәгать итеп, халык акчасын санап карарга булдык. Алдан ук искәртик: язмада саннар күп булачак.

Булганыннан канәгатьме?

Росстат агымдагы елның гыйнвар – сентябрь айларында халык керемен тикшергән. 2021 елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, вазгыять үзгәргән – кешеләрнең акчасы 12,3 процентка арткан, ди белгечләр. Ләкин реаль керем кимегән, дип тә искәртергә онытмаганнар.

Ялгыш язмадык, арткач, кимергә тиеш түгел, диярга ашыкмагыз. Реаль керем белән керем арасында аерманы аңлатыйк. Икенчесе – кешенең билгеле бер вакыт аралыгында алган акчасы ул. Пенсия, хезмәт хакы, дивидендлар, кертемнәрдән процентлар, стипендия. Башкача аны, номиналь керем, диләр. Реаль дигәне исә – төрле чорда бер үк суммага сатып алырга мөмкин булган товарлар һәм хезмәтләрнең санына тигез күрсәткеч.

Хәер, реаль кеременң кимүе фаразланган иде инде. Россиянең социаль-икътисади үсеше фаразында ук 2023–2025 елларга халыкның реаль кереме 1,6 процентка артачак, ә 2022 ел нәтиҗәләре буенча 2 процентка кимеячәк дип күтәлгән иде.

Росстат мәгълүматларын барлауны дәвам иттерик. 2022 елның гыйнвар – сентябрь айларында халыкның 1965,5 млрд сум күләмендә саклап тоткан акчасы булган. 2021 елда – 886,2 млрд сум.

Агымдагы елның гыйнвар – сентябрь аенда халыкның чыгымнары 53331,4 млрд сумга җиткән һәм узган елгы күрсәткечтән 10,3 процентка артып киткән. 45144,2 млрд сумны товар сатып алу һәм төрле хезмәтләр өчен түләүгә тотканнар. Бу да узган елның шушы ук чорына караган күрсәткечтән 10,3 процентка күбрәк.

Монысы – бу елның 9 аена караган икътисади хәл. Росстатның яңа мәгълүматлары исә ил халкының ихтыяҗларының ни дәрәҗәдә үзгәрүен күрсәтә.

Белгечләр аңлатканча, Россиядә яшәүчеләр пандемия чорындагы куллану моделенә кире кайтты. Икътисади аңлашылмаучанлык, билгесез киләчәк халыкны алкоголь, тәмәке, тәм-томнарга күбрәк акча тотарга мәҗбүр иткән. Ә мәдәни, спорт чараларына чыгымнар бермә-бер кимегән.

Сан теле белән әйткәндә, бик үк файдалы булмаган товарларга тоткан акча 18,6 процентка арткан. Уртача алганда, бу чыгымнар өч кешедән торган гаиләнең акча янчыгын 3,5 мең сумга бушата. Мәдәни һәм спорт чараларына чыгымнар 26,6 процентка кимегән. Өч кешедән торган гаилә әлеге максатлар өчен аена 1910 сум тоткан, димәк. Моннан тыш, җәмгать туклануына (китереп бирү хезмәтен дә кертеп) сарыф ителгән акча күләме 15,3 процентка арткан.

Тамак хакы

Кышның беренче аена әле кермәдек. Шуңа күрә азыктөлек бәяләренең ничек уйнавын көзге саннарга карап чагыштырып карыйк.

«АБ-Центр» белгечләре 121 товарның 2021 елдагы һәм быелгы бәяләрен тикшереп, 15енең хакы төшкәнен ачыклаган. Ә 20 товарга – 25, 92 товарга 10 процентка бәя арту күзәтелә.

Яңа ел табынына традицион салатлар өчен кирәк продукция бәясе дә әллә ни үзгәрмәс дип ышандыралар белгечләр. Сүз «Оливье» һәм «Тунлы балык» салатлары турында бара. Базарда әллә ни тетрәнүләр булмас, дип ышандыралар. Ник дигәндә, моңа ике фактор тәэсир иткән: узган елгы бәяләр күтәрелү һәм быел базарның тотрыклылануы. Әйтик, балык һәм майонез бәясе артса да, яшелчә һәм йомыркага төшкән.

Юкка-барга тотмаска!

Яңа ел җитәрәк Россия халкы әнә шул кагыйдәне исәпкә алыр, мөгаен. Моның шулай буласын аналитиклар 1,1 млн онлайн-чек тикшереп уздырган сораштыру нәтиҗәләре дә раслый инде. Белгечләр моны товарларга бәяләр төшү белән түгел, ә кешеләрнең, чыннан да, кесә ягын кайгыртуы һәм киеренке хәрби вазгыятьтә зурлап бәйрәм оештырырга теләмәүләре белән аңлата.

Әйтик, россиялеләр чыршыны 5 процентка азрак сатып алганнар һәм моның өчен акчаны 17 процентка азрак сарыф иткәннәр. Узган ел белән чагыштырганда, билгеле. Моңа өстәп мишура һәм башка вак-төяк бизәү кирәк-яракларына уртача чекның кимүен искәртә белгечләр. Күпкә түгел, 1 процентка.

– Кибетләрдә Яңа елга багышланган кирәк-яраклар инде октябрьдә үк пәйда булуга карамастан, ил халкы мондый товарларны сатып алу мәсьәләсенә сак карый һәм сайлана, кесәгә дә отышлы булганнарына өстенлек бирә, эрерәк сатып алуларга караганда арзанрак һәм кечерәкләрен хуп күрә, – дип аңлата «Чек-Индекс» белгечләре. Яңа ел атрибутикасының якынча ничә сумга төшәчәген дә исәпләп чыгарганнар – 5123 сум. Бу җыелмага ясалма чыршы, гирлянда, чыршыга элү өчен шарлар, уенчык йолдыз, мишура, шәраб һәм мандарин керә. Әлеге сан узган елгысыннан 6 процентка кимрәк булып чыга.

Шулай да, кайбер электрон сәүдә мәйданчыклары белдергәнчә, халык тәм-томга акча җәлләми. Балалар өчен Кыш бабай күчтәнәчләре турында сүз. Бу максатларга акчаны ел да күп итеп тоталар.

Башны югалтасы түгел

Финанс белгече Ләйсән Халикова бәйрәмгә кадәр дә, бәйрәмнән соң да бу киңәшне истән чыгармаска куша. Вазгыятькә бәйле рәвештә айлык керем-чыгымнар бигрәк тә сакчыл караш сорый. «Бәйрәмгә кадәр үк табын, бүләк, күңел ачу чараларына акча туплар өчен, исемлек төзеп, шул исемлек һәм суммадан чыкмаска тырышыгыз. Акчаны да мендәр астында сакларга кирәкми. Хәзер мөмкинлекләр күп. Әйтик, банкларның мобиль кушымталарында махсус хезмәтләр кушарга мөмкин. Ул ай саен кеременң бер өлешен туплау счетына күчерә барачак. Чыгымнарны алдан планлаштырсак, кыен хәлдә калмабыз», – ди ул.

Сүз дә юк, чыгымнарны көйләү, җентекләп планлаштыру ише киңәшләр кәефне төшерергә, ярсытырга да мөмкин. Нәрсәне дә булса сатып алу шатлыгын югалтмас өчен, алдан ук бюджетта бу максатларга акча бүлеп куярга була.

Финанс белгече Ольга Дайнеко да, алдан аяк киенүнең уңай яклары бар, ди. Әйтик, ташлама, төрле акция, бонуслардан файдалану. Кибетләр аларны еш оештырып тора. «Әгәр кайбер бүләкләрне 31 декабрьдә үк тапшыру ихтыяҗы юк икәнен белсәгез, аларны гыйнварда сатып алу отышлырак. Бу вакытка кибетләрдә бәяләр инде алай ук тешләмәячәк», – дигән фикердә белгеч.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Сораштыру

Рәфинә МОСТАФИНА,
хуҗабикә (Зәй районы Югары Шепкә авылы):
– Яңа елга быел халык алай зурдан кубып әзерләнмәс дип уйлыйм. Илдә барган ыгы-зыгылар бөтен кешегә дә кагыладыр ул, минемчә. Күршеңнең улы яисә ире хәрби хәрәкәтләрдә йөргәндә, ду китереп музыка акырту килешә торган гамәл түгел. Дөньяның кызыгы бетте. Бер генә теләк – тынычлык, киткән егетләр кире кайтсын. Халык ут йотып яши.
Яңа елга, гадәт буенча, каз пешерәм. Быел да шулай итәрмен, исән булсак. Салат ясармын. Җиләк-җимеш табында булыр. Артыгы кирәкми. Оныкларга бүләк әзерлисе бар. Алар бәйрәмне бик көтә.

Раилә ХӘЯЛИЕВА, журналист, 2 бала анасы:
– Мин узган елдан башлап Яңа ел матавыкларына бирелми башладым. Минем маркетологларның Яңа ел хаосына бирелмичә калганнан бер ни дә үзгәрмәде! Бәйрәм дә килде, бүләкләр дә бирештек, чыршы да бизәлде, мин дә соңгы чиккә җитеп арымаган идем. Быел да шулай итәргә исәп. Балалар, чыршы уенчыкларын үзебез ясыйбыз, диделәр. Көздән үк имән чикләвеге, каштан киптереп куйдык. Ә табын ягыннан... Яңа елда әниләргә кайтабыз бит без! Кадерле кунак булып! Шуңа табынга киткән акчаны әйтә алмыйм. Ә болай бүләкләргә, күчтәнәчләргә, балалар күңелен күрергә 10 мең сум тирәсе акча тотыла дип уйлыйм.

Ләйсән ШӘФИГУЛЛИНА, мәдәният йорты җитәкчесе (Арча районы Кышкар авылы):
– Һәр нәрсәнең кадерен аңлый башладык бугай. Артыгын кыланган булмаса да, хәзер бу хакта күбрәк уйлыйбыз. Атлаган саен «шөкер» диясе икән. Мәдәният хезмәткәре үзен дә, башкаларны да төшенкелеккә чумдырмас өчен тырыша инде ул. Бәйрәмне матур итеп үткәрү өчен көч куябыз. Өйдә дә шулай. Өч оныгыбыз бар. Кызларыбыз кияүләре белән кайта. Алар кайтышка үзебез асраган казны әзерләрмен. Мандариннар алабыз. Кызым тортлар пешерә. Пилмән бөгәбез. Малларыбыз исән-сау булсын.

«АБ-ЦЕНТР» ИСӘПЛӘП ЧЫГАРГАНЧА, БӘЯ ҮЗГӘРЕШЕ ТҮБӘНДӘГЕ РИЗЫКЛАРГА КАГЫЛА:

маргарин (+42,3%), томат консервлары (+39,9%), куертылган сөт (+36,5%), печенье (+33,7%), каһвә (+33,2%), дөге (+32,8%), туңдырылган кальмар (+32,6%), шикәр (+32,3%), туңдырылган яшелчәләр (+31,7%), тоз (+30,7%), баллы ризыклар (+29,8%), сырок (+29,8%), прәннек (+29,8%), зефир һәм пастила (+29,4%).

Бер ел эчендә бәя ягыннан арзанаю кәбестә (-44,4%), бәрәңге (-32,6%), чөгендер (-28,8%), кишер (-27,2%), помидор (-22,9%), кыяр (-20,9%), лимон (-12,0%), сарымсак (-9,8%), виноград (-8,9%), әфлисун (-8,8%), суган (-7,7%), груша (-6,3%), йомырка (-1,9%), туңдырылган тавык ите (-0,6%), дуңгыз итенә (-0,1%) кагылган.

28 ноябрь | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
10.00, 23.30 «БЕСПОКОЙНЫЙ УЧАСТОК» 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.40 «КӨМЕШ НАРАТЛЫК». Телесериал (татар телендә) 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45, 05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
16.30 «Татарлар» 12+
18.00 «Әдәби хәзинә» 6+
19.00, 20.00, 00.45 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «Реальная экономика» 12+
00.20 «Каравай». Красота национального костюма 6+
01.35 «Ватандашлар» 12+
02.00 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълумати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05 «Әниемнең җылы кочагы» 6+
15.30 «Заман көзгесе» 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
18.20, 21.25 «Сагындым... Бик сагындым сине, Туган ил!» Г.Кутуй 12+
19.15, 22.20, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
02.50 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ
05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Памяти Сергея Пускепалиса. Премьера. «ШИФР». Новые серии 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.50 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Анна Ковальчук. «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.00 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+
04.00 Анна Гарнова, Илья Шакунов, Никита Панфилов, Борис Невзоров, Екатерина Кистень. «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 16+

МАТЧ ТВ
06.00, 09.05, 12.15 Новости
06.05, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.10 Футбол. Чемпионат мира-2022. Испания – Германия. Трансляция из Катара 0+
11.15 «Оазис футбола» Прямой эфир.
12.20 Футбол. Чемпионат мира-2022. Обзор 0+
12.45 Футбол. Чемпионат мира-2022. Камерун – Сербия. Прямая трансляция из Катара
15.00, 18.00, 21.00 Катар 2022. Все на футбол! Прямой эфир.
15.45 Футбол. Чемпионат мира-2022. Южная Корея – Гана. Прямая трансляция из Катара
18.45 Футбол. Чемпионат мира-2022. Бразилия – Швейцария. Прямая трансляция из Катара
21.45 Футбол. Чемпионат мира-2022. Португалия – Уругвай. Прямая трансляция из Катара
00.45 «Один день в Катаре» 16+
01.10 Футбол. Чемпионат мира-2022. Камерун – Сербия. Трансляция из Катара 0+
03.15 Футбол. Чемпионат мира-2022. Южная Корея – Гана. Трансляция из Катара 0+
05.20 Гандбол. Чемпионат России. OLIMPBET Суперлига. Женщины. «Ростов-Дон» (Ростов-на-Дону) – «Университет» (Ижевск) 0+

НТВ
04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Сериал «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» (S) 16+
22.10 Максим Дахненко, Эдуард Флёров, Заза Чантурия. «АДМИРАЛЫ РАЙОНА» (S) 16+
00.00 Остросюжетный сериал «АДМИРАЛЫ РАЙОНА» (S) 16+
00.45 Сериал «ПРОФИЛЬ УБИЙЦЫ» 16+

ДОМАШНИЙ
06.30 6 кадров 16+
07.15 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.25 «Давай разведёмся!» 16+
10.25 «Тест на отцовство» 16+
12.35 «Понять. Простить» 16+
13.35 «Порча». Слабый пол 16+
14.05 «Знахарка» 16+
14.40 «Верну любимого» 16+
15.15 «ПЕРЕЛЁТНЫЕ ПТИЦЫ» 16+
19.00 «СЕМЕЙНЫЙ ПОРТРЕТ» 16+
22.50 «Порча». «Верный пёс». «Он предвидел смерть» 16+
23.55 «Знахарка» 16+
00.25 «Верну любимого» 16+
00.50 «Понять. Простить» 16+
01.40 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ» 16+
02.30 «Тест на отцовство» 16+
04.10 «Давай разведёмся!» 16+
05.00 6 кадров. Скетч-шоу 16+
05.05 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА
05.25 «ИЗ ПЛАМЯ И СВЕТА...» 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня. 16+
09.20, 02.35 «РОССИЯ МОЛОДАЯ». «Здравствуй, кормщик!» 12+
10.55, 18.15 «Специальный репортаж» 16+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05 «СНАЙПЕР-2. ТУНГУС». 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
17.30 «Освобождение». Док. сериал 16+
18.50 «Ледоколы войны». Док. сериал. «Ледокол Ермак». Первый в мире». Премьера! 16+
19.40 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Док. сериал. «Как делили карту мира после войны» 12+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.25 «КЛЮЧИ ОТ НЕБА» 12+
01.05 «ССОРА В ЛУКАШАХ» 12+
03.45 «Маресьев: продолжение легенды». Док. фильм 12+
04.35 «НЕ ХЛЕБОМ ЕДИНЫМ». 1-я и 2-я серии 16+

29 ноябрь | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН
05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
10.00, 23.00 «БЕСПОКОЙНЫЙ УЧАСТОК» 12+
11.00 «Азбука долголетия» 6+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «КӨМЕШ НАРАТЛЫК» (Татар телендә) 16+
13.00 «Туган җир»12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
14.45, 05.35 «Оныта алмыйм...» Ретро-концерт 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Төймә» 0+
16.00 «Ватандашлар» 12+
18.00 «Казаннан – Казанга» 12+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Туган авылым» 6+
21.00 «Соотечественники» 12+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники». Адель Кутуй. Письма в будущее 12+
00.45 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
01.10 «Башваткыч» 12+
02.00 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
04.45 «Ком сәгате» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълумати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.40, 23.05, 04.15 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
15.30 «Ватандашлар». «Урманнан сузылган җыр». Зилә Сөнгатуллина 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә... 6+
18.20, 21.25 «Йөрәктән – йөрәккә». Габделфәрт Шәрәфиев турында телеочерк 6+
19.10, 22.20, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
02.50 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+

1 КАНАЛ
05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «ШИФР». Новые серии (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.50 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1
05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Анна Ковальчук. «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.00 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+
04.00 Анна Гарнова, Илья Шакунов, Никита Панфилов, Борис Невзоров, Екатерина Кистень. «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 16+

МАТЧ ТВ
06.00, 09.05, 12.15, 14.50, 17.00 Новости
06.05, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.10, 14.55 Футбол. Чемпионат мира-2022. Бразилия – Швейцария. Трансляция из Катара 0+
11.15 «Оазис футбола» Прямой эфир.
12.20 Футбол. Чемпионат мира-2022. Обзор 0+
12.45 Футбол. Чемпионат мира-2022. Португалия – Уругвай. Трансляция из Катара 0+
17.05, 20.00 Катар 2022. Все на футбол! Прямой эфир.
17.45, 21.45 Футбол. Чемпионат мира-2022. Прямая трансляция из Катара.
00.45 «Один день в Катаре» 16+
01.10, 03.15 Футбол. Чемпионат мира-2022. Трансляция из Катара 0+
05.20 Баскетбол. Единая лига ВТБ. МБА (Москва) – «Самара» 0+

НТВ
04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» (S) 16+
22.10, 00.00 Остросюжетный сериал «АДМИРАЛЫ РАЙОНА» (S) 16+
00.45 Премьера. «Англия – Россия. Коварство без любви». «Подстава государственной важности» 16+
01.40 Сериал «ПРОФИЛЬ УБИЙЦЫ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ
06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.45 «Давай разведёмся!» 16+
09.45 «Тест на отцовство» 16+
12.00 «Понять. Простить» 16+
13.00 «Порча» Плоды греха 16+
13.30 «Знахарка» 16+
14.05 «Верну любимого» 16+
14.40 «ДЕВИЧИЙ ЛЕС» 16+
18.45 «Про здоровье» 16+
19.00 «О ЧЁМ НЕ РАССКАЖЕТ РЕКА» 16+
22.45 «Порча» «Тут кто-то есть». «Сирена» 16+
23.50 «Знахарка» 16+
00.25 «Верну любимого» 16+
00.50 «Понять. Простить» 16+
01.40 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ» 16+
02.30 «Тест на отцовство» 16+
04.10 «Давай разведёмся!» 16+
05.00 6 кадров. Скетч-шоу 16+
05.20 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА
06.00 «НЕ ХЛЕБОМ ЕДИНЫМ». 3-я серия 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 02.40 «РОССИЯ МОЛОДАЯ». Телесериал (к/ст. им. М. Горького, 1981). «Нашествие» 12+
10.45, 18.15 «Специальный репортаж» 16+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05 «ПРИВЕТ ОТ КАТЮШИ». Телесериал (Россия, 2012). 1-я – 4-я серии. 16+
15.00 Военные новости 16+
18.50 «Ледоколы войны». Док. сериал. «Ледокол «Красин». Кругосветка 885». Премьера! 16+
19.40 «Улика из прошлого» 16+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.25 «РЫСЬ» 16+
01.25 «ПО ДАННЫМ УГОЛОВНОГО РОЗЫСКА...» 12+
03.45 «Сделано в СССР». Док. сериал 12+
04.00 «АНАКОП». 1-я и 2-я серии 16+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 28 НОЯБРЬ – 4 ДЕКАБРЬ

КУЧКАР (21.03 – 20.04)
Бу атнада бетеренеп эшләмәгез. Әкрен генә селкенеп йөрүдән дә яхшысы юк. Сәбәбен дә беләчәксез һәм шуңа бик сөенәчәксез. Тик бераз соңрак...

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)
Документлар белән эшләгәндә, җыйнак, төгәл һәм сак булыгыз: хата китүе бар. Тегеннән-моннан акча эшләү тәкъдимнәре ява башлар. Матур гына планнар коруга сәбәп чыгар.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)
Хәлегезне җиңеләйтердәй ниндидер бер мөһим эшкә нокта куярсыз. Гомумән, тормышыгызның барлык өлкәләрендә уңышлар көтегез. Кыскасы, шатлык-сөенечләр белән тулы чор.

КЫСЛА (22.06 – 22.07)
Белемегез, чын осталыгыгызны күрсәтү җае чыгар. Бу кемнәргәдер ошап та бетмәс. Төрткеле сүзләргә, кимсетүле карашларга исегез китмәсен – көнчелек галәмәте генә бу.

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)
Акчалы эш эзләү өчен әйбәт чор. Һич көтелмәгән җирдән искиткеч мөмкинлекләр чыгар. Каушап-куркып кына калмаска!

КЫЗ (24.08 – 22.09)
Кыенлыкларны ерып чыктыгызмы?! Инде хәзер тынычланып калсагыз да була. Матди хәлегезнең яхшы гына түгел, ә бик нык яхшыруына өмет-ышаныч туар.

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)
Бер мәсьәләне кичекмәстән хәл кылып куярга кирәк булыр. Үзегез өчен файдалы нәтиҗә чыгаруга китерер бу. Атна урталарында әйбәт яңалыклар ишетергә насыйп булыр.

ЧАЯН (24.10 – 22.11)
Кулларыннан гөлләр тама, дигәнне ишеткәнегез бармы? Бу атнада сезнең эшләрегезгә карап сокланучылар нәкъ менә шул сүзләрне әйтер. Шәхси тормышыгызда да уңай үзгәрешләр башланыр. Кадерен белегез.

УКЧЫ (23.11 – 21.12)
Баштарак теләкләр мөмкинлекләрегезгә туры килеп җитмәс. Ләкин барысы да сез уйлаганча тәмамланыр. Сабыррак, түземлерәк булырга, аттан алда чапмаска гына кирәк.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)
Бу атнада көтелмәгән мөһим вакыйгаларны ишетми-күрми калмагыз. Аларны күз уңыннан ычкындыру үкенүгә китермәгәе. Әйбәт кенә тәкъдимнәрегез белән җитәкчегезне сокландырырсыз.

СУКОЯР (21.01 – 19.02)
Эшләрегез күбәйгәннән-күбәер, ә вакытыгыз тарайганнан-тараер. Борчылмагыз, барысы да уңышлы, саллы һәм акчалы килеп чыгар. Атна ахырында кемнәрдәндер рәхмәт һәм мактау сүзләре ишетерсез.

БАЛЫК (20.02 – 20.03)
Бәхәсләшеп утырудан мәгънә юк. Барысын да ничек бар – шулай кабул итсәгез, ак сакаллы карт булачаксыз. Сәламәтлеккә бәйле уңай үзгәрешләрне сизеп сөенәчәксез.

ЯШЕРЕН ДОШМАН

Табиблар аны замана афәте дип атый. Аннан интегүчеләр саны да елдан-ел арта бара, дип чаң суга белгечләр. Сүзебез – күпләрнең үзәгенә үткән бүсер турында.

Аның без белгән һәм белмәгән яклары хакында табиб-терапевт, невролог Эльвина ХАЛИТОВА сөйләде.

➤Умырткалар арасындагы бүсер – остеохондрозның бер «бүләге». Ул умырткалар арасында урнашкан дискның чыгып торуыннан гыйбарәт. Авырлык күтәргәндә умыртка дискының тышкы катламы кысыла һәм аның үзәгендәге төшкә баса. Гадәттә, умырткалар арасындагы диск бу авырлыкны күтәрә. Әмма җәрәхәтләнү я булмаса ялкынсыну вакытында сеңерләргә зыян килгән булса, аның төше тышка кыса, бүсер пәйда булачак.

➤Рәсми саннардан күренгәнчә, бүсердән интегүчеләр саны елдан-ел арта бара. Ни кызганыч, соңгы арада ул яшьләр арасында да ешрак күзәтелә башлады.

➤Бүсер, нигездә, умырткалыкка авырлык китерү, имгәнү, сеңерләр тартылу аркасында пәйда була. Организмның матдәләр алмашы бозылу, инфекцияле авырулар, умыртка баганасының кәкрелеге (сколиоз) аркасында да барлыкка килергә мөмкин. Офиста эшләүчеләр, машина йөртүче, йөк бушатучы, төрле эшләрдә йөрүчеләр, авыр атлетлар арасында бүсер чыгудан интегүчеләр аеруча еш очрый.

➤Көндәлек тормышыбызда умарткалыкның бил тирәсендәге өлешенә даими рәвештә авырлык төшә. Әйтик, 14 килограмм авырлыктагы әйберне күтәрергә иелгәндә, кешенең умыртка сөякләренә 150–200 килограмм чамасы авырлык төшә. Өстәвенә кешенең артык авырлыгы да булса, умырткалыкка икеләтә авырга туры килә.

shutterstock.com

БҮСЕРНЕ КИСӘТҮ ӨЧЕН ТАБИБ КИҢӘШЛӘРЕ

✱Имгәнү-җәрәхәтләнүләрдән сакланыгыз. Баскычтан төшкәндә, юлда йөргәндә, бозга кергәндә аеруча игътибарлы булыгыз. Имгәнгән очракта да «борчымый бит» дип тынычланырга ярамый. Кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Еш кына бүсер үзен озак еллар буе сиздермичә яши дә операция ясамыйча котылып булмас дәрәҗәгә җиткәч кенә ачыклана. Яшерен дошман белән бер ул.

✱Чамадан тыш артык авыр әйбер күтәрмәгез.

✱Эш белән ялны чиратлаштырырга өйрәнегез. Ныгытып эшләп алганнан соң ял итеп ала да белергә кирәк.

✱Күбрәк хәрәкәтләнегез. Йөзү, йога, пилатес – болар бар да бүсерне булдырмаска ярдәм итә. Җәяү йөрү дә файдалы. Хәтта ярты сәгать җәяү йөрү дә умырткалыкны ныгыта.

➤Бүсер үзен нинди билгеләр буенча сиздерә соң? Умырткалыкның бил өлеше бернечә сегменттан тора. Кайсы өлештә пәйда булуына бәйле рәвештә бүсернең билгеләре дә аерыла. Әйтик, аның бер өлешендә (L5-S1) бүсер пәйда булганда, оча башы сөяге (крестец) авырта, чәнти бармак ойый, аяклар шешә, аяк очларына басу авырлаша. Умырткалыкның бил тирындагы икенче бер өлешенә бүсер чыккан вакытта (L4-L5) бил сызлый, утракса нервы борчый, аякның баш бармагы ойый. Андый чакта кеше үкчәсенә баса алмый, кече йомышын башкара алмыйча да тилмерергә мөмкин. Бүсер вакытында күзәтелгән билгеләрнең чираттагы төркеме (L3-L4) аякларны күтәргәндә көчәючә бил авырту, йөргәндә тездән аяк «сынып китү», ир-атларның җенес һәм сидек юллары эшчәнлеге бозылудан гыйбарәт.

➤2–3 ай дәвамында дәваланганнан ары да файдасы булмаса, бүсердән операция ярдәмендә котылырга туры киләчәк. Бүсере арка миен, аркадагы нерв һәм кан тамырларын кыскан, аның аркасында аякларын бөгә алмый башлаган кешегә дә хәлен җиңеләйтү өчен бердәнбер алым бу.

ХӘТЕРНЕ ЯХШЫРТА

➡Үз тирәңдә яңа мохит тудырырга кирәк. Әгәр уң кулың белән язсаң, сул кулың белән язып кара. Караңгы бүлмәдә йөреп карарга кирәк. Бу алым хәтерне, игътибарны арттырыр.

➡Укуга, эшкә барганда, моңа хәтле таныш булмаган юлдан йөрергә кирәк. Баш мие эшчәнлеге дә яхшырыр, гәүдәгез дә сылу булыр.

➡Гадәти, гади сорауларга да гадәти булмаган җаваплар кайтарырга тырышыгыз. Бу алым уйлау сәләтен яхшырта.

➡Кибеткә кергәч, калькулятор кулланмаска тырышыгыз. Хәтердән генә кушу, алу баш мие эшчәнлеген яхшырта.

➡Хәтерне яхшырту өчен, белгечләр көн дә кишерне кырып, аны үсемлек мае белән ашарга киңәш итә. Ананас согы да хәтерне яхшырта. Чит телләр өйрәнгәндә лимон ашау, әфлисун согын даими куллану ярдәм итә. Авокадо, суган, чикләвек, кәбестә, креветкалар да баш мие эшчәнлеген яхшыртып, хәтерне ныгыта икән.

Үзем сынадым

Чөгендер булышты

Тамак авыртканда чөгендер төнәтмәсенең файдасын күрдем әле. Кыргычта уылган бер стакан кызыл чөгендергә бер аш кашыгы аш серкәсе салып төнәтәсең дә соңыннан шуны сыгып, тамакны чайкатасың. Бер-ике кашык йотып куйсаң да зыян юк. Ике көндә тамак авыртуын рәтләдем.

Әлфия САБИРОВА. Казан

Сәламәтлек киемнән башлана



vk.com

Кеше сәламәтлегенә аның ни белән туклануы, тормыш рәвеше генә түгел, кигән киеме дә йогынты ясый. Хатын-кызларга бу уңайдан аеруча игътибарлы булырга киңәш итә белгечләр. Ник дигәндә, матурлык артыннан куганда киелгән киемнәрнең күпчелеге сәламәтлек өчен зыянлы, ди алар.

КЫСЫП ТОРА ТОРГАН ЭЧКЕ КИЕМ

Ябык күренер өчен, кысып тора торган эчке киемнәр кияргә яратучыларга да сак булырга кирәк. Хатын-кыз гардеробындагы мондый эчке киемнәр ашкайнату системасында тайпылышлар китереп чыгарырга, кече оча сөяге тирәсендә кан әйләнешен бозарга мөмкин.

СЫЙФАТСЫЗ БИЖУТЕРИЯ

Арзанлы бижутерия еш кына көчле аллергия китереп чыгара. Тәнгә тиеп тора торган бижутерия сайлаганда билгеле маркаларга тукталу хәерлерәк. Шуңа күрә бижутерия кыйммәтлерәк булган саен ышанычлырак.

КЫСЫП ТОРГАН КОЛГОТКАЛАР

Кайчак яңа колготка кигәч, аның бераздан эчне кыса башлаганын сизгәнегез бармы? Андый чакта, тизрәк эш көне бетсен иде дә, өйгә кайтып, бу колготканы саласы иде, дип кенә уйлыйсың. Колготканың кысканын тоясы икән, ничек тә аны салу, алыштыру җаен карагыз – эчке органнарны шулкадәр озак вакыт кысып торуның һич кирәге юк.

ДЖИНСЫ-СКИННИ

Хатын-кыз өчен иң зыянлы кием шушы! Хәзер бик модада булган skinny моделен бик яратсагыз да, аннан баш тарту хәерлерәк булыр. Гел мондый джинсыдан йөрисез икән, тән кызару, эч күбү һәм кече оча сөяге әгъзаларындагы веналарда кан йөреше бозылуга әзер булыгыз. Яшүсмер чорда бик тар чалбар кию оча сөягенең тараюына һәм кысырлыкка китерергә мөмкин. Эштә көн буе утырып эшлисез икән, тыгыз тукымалы джинсы чалбар кан әйләнешен бозарга мөмкин.

БИЕК ҮКЧӘЛЕ АЯК КИЕМЕ

Биек үкчәле туфли еш кына буыннар сызлавы, умыртка баганасында бүсер чыгу кебек шактый катлаулы чирләрнең сәбәпчесе була. Шуңа күрә биек үкчәле туфлине мөмкин кадәр сирәгрәк кияргә кирәк.

ТИГЕЗ ТАБАНЛЫ АЯК КИЕМЕ

Биек үкчәләр генә аякка зыян сала дип уйласагыз, ялгышасыз – тигез табанлы аяк киемен гел кию дә шактый проблемалар китереп чыгарырга мөмкин. Ир-атларныкы кебек ботинка кияргә яратасыз икән, моның нәтиҗәсе буыннар сызлавы булып чыгу ихтималын онытмагыз. Бөтен нәрсәдәге кебек монда да алтын урталык кирәк. Үзегезне башка төрле аяк киеменнән күрергә теләмәсәгез дә, кайчакларда аз гына үкчәсе булган аяк киеменнән дә йөргәләгез.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА әзерләде

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Валентина СЕМЕНОВА

КЫШКЫ ЙОКЫГА ТАЛГАНДА

Хуҗабикәләр арасында мандарин, лимон кебек үсемлекләр үстерүчеләр байтак хәзер. Ләкин дөрес тәрбияләмәсәң, цитруслар чирләргә яки бөтенләй үк корып төшәргә генә тора. Аларны көзге-кышкы чорда ничек сакларга? Бакчачы, гөлләр үстерүче Эльза ХӨСӘЕНОВАдан гөлләрне суык чорда карау серләрен белештек.

Гөрләп үсеп утырган гөл көзен кинәт кенә чирләшкәгә әйләнергә мөмкин. Киресенчә, көз-кышны әйбәт кенә чыгып, язын бөтен яфракларын коеп бетерергә дә күп сорап тормый. Кышын дөрес карамаганга шулай бу, ди Эльза ханым. Шул сәбәпле үсемлекнең иммунитеты көчсезләнә икән.

Эльза ханым әйтүенчә, цитрус гөлләрен ике ысул белән кышлатырга мөмкин.

Беренчесе – салкын ысул. Гөл чүлмәген салкын тәрәзә төбенә, пыяласына терәтеп үк диярлек куярга кирәк. Үсемлек инде агачка әйләнеп, зур үскән очракта, шәһәр җирендә җылытылган балкон-лоджиягә чыгарып кую әйбәт. Ләкин цитрусның тамырларына гына түгел, сабаклары-яфракларына да суык булу кирәк, юкса ул әле һаман, кирәкмәгәнгә көчен бетереп, йоклыйсы урынга үсеп утырачак. Шуңа күрә аңа күп яктылык, кояш нурлары төшеп тормау таләп ителә. Ул гына да түгел әле: чүлмәк туфрагындагы температура ябалдашы тирәсендәге температурага караганда 1–3 градуска салкынрак булганда гына, үсемлек кышны исән-имин уздырачак. Ә суны бик аз сибәргә кирәк. Кайберәүләр гөлнең яфраклары коелуын күреп, дым җитми ахры, дип, күбрәк сибә башлыйлар. Бу очракта яфрак коелу суны аз сибүгә түгел, ә туфракның тиешледән җылырак булуына бәйле. Шуңа күрә аны суыту чарасын күрергә кирәк, ди бакчачы.

Икенчесе – җылы ысул. Суыкта кышлатуны авырга санаучылар җылы ысулны да куллана ала. Тик бу очракта тәрәзә төбе җылы булырга (+18...+20 градус чамасы – чүлмәк төбенә җылырак әйбер җәяргә кирәк), шул ук вакытта кояш нурлары турыдан-туры төшеп тормаска һәм тәрәзә астындагы батареядан җылы нык күтәрелмәскә тиеш. Мондый ысул белән кышлатканда, гөл суны күбрәк таләп итә. Аны сипмәскә, ә ешрак бөркеп торырга кирәк. Ләкин мандарин, лимоннарны салкын ысул белән кышлату әйбәтрәк. Мәшәкате күбрәк булса да, гөл әйбәтрәк үсәчәк һәм җимешләрен дә күбрәк бирәчәк икән.

vk.com

Сүз уңаеннан, кышны уздыру өчен өйгә алып керелеп куелган хризантема, гортензияише чәчәкләрнең дә салкын ысулны яратуын әйтеп үтик.

Кышын йокы халәтендәге бу гөлләрне ашламыйлар. Ә менә йокламаучылар, аеруча хлорофитум, спатифиллум кебек кыяклы гөлләр кышын да тукландыруны таләп итә. Эльза Хөсәенова гөлләрне гәрәбә кислотасы (янтарная кислота – даруханәләрдә арзан гына бәядән сатыла) белән тукландыра икән. Бик гади: бүлмә температурасындагы 2 литр суга 2 г кислота салып, эремә ясый. Атнага бер тапкыр 50шәр мл күләмендә гөлнең төбенә сибә һәм тагын бер тапкыр бөркегечтән бөрки. Нәтиҗәдә гөлләрнең яфраклары кышын да ямь-яшел утыра, спатифиллум кебекләре әле чәчәк тә ата икән.

Тәмле булсын!

«Наполеон» торты

Фәния МИСАЛИМОВА рецепты

Вакыт тар булганда, «Наполеон»ны катлы камырдан түгел, ә каймактан гына изеп ясыйм.

Кирәк: *1 стакан каймак, 2 стакан он, 250 г маргарин, 500 мл сөт, 4 данә йомырка, 200 г шикәр комы, 40 г атланмай, 2 чеметем ванилин.*

2 стакан онга маргарин салып, вак бөртекләр ясалганчы, кул белән уабыз. Каймак өстәп, камыр басабыз. Камырны пленкага төреп, 1 сәгатькә суыткычка алып куябыз.

Крем өчен йомыркаларга шикәр комы, он һәм ванилин кушып күпертәбез. Сөт өстәп, тагын бер тапкыр күпертеп алабыз да утка куябыз. Болгатып торабыз. Кайнап чыгар алдыннан гына атланмай салып, эрегәч, куерганчы болгатабыз. Кремны пленка белән яхшылап төрәбез (кибеп китмәсен өчен, пленка крем өстенә тиеп торырга тиеш). Суытабыз.

Камырны берничә өлешкә бүләбез. Һәркайсын бик юка итеп җәябез. Чәнечке белән берничә урыннан чәнчеп алабыз.

Газ мичен 220 градуска кадәр җылытабыз. Һәрбер җәемне, алтынсу төскә кергәнче, 6–8 минут пешерәбез. Берсен озаграк – 9–10 минут тоткач, ваклыйбыз. Һәр җәемгә крем сылап, катлы торт ясыйбыз. Соңыннан тортның өстен, кырыйларын да «кремлап», валчыкны сибәбез. Төнгә суыткычка куеп калдырабыз.

Исеңдә тот!

КРЕДИТ ТАРИХЫ: АНЫ НИЧЕК ТИКШЕРЕРГӘ?

Кайвакыт әллә нинди сюрпризлар ясарга мөмкин ул. Ялгыш мәгълүматлар, ябылмаган карталар, тфү-тфү, безнең исемгә кемнеңдер кредит алуы... Шуңа күрә белгечләр аны ким дигәндә елына ике тапкыр тикшерергә киңәш итә. Һәм ул бушлай икән.

Дәүләт хезмәтләре порталында теркәлүчеләр бу эшне бик җиңел башкара. Моның өчен нибары өч адым ясарга кирәк.

1 Кредит тарихларының үзәк каталогыннан (ЦККИ) Кредит тарихлары бюросы (БКИ) турында мәгълүматлар алу (кредитларны тикшерү рәсми тел белән шулай бик авыр әйтелә) өчен, теләсә кайсы браузерга кереп, «Запрос ЦККИ о БКИ» дип язып, эзләүгә басарга.

2 Эзләү нәтиҗәсеннән Gosuslugi.ru сайтын сайларга. Порталга кучәргә. Аккаунтка керүгә, кирәкле сәхифә автомат рәвештә ачыла. Экранда «Получение информации о хранении вашей кредитной истории» дигән җөмлә чыга. «Начать» төймәсенә басып, система «әйткән»нәрне эшләргә. «Отправить запрос» төймәсенә басып тәгәлләргә. Запрос берничә минуттан бер тәүлеккә кадәр эшкәртелә. Нәтиҗәсе шәхси кабинетка килә. Анда сезнең кредитлар турында мәгълүматлардан торган БКИ исемлеге (ул беркайчан да бер генә булмый – иминлек өчен шулай кирәк), аларның мәгълүматлары һәм сайт адресы күрсәтелә.

3 Һәрбер БКИ сайтына күчеп, кредит хисабын сорарга һәм аны җентекләп тикшерергә.

Дәүләт хезмәтләре порталында теркәлмәүчеләр исә кредит тарихын теләсә кайсы БКИ аша соратып алырга мөмкин. Ләкин бу гади генә эш түгел. Запрос формасын тутырып, бастырып чыгарырга, нотариуста раслатып, почта аша юлларга кирәк. Әлеге ысул белән кредит тарихын белү өчен 300 сум түләргә кирәк. Моңа тагын нотариуста раслау, почта аша җибәрү чыгымнары өстәлә.

Матур бул!

КЫШКА ФАЙДАЛЫ БИТЛЕК

Матурлыкны саклау өчен, сезонлы яшелчә һәм җимешләр ярдәмгә килергә мөмкин.

✓ 3 аш кашыгы изелгән (пешкән) кабакка 2 аш кашыгы әфлисун (мандарин, алма, ананас булса да ярый) согы һәм 1 аш кашыгы каймак салып болгатабыз. Катнашманы биткә сылап, 15 минут тотабыз. Нәтиҗәсе шундук күренәчәк!

✓ 4 аш кашыгы бәрәңге боламыгына (сөт белән) 1 аш кашыгы тозлы кәбестә (яки 1 чәй кашыгы кәрән, торма согы), 1 аш кашыгы бал кушып болгатабыз. Катнашманы биткә сылап, 10 минут тотабыз. Бит тиресе матураеп, шомарып китәчәк.

✓ Ирен ярылса, аңа кишер яки чөгендер согы кушылган сөт өсте (сливки) сыларга мөмкин.

Белеп тор!

Тырнак буяу сере

Ниндидер мөһим чара алдыннан маникюрны алыштырырга вакыт тапмасагыз, искесен яңартып җибәрегез. Тырнак очларында лак купса, шул урыннан башка төстәге лак белән тырнакның буеннан-буенча нечкә генә сызык сызыгыз. Шул рәвешле маникюрның купкан урыны капланып калачак. Ә инде агарган аскы ярымтүгәрәген яшерү өчен, тырнакны төссез лак белән буяп, ак өлешенә бер чеметем җемелдәвек ябыштырып куярга мөмкин. Маникюр шундук яңарып китәчәк!

ӘНИ БУЛУНЫҢ ӘҖЕРЕ ДӘ, БУРЫЧЫ ДА КҮП

Ноябрьнең соңгы якшәмбесе Әниләр көне буларак билгеләп үтелә. Әлбәттә, кадерле кешеләребезгә хөрмәт-кадерне бу көндә генә күрсәтергә кирәк дигән сүз түгел бу. Хак динебез дә газизләребезгә карата мөнәсәбәтнең көн дә яхшы, күркәм булырга тиешлеген искәртеп тора.

Исламда ана хакы, аналарның һәм балаларның бурычлары турында Алмаз хәзрәт ГАЛИМҖАНОВтан сораштык.

pinterest.com

:: Ислам динендә әни хакы турында ни диелә?

– Бисмилләһир-рахмәнир-рахим! Ислам динендә аналарның хакы зур. Корьәни Кәримдә: «Әгәр дә әти-әниең олы яшькә җитсә, аларга «уф» дип тә әйтмә», – диелә. Олыгайган кешенең тормышка карашы да үзгәрә. Аңа күп нәрсәләр аңлашылып та бетмәскә мөмкин. Шушы вакытта: «Уф, арыдым инде синнән», – дияргә ярамый. Ата-анага хәерле мөнәсәбәт күрсәтү – иң зур нигъмәтләрнең берсе булып тора. Пәйгамбәребездән (с.г.в.): «Кемгә хәер-хөрмәт күрсәтергә?» – дип сорагач, ул: «Әнигә», – дип җавап биргән. Тагын бер сорагач, тагын бер тапкыр: «Әнигә», – дигән. Тагын бер сорагач та шулай дигән. Дүртенче тапкыр сорагач: «Әтигә», – дигән. Алар – иң хәерле затлар булып тора. Ата-аналарны кимсетү – җинаять, гөнаһ.

:: Ана хакын хакламасаң, нинди җәза була?

– Бер кеше үлә алмый ята икән. Пәйгамбәребез (с.г.в.) моның янына килгәч: «Бу кешенең әнисе бармы?» – дип сорый. «Бар», – диләр. Әнисен алып килергә куша. Пәйгамбәребез (с.г.в.) бу әнигә: «Улыңа рәнҗедеңме әллә?» – дигән сорау бирә. «Әйе, улым, өйләнгәнче, миңа кадер-хөрмәт күрсәтә иде, өйләнгәч, хатын ягына авышып, мине онытты, шуңа үпкәләдем», – ди бу ана. Пәйгамбәребез (с.г.в.) исә: «Алайса, бу адәмне җәзага тартыгыз», – ди. Әлбәттә, ул аны бу ананың күңеле йомшарсын өчен генә әйтә. Теге кешенең әнисе исә: «Юк, юк, җәзаламагыз, мин аны гафу иттем», – дип каршы чыга. Шуннан соң гына үләргә яткан кеше, кәлимәләрен әйтеп, мәрхүм була. Бу кыйсса да аналарның никадәр олы дәрәҗәдә икәнен күрсәтә. Ата-анасын кадерләмәгән кешене ачы газаплар көтә. Аллаһы Тәгалә аны бу дөньяда ук сыный башлый. Каргыш-рәнҗеш төшәргә мөмкин.

:: Ана ризалыгына ирешү өчен ни эшләргә?

– Әни кушкан гамәлләрне, үтенечләрне үтәргә тырышырга кирәк. Әлбәттә, гөнаһка этәрми торганнарын. Әнине олыгайган көнендә карарга кирәк. Аллаһы Тәгалә: «Ата-анаң өчен сора», – ди. Әти-әнинең кадерен, кызганыч, үзебез әти-әни булгач яисә кадерлеләребез бу дөньядан киткәч кенә аңлыйбыз. Күпләр моны үз башыннан кичергәндер... Яшьләр арасында ата-анасына теләсә нәрсә кычкырып, җикеренеп, үзләрен өстен куеп сөйләшүчеләр байтак хәзер. Без алар белмәгән нәрсәнедер беләбез икән, бу әле безнең акыллы икәнне аңлатмый бит. Нәкъ менә аларның тырышлыгы белән без бу кадәр интеллектка ия. Шуны онытмаска иде. Әти-әни ризалыгын алу – безнең өчен иң хәерле гамәл.

:: Кайчагында кияүгә чыккан кызларны хәләл җефетләре әниләре ягына кайтармый. Моңа өстәп, каенанасына буйсындырып яшәтә. Каенана үз анаң була алмый бит инде ул... Мондый очракта нишләргә?

– Әлбәттә, бу дөрес гамәл түгел. Әмма һәр очракны аерым карарга кирәк.

Кайвакыт йә егетнең, йә кызның ата-анасы, якын туганнары, яңа гаиләнең тормышына кысылып, барысын да катлауландыра. Яңа өйләнешкәннәрнең әле тәҗрибәсе булмый бит. Башкаларның уртаклашасы киләдер. Без, никахлар укыганда да: «Балаларны өйләндерү белән, әти-әнинең бурычы тәмамлана», – дип кисәтәбез. Алар инде – аерым гаилә. Хәерле киңәшләре белән ярдәмләшә генә алалар. Бүтәнчә кысылырга тиеш түгелләр. Кызганыч, шундый хәлләр була: кыз ягыннан да, егет ягыннан да әти-әниләр кысылып, мөнәсәбәтләр чәлпәрәмә килә.

Урталык табарга кирәк, билгеле. Хатын-кызга, әлбәттә, кияүгә чыккач, иренә буйсыну хәерле. Әмма ир-ат та хатынының әнисе белән сөйләшүенә, очрашуына каршы килергә тиеш түгел. Татулыкта, хөрмәтләшеп яшәүгә ни җитә! Аллаһы Тәгалә дә: «Кардәш булган халәттә яшәгез», – ди.

:: «Ана – бөек исем. Нәрсә җитә ана булуга!» дигән шигырь юллары бар. Кызганыч, әни булырга ашкынып торган гүзәл затлар гына кими...

– Әни булуның әҗере дә, бурычлары да күп. Һәрбер тулгак, һәр йокламый калган төнге йокы, күкрәк сөтенең һәр тамчысы – хатын-кызның кече гөнаһларын ярлыкауга, тормышка бәрәкәт иңүгә бер сәбәп. Кыямәт көнендә, мөмкинлеге булып та, үзе теләп бала алып кайтмый калган хатын-кыз бәби алып кайткан хатын-кыздан түбәнрәк дәрәҗәдә була. Бала ул – җәннәт нигъмәте. Баладан җәннәт исе килә, диләр. Иң хәерлесе – кияүгә чыгу һәм бәби алып кайту. Кызларга да бу теләктән кайтмаска киңәш итәр идем. Аллаһы Тәгалә шундый мөмкинлек биргән икән, аннан файдаланырга кирәк.

:: Тапкан ана – анамы, баккан анамы? Кайбер очракта баланы дөньяга китергән хатын-кызны «әни» дип әйтерлек тә булмый бит...

– Бу очракта, әлбәттә, баланың тапкан анага да бурычы кала. Ул бит аны 9 ай буе карынында йөрткән, тулгак тотып, дөньяга китергән... Карап үстергән әнисенә дә бурычлы ул. Әле бит «сөт әнисе» дигән төшенчә дә бар. Баланы әнисеннән тыш бүтән хатын-кыз имезгән икән, ул аңа да кадер-хөрмәт күрсәтергә тиеш. Әлбәттә, карап үстергән ананың билгеле бер олы хакы, дәрәҗәсе була. Нинди генә булса да, тапкан анаң анаң булып кала.

Декабрь аенда намаз вакытлары

Көн саны	Көн исеме	Таң беленә башлый	Кояш чыга	Икенде намазы	Ахшам намазы	Ястү намазы
1	Пәнҗ	05:31	07:48	13:27	15:16	17:10
2	Җом	05:32	07:50	13:27	15:15	17:10
3	Шим	05:33	07:51	13:26	15:14	17:09
4	Якш	05:35	07:53	13:25	15:13	17:09
5	Дүш	05:36	07:54	13:25	15:13	17:09
6	Сиш	05:37	07:56	13:24	15:12	17:08
7	Чәрш	05:38	07:57	13:24	15:11	17:08
8	Пәнҗ	05:39	07:58	13:23	15:11	17:08
9	Җом	05:40	08:00	13:23	15:11	17:08
10	Шим	05:41	08:01	13:23	15:10	17:08
11	Якш	05:42	08:02	13:23	15:10	17:08
12	Дүш	05:43	08:03	13:23	15:10	17:08
13	Сиш	05:44	08:04	13:23	15:10	17:08
14	Чәрш	05:45	08:05	13:23	15:10	17:08
15	Пәнҗ	05:46	08:06	13:23	15:10	17:08
16	Җом	05:46	08:07	13:23	15:10	17:08
17	Шим	05:47	08:08	13:23	15:10	17:08
18	Якш	05:48	08:09	13:23	15:10	17:09
19	Дүш	05:49	08:10	13:24	15:10	17:09
20	Сиш	05:49	08:10	13:24	15:11	17:09
21	Чәрш	05:50	08:11	13:24	15:11	17:10
22	Пәнҗ	05:50	08:11	13:25	15:12	17:10
23	Җом	05:51	08:12	13:25	15:12	17:11
24	Шим	05:51	08:12	13:26	15:13	17:11
25	Якш	05:51	08:12	13:27	15:14	17:12
26	Дүш	05:52	08:13	13:27	15:14	17:13
27	Сиш	05:52	08:13	13:28	15:15	17:14
28	Чәрш	05:52	08:13	13:29	15:16	17:14
29	Пәнҗ	05:52	08:13	13:30	15:17	17:15
30	Җом	05:53	08:13	13:31	15:18	17:16
31	Шим	05:53	08:13	13:32	15:19	17:17

Искәрмә: өйлә намазы – 12.00 сәгатьтә.

Хикмәтле сүз

Аллаһы Тәгалә карак кешене ләгънәт кыла, җеп кенә урлаган булса да.
Гыйлем бирегез, җиңеләйтегез, авырайтмагыз, куандырыгыз, нәфрәтләндермәгез.
Әгәр ачуыгыз чыкса, дәшмәгез.
Кешенең йөрәге аны яратучыларның мәхәббәтеннән ясалган.
Адәм баласының таянычы – акылы. Акылы булмаган кешенең дине дә юк.

Гыйбрәт өчен

«ӘНИ ДОГАСЫ САКЛАДЫ»



Борын-борын заманда бер сугышчы булган. Ул сугыш мәйданына бер дә әзерлексез, саклану чараларысыз чыга, ди. Әйтәләр, әйтәләр – ишетми. Ә көннәрдән беркөнне башына киеп, калкан алып чыга. Иптәшләре: «Ник киендең?» – дип аптырый икән. «Минем әни үлде, – дигән сугышчы. – Моңа кадәр мине әнинең догалары саклады. Инде әни өчен дә, әни өйрәтеп калдырган догаларны үзем өчен дә кылам».

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА әзерләде

ӘЛЕГЕ БИТТӘ КОРЪӘН АЯТЬЛӘРЕ, ДОГАЛАР БУЛУ СӘБӘПЛЕ, КАДЕРСЕЗЛӘМӘВЕГЕЗ СОРАЛА

Лилия
ГЫЙМАЗОВА

Ә син таныйсыңмы?

Уенның чираттагысын тәкъдим итәбез. Шартлар шул ук. Тулы, дөрес итеп беренче җавап бирүчегә бездән бүләк – телефонына 100 сум! Җавапларны +7 (904) 718-14-69 номерына юллагыз.

*Газетабызның узган санында чыккан җырчы һәм җырларны беренчеләрдән булып Казаннан **Алсу Шакирова** танып алды. Афәрин! Бүләк – хуҗасында. Ә рәсемнәр астына без Алмаз Мирзаянов башкаруындагы «Түзә йөрәк сагышка», Илгиз Мөхетдинов репертуарыннан «Бик бәхетле булыр идек без», Эльвира Хамматованың «Яшьли сөйгән ярым» җырларын яшергән идек.*

Әлеге җыр – яшьлек белән хушлашу турында. Аны башкаручы борчылырга ашыкмый, чөнки күңелендәге дәрте нәкъ унсигездәге кебек икән.

Җырчы яраларына, йөрәгенә тимәүләрен үтенә. Җаннарны өшетердәй салкын җилләр кертмик араларга, ди.

Җырчы, иң кадерле кешеләребезнең җаннары әрнемәсен иде, ди. Сәгатьләрне санап көтәләр, шуңа да янарына кайтырга өнди ул.

АНА КҮҢЕЛЕ – БАЛАДА...

«Дөнья ямьле булсын өчен, әни кирәк...» Ноябрьнең соңгы якшәмбесендә дөньядагы иң җылы бәйрәм – Әниләр көне билгеләп үтелә. Бүгенге сәхифәбезнең кунаклары да – әниләр. Аларның исемнәре барыбызга да таныш. Балаларына вакытлары калмаган чакларда нинди хисләр кичерә алар? Буш вакытларын ничек уздырырга яраталар?

«ҮЗЕҢНЕ ГАЕПЛӘМӘСӘҢ, БАЛАГА ДА ҖИҢЕЛРӘК»

Ләйсән ГЫЙМАЕВА, җырчы, өч кыз әнисе:

– Нинди генә һөнәр иясе булсаң да, бала тәрбияләү белән бергәттән нинди дә булса эштә эшләү зур тырышлык һәм сабырлык сорый. Барына да җитешәсе, җиренә җиткереп эшлисе килә бит инде. Үземнең балачагымны яхшы хәтерлим. Безнең әни укытучы булып эшләде. Иртәдән кичкә кадәр мәктәптә була торган иде. Әле мәктәптән кайткач та, бер кочак дәфтәр тикшереп утырганы хәтердә. Ә менә безнең белән уйнап утырган чакларын бер дә хәтерләмим. Әле бит, авыл җире булгач, мал-туары бар, аны карарга кирәк. Ләкин без моның кыенлыгын сизмәдек, шулай тиеш дип кабул иттек. Аннан күреп, үзебез дә аның шикелле әни булырга өйрәндек. Гел китаптагыча булмаса да, тырышабыз инде. Үз-үзеңне гаепләп, мин балаларыма тиешле игътибар бирәмме икән, дип уйламыйча гына тәрбияләсәң, үзеңә дә, балаңа да җиңелрәк булачак. Андый чакта балаң да үзен игътибардан мәхрүм калган итеп тоймаячак, минемчә.

«КЫЗЛАРЫМА КАРЫЙМ ДА ЕЛЫЙМ...»

Резеда МИҢНЕГУЛОВА, блогер, ике кыз әнисе:

– Блогер әни булу җиңел димәс идем. Балаларга тиешле игътибарны биреп бетереп булмый. Югыйсә син өйдә, балалар белән бит инде, ләкин уйларың, хисләрең башка җирдә. Чөнки син ничек тә булса «охват»ларны күтәрү, ни дә булса төшерү турында уйлыйсың, йә булмаса ни дә булса төшерәсең. Адәм баласы шундый бит инде ул: аңа гел вакыт җитми. Мин дә шулай, вакытым булмаганда, ачуланып кычкырырга да мөмкинмен. Андый чакта кызганып та куям үзләрен. Йоклаган чакларында яннарына килеп утырып, кызларыма карыйм да елыйм кайвакыт. Аннары үземне тынычландырырга тырышып, без үскәндә дә әниләрнең вакыты җитми иде, дип уйлап куям. Бер уйласаң, шулай бит инде. Алар – көне буе эштә, ә без йә урамда, йә балалар бакчасында, йә әби-бабай янында идек.

Кызларым белән буш вакытыбызны саф һавада уздырырга яратабыз. Ашыкмый гына, сөйләшә-сөйләшә, урман-паркларда йөрибез.

«БЫЕЛ БИГРӘК ТӘ АВЫР БУЛДЫ...»

Айсылу ЛЕРОН, журналист, өч бала әнисе:

– Миңа калса, хәзерге заманда өйдә хуҗабикә булып утырган әниләрнең генә балаларына вакыты җитәдер. Кайда гына эшләсә дә, вакытының күп өлешен эштә уздыручы әниләргә бик авыр инде ул. Үземә дә шулай. Быел – бигрәк тә. Фатир алып, ремонт эшләре белән йөргәч, бу елыбыз бик ыгы-зыгылы булды. Чыктык та киттек, чыктык та киттек. Балаларыбызга игътибар да, вакыт та бик аз калды. Шөкер, үзләре аңлады тагын. Әби-бабасы, апалары белән уздырган вакытлары үзенә күрә бер «компенсация» булгандыр инде. Инде хәзер, яңа фатирга күченеп, безнең бертуктаусыз чапкынлавыбызның нәтиҗәсен күргәч, үпкәләгән булсалар, аңлаганнардыр дип ышанам.

Эштән арына алмасак та, гаилә белән ни дә булса эшләргә тырышабыз. Тиздән Яңа ел бәйрәмнәре җитә, зарыгып, каникулны көтәбез. Мөмкинлек чыкканда, театрга йөрибез. Моның тәмен белә алар. Кыскасы, ничек тә «бет кояр» өчен мөмкинлек табарга кирәк.

«ҮЗ КАНАТЫМ АСТЫНДА САКЛЫЙМ ШИКЕЛЛЕ...»

Альбина ГАЙЗУЛЛИНА, Кариев театры артисты, ике ул әнисе:

– Яшь тамашачы театрында эшләгәч, миңа барыбер җиңелрәк кебек. Без болай да көне буе балалар белән. Шул балалардан алган көч, дәрт, энергия белән үз балаларым янына кайтам. Билгеле, элек, улларым кечкенә чакта авыррак иде. Хәзер инде үстеләр, үзләрен үзләре карый башладылар. Шулай да, безнең гаиләдә электән килә торган бер гадәт бар. Кичке спектакльдән кайткач, өстәл янына түгәрәкләнеп утырабыз да сөйләшәбез. Алар миңа көннәрен ничек уздыруларын, ниләр эшләүләрен сөйли. Аннан соң, мин һәр иртә саен улларымны уятканда, «Бисмилла»мны әйтеп, башларыннан сыпырам да, үзләренә ишетелерлек итеп, теләкләр телим. Шулай иткәч, яннарында булмасам да, көн буе үз канатым астында саклап торамдыр шикелле.

Вакыт булганда, җыелышып, йә авылга кайтабыз, йә Казандагы дәү әти һәм дәү әниләре янына барабыз. Форсаттан файдаланып, ике әниемә дә рәхмәтемне җиткерим әле. Балаларыма вакытым җитә, дисәм дә, аларның ярдәменнән башка бик авыр булыр иде.

30 ноябрь | Чәршәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
10.00, 23.30 «БЕСПОКОЙНЫЙ УЧАСТОК» 12+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.40 «КӨМЕШ НАРАТЛЫК» (Татар телендә) 16+
13.00, 01.10 «Жырлыйк әле!» 6+
14.00 «Если хочешь быть здоровым» 12+
14.15 «Мой формат» 12+
14.45, 05.35 «Оныта алмыйм…» Ретро-концерт 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Бергәләп өйрәник» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
18.00 «Таяну ноктасы» 16+
19.00 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак барс» – «Сибирь». Прямая трансляция 6+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «Спортивная среда» 6+
00.20 «Соотечественники». Александр Славутский. Человек – театр 12+
00.45 «Каравай». Мастер народных промыслов 6+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Кәмит Җавит» 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.40 «Әй, язмыш, язмыш…» (субтитрлы) 12+
09.40 «Ачыктан-ачык» 12+
10.40 «Туган авылым» 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 20.00, 04.15 «Таяну ноктасы» 16+
12.35 «Ватандашлар». Роберт Миңнуллин. Родом из детства 6+
15.30, 00.15 «Яшьләр тукталышы» 12+
16.00 «Әдәби хәзинә» 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
18.20, 21.25 «Йөрәктән – йөрәккә». (субтитрлы) 6+
Наил Әюпов турында телеочерк 6+
19.15, 22.20, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.30 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
23.05 «Әй, язмыш, язмыш…» (субтитрлы) 12+
02.50 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш…» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «ШИФР». Новые серии (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.50 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?». Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Анна Ковальчук. «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.00 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+
04.00 Анна Горнова, Илья Шакунов, Никита Панфилов, Борис Невзоров, Екатерина Кистень. «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.05, 12.15, 14.50, 17.00 Новости
06.05, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.10, 12.45, 14.55, 01.10, 03.15 Футбол. Чемпионат мира-2022. Трансляция из Катара 0+
11.15 «Оазис футбола». Прямой эфир
12.20 Футбол. Чемпионат мира-2022. Обзор 0+
17.05, 20.00 Катар 2022. Все на футбол! Прямой эфир
17.45, 21.45 Футбол. Чемпионат мира-2022. Прямая трансляция из Катара
00.45 «Один день в Катаре» 16+
05.20 Баскетбол. PARI Чемпионат России – Премьер-лига. Женщины. УГМК (Екатеринбург) – «Динамо» (Курск) 0+

НТВ

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Сериал «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» (S) 16+
22.10, 00.00 Остросюжетный сериал «АДМИРАЛЫ РАЙОНА» (S) 16+
00.45 Премьера. «Англия – Россия. Коварство без любви». «В поисках пятой колонны» 16+
01.40 Сериал «ПРОФИЛЬ УБИЙЦЫ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.10 «Давай разведёмся!» 16+
10.10 «Тест на отцовство» 16+
12.25 «Понять. Простить» 16+
13.30 «Порча» Воспоминание из будущего 16+
14.00 «Знахарка» 16+
14.35 «Верну любимого» 16+
15.05 «СЕМЕЙНЫЙ ПОРТРЕТ» 16+
19.00 «МОЖЕШЬ МНЕ ВЕРИТЬ» 16+
22.55 «Порча» «Двойник». «Новый жилец» 16+
00.00 «Знахарка» 16+
00.30 «Верну любимого» 16+
00.55 «Понять. Простить» 16+
01.45 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ» 16+
02.35 «Тест на отцовство» 16+
04.15 «Давай разведёмся!» 16+
05.05 6 кадров. Скетч-шоу 16+
05.10 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.25 «АНАКОП». 3-я и 4-я серии 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 02.20 «РОССИЯ МОЛОДАЯ». «ПРАВДА ПРОТИВ КРИВДЫ» 12+
10.55, 18.15 «Специальный репортаж» 16+
11.20, 21.15 «Открытый эфир». Ток-шоу 16+
13.20, 15.05 «ЧЕРНЫЕ ВОЛКИ». 1-я – 4-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.50 «Ледоколы войны». Док. сериал. «Ледокол «Иосиф Сталин». Мировой рекорд» 16+
19.40 «Секретные материалы». Док. сериал 16+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.25 «БЕЗ ПРАВА НА ПРОВАЛ» 12+
01.05 «КЛЮЧИ ОТ НЕБА» 12+
03.35 «РЫСЬ» 16+
05.10 «Живые строки войны». Док. фильм 12+

1 декабрь | Пәнҗешәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
10.00 «БЕСПОКОЙНЫЙ УЧАСТОК» 12+
11.00 «Каравай» 6+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «КӨМЕШ НАРАТЛЫК» (Татар телендә) 16+
13.00 «Кәмит Җавит». Юмористик тапшыру 16+
14.00 «Туган авылым» 6+
14.15 «Рыцари вечности» 12+
14.45, 05.35 «Оныта алмыйм…» Ретро-концерт 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Шома бас» һәм «Алты хәреф» 0+
16.00 «Казаннан – Казанга» 12+
18.00 «Юлчы» 6+
19.00, 20.00 «Точка опоры» 16+
21.00 «Ватандашлар» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники». Лилиана Терегулова. Делай добро и бросай в воду 12+
00.40 «Каравай». Хобби, которое приносит счастье 6+
01.05 «Кәмит Җавит» 16+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Башваткыч» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.40, 23.05, 04.15 «Кәмит Җавит». Юмористик тапшыру 16+
09.40 «Кунак БиТ Шоу» 12+
10.40 «Туган авылым» 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 Яңалыклар 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05 «Таяну ноктасы» 16+
12.35 «Ватандашлар». Ык елгасының акиятн ярларында 6+
15.30, 00.15 «Халкым минем» 12+
16.00 «Әдәби хәзинә» 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
18.20 «Яктырак йолдыз янады». Мөхәммәт Мәһдиев иҗатына багышланган әдәби-музыкаль кичә 6+
20.00 «Tatarstan today. Деньяга ачык» (субтитрлы) 12+
20.30, 22.20, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
21.25 Р.Харис. «СӘЙДӘШ ЯРЫ». Телефильм 12+
02.50 «Караоке татарча» 6+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш…» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «ШИФР». Новые серии (S) 16+
22.45 «Большая игра» 16+
23.45 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?». Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Анна Ковальчук. «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ» 16+
23.25 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.00 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+
04.00 Анна Горнова, Илья Шакунов, Никита Панфилов, Борис Невзоров и Екатерина Кистень в телесериале «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.50, 17.00 Новости
06.05, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
08.50 Биатлон. Pari Кубок России. Индивидуальная гонка. Женщины. Прямая трансляция из Увата
10.35, 12.45, 14.55, 01.10, 03.15 Футбол. Чемпионат мира-2022. Трансляция из Катара 0+
17.05, 20.00 Катар 2022. Все на футбол! Прямой эфир
17.45, 21.45 Футбол. Чемпионат мира-2022. Прямая трансляция из Катара
00.45 «Один день в Катаре» 16+
05.20 Биатлон. Pari Кубок России. Индивидуальная гонка. Мужчины. Трансляция из Увата 0+

НТВ

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.30 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 Премьера. Сериал «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» (S) 16+
22.10, 00.00 Остросюжетный сериал «АДМИРАЛЫ РАЙОНА» (S) 16+
00.40 «Поздняков» 16+
00.55 «Мы и наука. Наука и мы» 12+
01.45 Сериал «ПРОФИЛЬ УБИЙЦЫ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
08.50 «Давай разведёмся!» 16+
09.50 «Тест на отцовство» 16+
12.05 «Понять. Простить» 16+
13.10 «Порча» Из леса 16+
13.40 «Знахарка» 16+
14.15 «Верну любимого» 16+
14.50 «О ЧЁМ НЕ РАССКАЖЕТ РЕКА» 16+
18.45 «Спасите мою кухню» 16+
19.00 «СЛЕДУЯ ЗА СЕРДЦЕМ» 16+
22.45 «Порча» «Синдром Бога». «Разыскивается девочка» 16+
23.50 «Знахарка» 16+
00.25 «Верну любимого» 16+
00.55 «Понять. Простить» 16+
01.50 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ» 16+
02.40 «Тест на отцовство» 16+
04.20 «Давай разведёмся!» 16+
05.10 6 кадров 16+ Скетч-шоу
05.25 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.45 «Герой 115». Док. фильм 16+
07.00 Информационно-развлекательная программа «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 20.30 Новости дня 16+
09.20, 02.30 «РОССИЯ МОЛОДАЯ». «ВЕТЕР БАЛТИКИ» 12+
11.20, 21.15 «Открытый эфир» 16+
13.20, 15.05 «ЧЕРНЫЕ ВОЛКИ». 5-я – 8-я серии 16+
15.00 Военные новости 16+
18.15 «Специальный репортаж» 16+
18.50 «Ледоколы войны». Док. сериал. «Ледокол «Анастас Микоян». Огненный рейс». Премьера! 16+
19.40 «Код доступа» 12+
22.55 «Между тем» с Наталией Метлиной 12+
23.25 «Легенды футбола: 11 молчаливых мужчин». Док. фильм 16+
00.50 «МОЙ ЛУЧШИЙ ДРУГ ГЕНЕРАЛ ВАСИЛИЙ, СЫН ИОСИФА» 16+
03.55 «СВИНАРКА И ПАСТУХ» 12+
05.15 «Военные врачи». Док. сериал. «Военный врач Юрий Воробьев. Операция «Граната»: извлечь любой ценой» 16+

2 декабрь | Җомга

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Вести Приволжского федерального округа»
09.15 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.15 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
10.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
11.00 «Нәсыйхәт» 6+
11.30 «Татарлар» 12+
12.00 «Көмеш наратлык». Телесериал (татар телендә) 16+
13.00 «Башваткыч» 12+
14.00 «Актуальный ислам» 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
14.45, 05.35 «Оныта алмыйм…» Ретро-концерт 0+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Тизрәк! Алга! Житезрәк!» һәм «Алты хәреф» 0+
16.00 «Аулак өй» 6+
16.30 «Әдәби хәзинә» 6+
18.00 «Туган җир» 12+
19.00 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак барс» – «Локомотив». Прямая трансляция 6+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «КӨМЕШ НАРАТЛЫК» (Татар телендә) 16+
23.00 «БЫТЬ АСТРИД ЛИНДГРЕН» 16+
01.05 «Каравай». Национальные куклы 6+
01.30 «УЕННАН УЙМАК 2» 12+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Кәмит Җавит» 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра» 6+
08.40, 23.05, 04.15 «Ком сәгате» 12+
09.40, 15.30, 00.15 «Нәсыйхәт» 6+
10.30 «Казаннан – Казанга» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30 «Татарлар» 12+
12.05 «Идрис Газиев тәкъдим итә». «Сәйдәш театры» 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.30 «Калеб» 6+
18.20 «Әниемнең җылы кочагы» 6+
19.15 «Туган җир» 12+
19.40 «Заман көзгесе» 6+
20.10, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
21.25 «Йөрәктән – йөрәккә». Хәй Вахитов турында телеочерк 6+
22.20 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
00.40 «Калеб» 6+
01.05 И.Мәхмутова. «МӘХӘББӘТ ЧИШМӘСЕ». К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры спектакле 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш…» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 Премьера. «АнтиФейк» 16+
09.55 «Жить здорово!» 16+
10.45 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости
18.40 «Человек и закон» с Алексеем Пимановым 16+
19.45 «Поле чудес» (S) 16+
21.00 «Время»
21.45 Премьера. «Баста. Концерт в Лужниках» (S) 12+
23.30 Впервые на телевидении. «ЧУЖАЯ» (S) 18+
01.30 «СУДЬБА НА ВЫБОР». Многосерийный фильм (S) 16+
02.20 «Информационный канал» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?». Ток-шоу 12+
16.30 Премьера. «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.15 Местное время. Вести-Татарстан
21.30 Премьера. Музыкальное грандшоу «Дуэты». 12+
23.45 Премьера. «Улыбка на ночь». Программа Евгения Петросяна 16+
00.50 Анна Миклош, Андрей Биланов, Андрей Финягин. «ЛЮБОВЬ КАК НЕСЧАСТНЫЙ СЛУЧАЙ» 12+
04.10 Анна Горнова, Илья Шакунов, Никита Панфилов, Борис Невзоров, Екатерина Кистень. «ЛИЧНОЕ ДЕЛО» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.05, 12.15, 14.50, 17.00 Новости
06.05, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.10, 12.45, 14.55, 01.10, 03.15 Футбол. Чемпионат мира-2022. Трансляция из Катара 0+
11.15 «Оазис футбола». Прямой эфир
12.20 Футбол. Чемпионат мира-2022. Обзор 0+
17.05, 20.00 Катар 2022. Все на футбол! Прямой эфир
17.45, 21.45 Футбол. Чемпионат мира-2022. Прямая трансляция из Катара
00.45 «Один день в Катаре» 16+
05.20 Фехтование. Международный турнир «Московская сабля 2022». Женщины 0+

НТВ

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
08.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим» 6+
09.25, 10.35 «Следствие вели…» 16+
11.00 «Страшная химия». Научное расследование Сергея Малозёмова 12+
12.00 «ДедСад» 0+
13.30 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «ДНК» 16+
17.55 «Жди меня» 12+
20.00 Премьера. Сериал «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» (S) 16+
22.10 Остросюжетный сериал «АДМИРАЛЫ РАЙОНА» (S) 16+
00.00 «Своя правда» с Романом Бабаяном 16+
01.45 «Захар Прилепин. Уроки русского» 12+
02.10 «Квартирный вопрос» 0+
03.05 Сериал «ПРОФИЛЬ УБИЙЦЫ» (S) 16+
04.35 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.05 «Давай разведёмся!» 16+
10.05 «Тест на отцовство» 16+
12.20 «Понять. Простить» 16+
13.25 «Порча». Путы 16+
13.55 «Знахарка» 16+
14.30 «Верну любимого» 16+
15.00 «МОЖЕШЬ МНЕ ВЕРИТЬ» 16+
19.00 «САДОВНИЦА» 16+
23.00 «Порча» «Невыплаканные слёзы». «Чёрные слёзы» 16+
00.05 «Знахарка» 16+
00.35 «Верну любимого» 16+
01.05 «Понять. Простить» 16+
02.00 «ОТ НЕНАВИСТИ ДО ЛЮБВИ» 16+
02.50 «Тест на отцовство» 16+
04.30 «Давай разведёмся!» 16+
05.20 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

06.00 «Тацинский рейд. Маленькие герои победоносного боя». Док. фильм 12+
06.50 «БЕЗ ПРАВА НА ПРОВАЛ» 12+
09.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.20 «Легенды армии» с Александром Маршалом. Иван Баграмян 12+
10.10, 13.20 «НЕ ЗАБЫВАЙ». 1-я – 4-я серии 16+
14.35, 15.05 «Я ОБЪЯВЛЯЮ ВАМ ВОЙНУ» 16+
15.00 Военные новости 16+
16.50, 18.40 «КОМАНДА 8». 1-я – 4-я серии 16+
22.00 «Здравствуйте, товарищи!» Премьера! 16+
23.00 «Музыка+». Премьера! 12+
23.55 «ПОВЕСТЬ О ЧЕКИСТЕ» 12+
01.35 «СХВАТКА» 12+
03.10 «МОЙ ЛУЧШИЙ ДРУГ ГЕНЕРАЛ ВАСИЛИЙ, СЫН ИОСИФА» 16+
04.50 «Москва фронту». Док. сериал 16+
05.10 «ПОДКИДЫШ» 6+

3 декабрь | Шимбә

ТАТАРСТАН

08.00 «Вести-Татарстан»
08.20 Местное время. Суббота

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
07.00 «Синә Миннән Сәлам». Музыкаль котлаулар 6+
09.00 «Әй, язмыш, язмыш...» Разил Вәлиев (1 нче булек) 12 +
10.00 «Кайнар хит» 12+
11.00 «Туган авылым» 6+
11.30 «Казаннан – Казанга» 12+
12.00 «Каравай» 6+
12.30 «Видеоспорт» 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
13.30 «Болгар радиосы» концерты 6+
14.00 «Татар сүзе-2021» 6+
14.50 «Сынатмый яшик!» Илсур Сафиннның 60 яшьлек юбилей кичәсе 6+
18.00 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
19.00 «Tatarstan today. Открытый мир» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу 12+
20.00 «Адымнар» 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «Кунак БиТ шоу». Бәширә Насырова 12+
23.00 «РЕПЕТИТОР» 12+
00.35 «ПРОДЛИСЬ, ПРОДЛИСЬ, ОЧАРОВАНЬЕ...» 16+
02.05 «Вехи истории». Судьбоносные 90-е 12+
02.30 «Каравай». Портрет современного фольклориста 6+
02.55 «Кыр урдәге». Концерт 6+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
04.45 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
05.35 «Онытa алмыйм...» Ретро-концерт 0+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Идрис Газиев тәкъдим итә». «Сәйдәш театры» 6+
07.00, 15.00 «Синә Миннән Сәлам» 6+
09.00 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
10.00 «Кайнар хит» 12+
11.00, 18.15, 03.00 «Башваткыч» 12+
12.05, 19.05, 03.50 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 «Туган авылым» 6+
13.20 «Синең өчен сөюләрем». Алсу һәм Азат Фазлыевлар концерты 6+
17.10 «Казаннан – Казанга» 12+
17.45, 05.05 «Халкым минем» 12+
20.00 «Адымнар» 12+
20.30 «Восточный базар-2022». Гала-концерт I Международного фестиваля эстрады тюркских народов 6+
22.40 Ф.Бүләков. «Әбиләргә ни житми?» Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 12+
00.25 «Галиҗәнап шагыйрь» циклыннан. Илдар Юзеев 6+
01.20 Җ.Файзи, Т.Гыйззәт. «БАШМАГЫМ». Г.Кариев исемендәге Татар дәүләт яшь тамашачы театры спектакле 12+
04.40 «Юлчы» (субтитрлы) 6+
05.30 «Нәсыйхәт» 6+

1 КАНАЛ

06.00 Телеканал «Доброе утро. Суббота»
09.00 «Умницы и умники» 12+
09.45 «Слово пастыря» 0+
10.00 Новости (с субтитрами)
10.15 Премьера. «ПроУют» (S) 0+
11.10 Премьера. «Поехали!» 12+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Премьера. «Бог войны. История русской артиллерии» (S) 12+
13.50 «Юлиан Семенов. «Он слишком много знал...» 12+
14.40 По бестселлерам Юлиана Семенова. Василий Лановой, Георгий Юматов. «ПЕТРОВКА, 38» 12+
16.15 Фильм «Огарева, 6» 12+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Премьера. «Снова вместе. Ледниковый период» (S) 0+
21.00 «Время»
21.35 «Клуб Веселых и Находчивых». Кубок мэра Москвы (S) 16+
23.15 Премьера. Лиам Нисон «СДЕЛАНО В ИТАЛИИ» (S) 12+
01.00 «Великие династии. Строгановы» 12+
02.00 «Моя родословная» 12+
02.40 «Наедине со всеми» 16+
03.25 «Россия от края до края» 12+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России. Суббота»
08.00 Местное время. Вести-Татарстан
08.20 Местное время. Суббота
08.35 «По секрету всему свету»
09.00 «Формула еды» 12+
09.25 «Пятеро на одного»
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 Премьера. «Большие перемены»
12.35 Максим Аверин в телесериале «СКЛИФОСОВСКИЙ» 16+
18.00 «Привет, Андрей!» Вечернее шоу Андрея Малахова 12+
21.00 Премьера. Соня Присс, Сергей Перегудов, Максим Блинов, Владимир Петров, Мария Капустинская. «ЛАБОРАНТКА» 12+
00.40 Ирина Таранник, Сергей Ланбамин, Константин Соловьёв, Александра Власова. «ЗОРКО ЛИШЬ СЕРДЦЕ» 12+
03.50 Олеся Фаттахова, Сергей Мухин, Татьяна Чердынцева. «Я ЕГО СЛЕПИЛА» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 Смешанные единоборства. One FC. Анатолий Малыхин против Ренье де Риддера. Прямая трансляция из Филиппин
08.30, 12.20, 14.55, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
08.50 Биатлон. Pari Кубок России. Спринт. Женщины. Прямая трансляция из Увата
10.15, 12.50 Футбол. Чемпионат мира-2022. Трансляция из Катара 0+
14.50, 17.00 Новости
16.30 Футбол. FONBET Кубок России. Жеребьёвка. Прямая трансляция
17.05, 20.00 Катар 2022. Все на футбол! Прямой эфир
17.45, 21.45 Футбол. Чемпионат мира-2022. 1/8 финала. Прямая трансляция из Катара
00.45 «Один день в Катаре» 16+
01.10, 03.15 Футбол. Чемпионат мира-2022. 1/8 финала. Трансляция из Катара 0+
05.20 Фехтование. Международный турнир «Московская сабля 2022». Мужчины 0+

НТВ

05.05 «Спето в СССР» 12+
05.50 Детективный сериал «ИНСПЕКТОР КУПЕР» (S) 16+
07.25 «Смотр» 0+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «Поедем, поедим!» 0+
09.20 «Едим дома» 0+
10.20 «Главная дорога» 16+
11.00 «Живая еда» с Сергеем Малозёмовым 12+
12.00 «Квартирный вопрос» 0+
13.00 «Секрет на миллион». Елена Кондулайнен 16+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 «ЧП. Расследование» 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение» с Вадимом Такменевым
20.20 «Ты не поверишь!» 16+
21.25 «ПЯТЬ МИНУТ ТИШИНЫ. СИМБИРСКИЕ МОРОЗЫ» (S) 12+
23.30 «Международная пилорама» с Тиграном Кеосаяном 16+
00.15 «Квартирник НТВ у Маргулиса». Ваня Дмитриенко (S) 16+
01.25 «Дачный ответ» 0+
02.20 Сериал «ПРОФИЛЬ УБИЙЦЫ» (S) 16+
04.00 «АГЕНТСТВО СКРЫТЫХ КАМЕР»

ДОМАШНИЙ

06.30 6 кадров 16+
06.45 «Предсказания 2.2» 16+
08.45 «ПРИЗРАК НА ДВОИХ» 16+
10.45 «ЧУЖАЯ ДОЧЬ». 1-я – 8-я серии 16+
19.00 «ВЕТРЕНЫЙ». 61-я – 64-я серии 16+
22.30 «ОЛЮШКА» 16+
00.20 «ДЕНЬ РАСПЛАТЫ» 16+
03.35 «Нотариус» 16+
06.00 6 кадров 16+

ЗВЕЗДА

06.20, 03.15 «КОРОЛЕВСТВО КРИВЫХ ЗЕРКАЛ» 6+
08.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
08.15 «ОСТОРОЖНО, БАБУШКА!» 6+
10.05 «ДАЧНАЯ ПОЕЗДКА СЕРЖАНТА ЦЫБУЛИ» 12+
11.45 «Легенды музыки». «Приключения Электроника» 12+
12.10 «Легенды кино». Анатолий Ромашин 12+
13.15 «Время героев». Премьера! 16+
13.35 «Главный день». «Матч века и Лев Яшин» 16+
14.20 «СССР. Знак качества» с Иваном Охлобыстиным» 12+
15.10 «Не факт!» 12+
15.35 «Война миров». Док. сериал. «Советские герои. Битва одиночек» 16+
16.25 «ЧЕРНЫЕ БЕРЕТЫ» 16+
18.30 «КОДОВОЕ НАЗВАНИЕ «ЮЖНЫЙ ГРОМ» 12+
21.20 «Легендарные матчи» 12+
00.25 «Я ОБЪЯВЛЯЮ ВАМ ВОЙНУ» 16+
02.00 «В НЕБЕ «НОЧНЫЕ ВЕДЬМЫ» 12+
04.35 «Оружие Победы». Док. сериал 12+
04.45 «СИЦИЛИАНСКАЯ ЗАЩИТА» 12+

4 декабрь | Якшәмбе

ТАТАРСТАН

08.00 Местное время. Воскресенье

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00 Татарстанның халык артисты Искәндәр Биктаһировның юбилей концерты 6+
08.00 «Адымнар» 12+
08.30 «Зебра полосатая» 0+
08.45 «Әти һәм мин» 0+
09.15 «Тамчы-шоу» 0+
09.45 «Яшьләр тукталышы» 12+
10.15 «Ачыктан-ачык». Гөлназ Сәфәрова 12+
11.00 «Туган авылым» 6+
11.20 «Очрашулар эзләп». Габделфәт Сафин 6+
12.00 «Каравай» 6+
12.30.00 «Закон. Парламент. Общество»12+
13.00.00 «Видеоспорт» 12+
13.30.00 ТВ фондыннан. Г.Кариев. «АРТИСТ». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 12+
15.00 «Әниемнең җылы кочагы» 6+
16.00 «Ком сәгате» 12+
17.00 Хоккей. Чемпионат КХЛ. «Ак барс» – «Динамо» (М). Прямая трансляция 6+
19.30, 22.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
20.30 «Заман көзгесе» 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» Разил Вәлиев (1 нче булек) 12 +
23.00 «ПИРАТЫ ПО-СОСЕДСТВУ» 16+
00.40 «Ком сәгате» 12+
01.30.00 «Очрашулар эзләп». Габделфәт Сафин 6+
02.00.00 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
03.30.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.55.00 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45.00 «Җырлыйк әле!» 6+
05.35 «Онытa алмыйм...» Ретро-концерт 0+
05.50 Татарстан хәбәрләре 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00 «Заман көзгесе» 6+
06.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
07.00 «Адымнар» 12+
07.30 «Уткәннәр сагындыра» 6+
08.15 «Нурлы гомер... Нурлы күңел...» Татарстанның халык артисты Илдус Әхмәтҗановның юбилей кичәсеннән мизгелләр 6+
09.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 6+
10.30 «Калеб» 6+
11.10 «Тамчы-шоу» 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник» 6+
12.15 «Яшьләр тукталышы» 12+
12.35 «Халкым минем» 12+
13.00 «Туган авылым» 6+
13.20 «Tatarstan today. Дөньяга ачык» (субтитрлы) 12+
13.50 «Әдәби хәзинә» 12+
14.20 З. Хәким. «УТРАУ». Әлмәт татар дәүләт драма театры спектакле 12+
16.20 «Әниемнең җылы кочагы» 6+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». Юмористик тапшыру 16+
19.05 «Ком сәгате» 12+
20.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
21.10 «Әниемнең җылы кочагы» 6+
22.00 «Яңып яшик әле!» Айдар Габдиновның юбилей кичәсе 6+
00.10 «Шаян хәлләр» 12+
00.45 «Яшьләр тукталышы» 12+
01.05 «Манзара». Мәгълумати-күңел ачу программасы 6+
02.45 «Адымнар» 12+
03.20 Нәҗип Җиһанов исемендәге «Мирас» VII татар музыкасы фестивале 6+
05.20 «Уткәннәр сагындыра» 6+

1 КАНАЛ

05.15, 06.10 Фильм «ПЕТРОВКА, 38» 12+
06.00 Новости
06.55 «Играй, гармонь любимая!» 12+
07.40 «Часовой» (S) 12+
08.10 «Здоровье» 16+
09.20 «Мечталлион». Национальная лотерея (S) 12+
09.40 «Непутевые заметки» с Дм. Крыловым 12+
10.00 Новости (с субтитрами)
10.15 Жанна Бадоева в проекте-путешествии «Жизнь других» (S) 12+
11.10 Премьера. «Повара на колесах» 12+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 К 85-летию Эдуарда Артемьева. «ОБЫКНОВЕННЫЙ ГЕНИЙ» 12+
13.20 Фильм «Свой среди чужих, чужой среди своих» 12+
15.15 «Горячий лед». Фигурное катание. Чемпионат России по прыжкам. Трансляция из Санкт-Петербурга (S) 0+
18.05 «Романовы» (S) 12+
19.10 Премьера. «Поем на кухне всей страной» (S) 12+
21.00 «Время»
22.35 «Что? Где? Когда?» Зимняя серия игр (S) 16+
23.45 «Горячий лед». Фигурное катание. Чемпионат России по прыжкам. Трансляция из Санкт-Петербурга (S) 0+
01.15 «Моя родословная» 12+
01.55 «Наедине со всеми» 16+
02.40 «Россия от края до края» 12+

РОССИЯ 1

05.40 Антонина Дивина, Александр Константинов, Мария Аниканова, Павел Харланчук-Южаков. «НЕСМЕШНАЯ ЛЮБОВЬ» 12+
07.15 «Устами младенца»
08.00 Местное время. Воскресенье
08.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым»
09.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым»
10.10 «Сто к одному». Телеигра
11.00 Вести
11.50 Глафира Тарханова, Анатолий Руденко, Ксения Теплова, Юрий Батурин, Любовь Германова. «ОДНО ЛЕТО И ВСЯ ЖИЗНЬ» 12+
16.00 Вести
17.00, 19.00 Премьера. «Песни от всей души». Вечернее шоу Андрея Малахова 12+
18.00 Премьера. «Всероссийский открытый телевизионный конкурс юных талантов «Синяя Птица»
20.00 Вести недели
22.00 Москва. Кремль. Путин
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
01.30 Премьера. «Век суда» 12+
02.20 «Судьба человека с Борисом Корчевниковым» 12+

МАТЧ ТВ

06.00 Смешанные единоборства. UFC. Стивен Томпсон против Кевина Холланда. Сергей Павлович против Тая Туиваса. Прямая трансляция из США
08.30, 11.55, 13.35, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
08.50 Биатлон. Pari Кубок России. Одиночная смешанная эстафета. Прямая трансляция из Увата
09.50, 01.10, 03.15 Футбол. Чемпионат мира-2022. 1/8 финала. Трансляция из Катара 0+
12.20 Биатлон. Pari Кубок России. Смешанная эстафета. Прямая трансляция из Увата
13.30, 16.25 Новости
14.25 Баскетбол. Единая лига ВТБ. УНИКС (Казань) – ЦСКА. Прямая трансляция
16.30, 20.00 Катар 2022. Все на футбол! Прямой эфир.
17.45, 21.45 Футбол. Чемпионат мира-2022. 1/8 финала. Прямая трансляция из Катара
00.45 «Один день в Катаре» 16+
05.20 Фехтование. Международный турнир «Московская сабля 2022». Команды 0+

НТВ

05.00 Детективный сериал «ИНСПЕКТОР КУПЕР» (S) 16+
06.35 «Центральное телевидение» 16+
08.00, 10.00, 16.00 «Сегодня»
08.20 «У нас выигрывают!» Лотерейное шоу 12+
10.20 «Первая передача» 16+
11.00 «Чудо техники» 12+
11.55 «Дачный ответ» 0+
13.00 «НашПотребНадзор» 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра» 0+
16.20 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации» 16+
19.00 «Итоги недели» с Ирадой Зейналовой
20.20 «Суперстар! Возвращение». Новый сезон (S) 16+
23.15 «Звезды сошлись» 16+
00.45 «Основано на реальных событиях» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 6 кадров 16+
06.50 «ЕВДОКИЯ» 16+
08.55 «ОЛЮШКА» 16+
10.55 «СЛЕДУЯ ЗА СЕРДЦЕМ» 16+
14.45 «САДОВНИЦА» 16+
18.45 «Пять ужинов» 16+
19.00 «ВЕТРЕНЫЙ». 65-я – 68-я серии 16+
22.30 «ПРИЗРАК НА ДВОИХ» 16+
00.20 «ВОЗМЕЗДИЕ» 16+
03.30 «Нотариус» 16+

ЗВЕЗДА

06.20 «КОДОВОЕ НАЗВАНИЕ «ЮЖНЫЙ ГРОМ» 12+
09.00 «Новости недели» с Юрием Подкопаевым 16+
09.25 «Служу России» 12+
09.55 «Военная приемка» 12+
10.45 «Скрытые угрозы» с Николаем Чиндяйкиным. «Альманах №121» 16+
11.30 «Код доступа». «Вячеслав Трубников. Разведчик иностранных дел» 12+
12.20 «Легенды армии» с Александром Маршалом. Александр Серебряков 12+
13.15 «Специальный репортаж» 16+
13.55 «ТОЧКА ВЗРЫВА». 1-я – 4-я серии 16+
18.00 Главное с Ольгой Беловой 16+
19.45 «Легенды советского сыска». Док. сериал 16+
23.00 «Фетисов». Ток-шоу 12+
23.45 «ДАЧНАЯ ПОЕЗДКА СЕРЖАНТА ЦЫБУЛИ» 12+
01.20 «ОСТОРОЖНО, БАБУШКА!» 6+
02.45 «Тацинский рейд. Маленькие герои победоносного боя». Док. фильм 12+

РАДИО РОССИИ

«ТАТАРСТАН» РАДИОСЫ НИЛӘР СӨЙЛИ?

Казан – FM 99,2 МГц
Чаллы – FM 92,01 МГц
Түбән Кама – FM 101,1 МГц

radiotatarstana.ru

Дүшәмбе, 28 ноябрь

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуаль әңгәмә»
6.50,7.50,18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10 Кояш Тимбикова. «Кышкы талпыну». Радиопостановка
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 Александр Довженко. «Мин кайтырмын». Радиопостановка
18.10 Яңалыклар
18.25 «Сердәшханә»
18.35 «Жыр – минем гомерлек юлдашым»

Сишәмбе, 29 ноябрь

6.00-8.00 «Новый день». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуальное интервью»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Пар канатлар»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.30 Сирәк яңгырый торган музыкаль язмалар

Чәршәмбе, 30 ноябрь

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Актуаль әңгәмә»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 «Вместе за безопасность»
7.20 Туры элемтә
7.45 «Юллар чатында»
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 «Актуальное интервью»
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Яшьлек аланы»
18.25 Мөнир Мазунов шигырьләренә җырлар

Пәнҗешәмбе, 1 декабрь

6.00-8.00 «Новый день». Панорама событий. Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.45 «Перекресток»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Прямой эфир
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Татарстан: национальные проекты
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 «Офыклар»
18.25 «Газиз тавышлар». Зиннур Нурмөхәммәтов язмалары

Җомга, 2 декабрь

6.00-8.00 «Иртәнге нур». Новости России и Татарстана
6.25 «Музыкаль мизгелләр»
6.50, 7.50, 18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00-7.10 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-18.10, 19.00 Трансляция радио России
11.10, 15.10, 18.10 Яңалыклар. Новости
11.20 Вести ПФО
11.30 «Доброе братство лучше богатства» (на чувашском языке).
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.20 Концерт
18.25 Эстрада концерты

Шимбә, 3 декабрь

8.10 «Безгә тылмач кирәкми». Башкортстан радиосыннан алмаш тапшыру
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00 Трансляция радио России
10.10 «Табигать дуслары»
10.30 «7 көн». Атналык күзәту
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 «Мин әтине өйрәтәм». Радиосериал
11.25 Татар халык көйләре
13.10 «Татарстан дулкынында»
15.10 Мөхәммәт Мирза. «Мәңгелек юлында». Поэма буенча моноспектакль

Якшәмбе, 4 декабрь

8.10-9.00 «Между Волгой и Уралом». Объединенный радиожурнал семи республик
9.00-10.10, 11.00-11.10, 12.00-13.10, 14.00-15.10, 16.00-16.10, 17.00 Трансляция радио России
10.10 «Көмеш кыңгырау»
10.30 «7 дней». Обзор событий недели
10.55, 13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.10 Ял концерты
13.10 «Татарстан дулкынында».
15.10 «Тел күрке – сүз»
15.35, 16.10 Аяз Гыйлаҗев. «Көлсәң көл, еласаң ела». К. Тинчурин ис. ТДДһКТ спектакленең радиоварианты

РЕКЛАМА БУЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

Диплом N 101631 0233733, регистрационный номер 190401023, выданный федеральным государственным бюджетным образовательным учреждением высшего образования «Казанский государственный медицинский университет» Министерства здравоохранения РФ г. Казани на имя Багмановой Вилены Камилевны, считать недействительным в связи с утерей.

Илдар Мөхәммәтҗанов

ШӘЛЕНЕ КҮР ӘЛЕ!

Сәрия МИФТАХОВА

47 чакрым урамы, 1212 йорты, 3 меңнән артык кешесе бар республикадагы иң зур авылның. Шәле башкаладан нибары 40 чакрым ераклыкта урнашкан. Дөресрәге, Казан – Шәленең бакча башында гына. Шуңа күрә халык телендә аны «Казанны ашатучы авыл» дип тә йөртәләр, бу сүз дөреслектән әллә ни ерак түгел. Калага якын булуның нинди уңай һәм тискәре яклары бар? Шәле якларын урап, халыкның тормышы белән танышып кайттык әле.

Урамнар буйлап...

Соңгы арада Шәлегә барганыбыз булмаган икән. Шушы вакыт эчендә шактый үзгәрешләр кичергән ул. Авыл башында ике катлы йортлардан төзелгән «Шәле Рублевкасы» үсеп чыккан. Бу урында хәзер 40лап йорт бар. Җирлек башлыгы Илшат Әхмәтҗанов әйтүенчә, авылда йорт салырга урын калмаган. Һәркемнең капка төбендә – икешәр-өчәр машина, тракторы, башка техникасы да күренә. Ком, таш кебек башка төзелеш материаллары да өелеп тора. Димәк, тик ятмыйлар, кеше йортын, каралты-курасын төзи, яңарта дигән сүз бу. Тагын бер күзгә ташланган әйбер: бакчаларда сырганак үсә. Гадәттә, авылларда балан, миләшне җыймыйча, кышка кошларга калдыралар. Монда исә без карлы сырганакларны күрдек. Кошларга калдырганнармы, әллә җыярга иренгәннәрме...

> Бездә берәү капкасын, түбәсен яңартса, икенчесе дә шуны эшли. Ак көнчелек белән яши. Начар әйбер түгел бу. Халык тырыш, усаллык дигән нәрсә дә бар, – ди җирлек башлыгы.

Авылда дистәдән артык кибет, мәктәп, бакча, почта, даруханә, амбулатория кебек барлык социаль объектлар да бар. Кемдер өендә тырнак, макияж ясап, кемдер заказга торт пешереп, пилмән ясап акча эшли. Тәрәзә йөзлекләре, кабер ташлары ясаучылар да бар. «Шәле-Агро» җәмгыятендә 120ләп кеше хезмәт куя. 800ләбе читкә йөреп эшли икән.

Кушаматсыз булмый

– Авыл бик зур булгач, халык бер-берсен беләме соң? – дип сорадык үткән-сүткәннәрдән.

– Белмибез, әлбәттә. Авыл урамнарын әйләнеп чыгу өчен дә бер көн кирәк. Барысының озынлыгын бергә кушсаң, 47 чакрым килеп чыга, – диде алар.

Кешенең бер-берсенә кушамат белән дәшүе – гадәти хәл биредә. Башкача мөмкин түгел. Бер исем, бер фамилияле кешеләр күп чөнки. Мәктәптә завхоз булып эшләүче Рафис Мөхетдинов та шулай диде. «Безнең авылда Мәрзияләр алтау иде. Әнинең дә исеме – Мәрзия. Гомер буе мәктәптә эшләде. Тегеләргә җибәргән хатны – әнигә, әнигә дигәнен башкага китергәннәр. Әнине Яфрак дип йөртәләр иде. Нинди генә кушамат юк. Бүре, Аю, Куян, Карга, Чыпчык, Карлыгач. Барысы да бар», – ди ул.

Мәктәп директоры Минзифа апа Хәсәновалар нәселен Үзбәк дип йөртәләр икән. «Моның өчен бер дә үпкәләмибез. Әти шулай, эштән кап-кара булып кайтып килә икән. Нинди үзбәк кайтып килә монда, тешләре генә күренә, дигәннәр. Шуннан әлеге кушамат тагылып калган инде», – ди Минзифа апа.

Килмешәк идек...

Шәле халкы үз авыллары турында яратып, горурланып сөйли. Кешедән сүз әйттермиләр, авыл ватанпәрвәрлеге көчле. Шул ук вакытта Шәледә читтән кайтып төпләнүчеләр дә аз түгел. Алар арасында төрле фикер әйтүчеләр булды.

– 20–30 ел элек безгә авыл халкы килмешәк итеп карый иде. «Ник кайттыгыз?» – диючеләр дә булды. Ызан бүлешү, башкасы да баштан үтте. Хәзер халык тынычланды. Күршегә йөрү гадәте дә саклана, – диде юлда очраган яңа танышыбыз. Әмма исемен барыбер әйтмәде үзе.

Таҗикстаннан күченеп кайткан Фәүзия апалар йортына да кердек. Тумышы белән Шәледән ул. Үзбәк егетенә кияүгә чыгып, 23 ел читтә яшәгән. «Туган авыл сагындырды, әле ярый вакытында кайтып калганбыз», – ди 69 яшьлек Фәүзия апа.

Кыз урлау

Шәле дигәндә, иң элек кыз урлау гадәте искә төшә. Без туктатып сөйләшкән парларның күбесе элек шулай кавышкан. Мәктәптә җыештыручы булып эшләүче Минзәһидә Бикчәнтәеваны да ире Мансур урлап алып кайткан. Гаилә коруларына – 43 ел, өч кыз үстергәннәр.

– Клубта кино күрсәтәләр иде. Мине авыл егетләре урлап, бер йортка илтеп куйдылар. Мансур кино күрсәтүче булып эшли иде. Эше беткәч, ул да килде. Өч көн шунда кундык, никахны егет өендә укыттык. Бер гадәт әле дә истә: булачак каенана күрешергә дип кулын сузгач, аңа әни дип дәшәргә кирәк. Шунсыз кулны ычкындырмый. Һәр атнаның пәнҗешәмбесендә яшь гаилә килен йортына барып куналар, – дип искә ала Минзәһидә апа.

Сыерлар көтүгә чыкмый

Авылда элек сыер саны 1400дән артып китсә, хәзер 250 генә тирәсе.

– Көтү чыкмый, малларны абзарда гына тоталар. Юллар салып, көтүлекләр бетте. Кешеләр пай җирләрен алып бетерде, – дип аңлатты Илшат Әхмәтҗанов.

Элек шәһәргә эремчек, каймак, сөт сатарга йөргән апалар да калага сукмакны суыткан. Бер сәбәбе – Казанда ачык базарларның ябылуы. Әмма башкалага барып сату итүчеләр бөтенләй үк бетмәгән әле.

Сафиннар гаиләсе моңа кадәр өчәр үгез, сыер тоткан. Банкетларда йөреп, акча керә башлаганнан бирле терлек тотмыйлар икән. Элек итен дә, бәрәңгесен дә Казанга барып сатканнар.

– Хайван асрау чыгымлы. Печәнен, ашлыгын сатып алырга кирәк бит. Хәзер сыерны колхоз тирәсендә эшләүчеләр генә тота, – ди Гүзәл Сафина.

Терлек димәктән, узган гасырның сиксәненче елларында Шәле халкы итне Мәскәүдән алып кайта торган булган. Юлдашыбыз Рафис Мөхетдинов әйтүенчә, кеше шулай акча эшләгән.

– Ул вакытта итнең килосы 1 сум 60 тиен – 2 сум тора иде. Авылдагы бер абзый 50–60 кило ит алып кайтып, биш сумнан сатты. Шулай итеп, «Москвич» алды. Поезд белән барып бит бу. Колхозда ул вакытта атчылар айга 50 сум акча эшли иде. Минем дә, әниләргә ияреп, берничә тапкыр атланмай, ит алып кайткан булды, – дип искә ала Рафис абый.

Өйдә яту минем эш түгел

Пилмән, мантый, голубцы ясап сатучы Галиуллиннар гаиләсенә дә сугылдык. Дүрт ел элек тотынган алар бу шөгыльгә, авылдагы дүрт кешене эшле дә иткәннәр әле. Сиринә Казанда йогышлы авырулар хастаханәсендә санитарка булып эшли. Аннан кайткач, 4–5 сәгать пилмән бөгә.

– Мин башта 20 ел кафеда пешекче булып эшләдем. Аннары өйдә генә ятарга уйладым. Янәсе, пилмән бөгеп, акча эшлим. Тик өч ай узуга кеше арасына чыгасы килә башлады. Казанга эшкә урнаштым, әмма ярымфабрикатлар ясаудан туктамадык. Ике сеңлем, килендәшем, күршем Сиринә булыша. Аларга да өстәмә акча эшләргә җай чыкты. Продукцияне авыл кешеләре дә ала, базарга да чыгып сатабыз, күрше авылларга да илтәбез, – ди Сиринә.

Мәктәп – кыйбла күрсәтүче

Шәле мәктәбендә 246 укучы укый, 27 укытучы белем бирә. Директор Минзифа Хәсәнова әйтүенчә, укучылар саны артып тора. Бакчага 250дән артык сабый йөри.

– Безнең мәктәптә Тукайны рухландыручы Зәйтүнә Мәүлүдова (1930–1934) укыткан, – дип горурланып сөйли Минзифа Хәсәнова. – Танылган шәхесләр күп чыккан безнең авылдан. Дин эшлеклесе Равил Гайнетдин мәктәпкә гел ярдәм итеп тора. Оялсак та, күбрәк аннан сорыйбыз инде. Әти-әниләр дә мәктәпкә булыша. 7–8 укучыбыз медицина университетында укый, биология-химия укытучысы да, башка укытучыларыбыз да көчле. Ел саен 4–5 укучыбыз республика күләмендәге олимпиадаларда җиңү яулый.

Урамда балалар татарча сөйләшәме? «Татар мәктәбе булгач, урамда үзебезчә сөйләшәләр. Чын татар авылы бу. Күченеп килгән башка милләт балалары да татар телен теләп өйрәнә», – диде мәктәп директоры.

Зөһрә САДЫЙКОВА

ЧИКНЕҢ ТЕГЕ ЯГЫ

Россиядә өлешчә мобилизация башланганнан соң, ватандашларыбыз арасында Казахстанга юл тотучылар күп булды. Әлеге республика – күп мигрантлар өчен алга таба күченүдә бер тукталыш ноктасы гына. Кемнәрдер, анда тукталганнан соң, юлларын Төркия, Грузия, Израиль һәм башка илләргә таба дәвам иттерде. Алар бүген ничек яши? Кире кайтырга җыенамы?

vk.com

«Барыбер китәсе идек»

Мобилизация башлангач, Россияне калдырып китүчеләр арасында Алсу һәм Илнур Гариповлар (язма геройларының исем-фамилияләре үзгәртелде) да бар. Илдә үзгәрешләр башлангач, алар башта ике балалары белән – Казахстанга, ә аннан Балига юл тоткан.

– Без – ирек яратучы, һәрвакыт сәяхәт итеп торучылар. Казанда да даими яшәү урыныбыз юк иде. Фатирны арендалап тордык, – дип сөйләде безгә Алсу. – Чираттагы сәяхәтебездән Казанга июньдә кайттык. Бу юлы Татарстанда озаграк торырга уйлаган идек. Туганнар белән күрешәсебез, эшләрне дә эшләп бетерәсебез бар иде. Ләкин мобилизация башлангач, планнарны тиз арада үзгәртергә туры килде. Әйе, яшермим, иремә хәрби операциягә чакыру килү мөмкинлеге зур иде. Ә минем ике балам белән ялгызым каласым килмәде. Балаларымның да бу хәлләрне күреп, ишетеп яшәүләрен теләмәдем. Һәм без, иң якын кешеләребезгә дә берни әйтмичә, юлга кузгалдык. Әгәр моңа кадәр гадәттә 2–3 чемодан белән сәфәргә чыксак, бу юлы дүрт кешелек гаиләнең бар кирәк-ярагы нибары ике рюкзакка сыеп бетте.

Беренче тукталышыбыз, ул вакыттагы бик күп ватандашларыбызныкы шикелле үк, Казахстан булды, чөнки безнең башка вариантлар юк иде. Мобилизация аркасында, билетларга бәя бик нык күтәрелде, безнең гаилә өчен турыдан-туры Балига очу 1 млн сумга төшә иде. Шуңа күрә берникадәр вакыт Казахстанда яшәгәч кенә, утрауга кузгалдык. Чикне чыкканда да зур кыенлыклар кичермәдек, балалар белән булгач, җиңелрәк булды. Ләкин чик янындагы хәлләр коточкыч, чиратлар озын чакрымнарга сузылган иде. Үз машиналары белән баручы кешеләргә өчәр тәүлек сусыз һәм ризыксыз утырырга туры килде. Без исә чиктә каршы алырга тиешле кешеләр белән алдан ук килешкән идек. Тик анда бер проблема белән очраштык – отельда урыннар юк иде. Бераздан анысы да хәл ителде. Казахстанда барысы да бик арзан, без хәтта шунда калу турында да уйлый башлаган идек. Тик барысын да тагын бер кат утырып сөйләшкәч, юлыбызны дәвам иттерергә булдык. Икенче чикне чыкканда, кая баруыбызны сорадылар. Без үзебезне сәяхәт итүчеләр дип таныштырдык, Балига баруыбызны әйттек. Башка сораулар бирүче булмады.

Моңа кадәр дә Балида булганыбыз бар иде. Монда безгә ошый. Тормыш дәрәҗәсе Казаннан әллә ни аерылмый. Бәяләр дә шулай ук. Балалар да мондагы тормышка ияләште. Алар балалар клубларына йөри, дуслары белән аралаша.

Эш мәсьәләсенә килгәндә, без инде күптәннән маркетинг, психология буенча читтән торып эшлибез. Шуңа күрә моның белән проблема булмады. Алда әйткәнемчә, кайчан да булса барыбер күченәчәк идек, мобилизация моны тизләтте генә.

Безнең алдан ниндидер планнарыбыз булса, күпләр өчен бу һич көтелмәгән хәл булды. Россиядән китүчеләрнең күпчелеге – барлык запасларын, соңгы акчаларын алып чыгып киткән урта хәлле кешеләр. Андыйлар безнең отельда да бар, аралашабыз, бер-беребезгә ярдәм итәргә тырышабыз. Бездән аермалы буларак, алар башка халәттә. Әгәр мобилизация булмаса, монда килмәсләр иде. Аларның тормышлары тулысынча үзгәрде, чарасызлыктан ни эшләргә белмиләр. Аларга бик авыр. Кемнәрдер офлайн эш эзли, кемдер алга таба ничек яшәргә, каян акча табарга кирәклеген аңламый. Кемдер, кире кайтыр өчен, илдәге хәлләрнең тотрыклануын көтә.

Танышларыбыз арасында бу хәлләрне бик авыр кичерүчеләр дә бар. Мәсәлән, Мәскәүдән килгән өч балалы гаилә. Без алар белән Казахстан чигендә күрештек. Мәскәүдә йортларын калдырып чыгып киткәннәр. 20 млн сум кертеп, күптән түгел генә салып чыккан булганнар. Шул тормышларыннан бары тик мобилизация аркасында гына аерылганнар.

> Алар машиналарын Казахстан чигендә ташлап калдырырга мәҗбүр булды. Хәлләре шулкадәр авыр булган ки, хәтта аны бикләүне дә кирәк дип тапмаганнар. Кем тели, шул алсын, дигәннәр. Алар бик нык курку һәм стресс халәтендә яши. Казахстаннан соң Ташкенттагы туганнарына барып сыенганнар дип беләбез, читтән торып эшли башлаганнар.

«Кирегә юл юк»

Тагын бер героебыз – шәхси эшмәкәр Айдар. Россиядә өлешчә мобилизация игълан ителгәннең икенче көнендә үк ул, машинасын сатып, бер рюкзак белән илдән чыгып киткән.

– Бу хәлләр башланганчы ук, йортыбызны сатуга куйган идек, мобилизация игълан иткән көннәрдә аны сатып алучы табылды, тиз арада аның да эшен бетердем, – дип сөйләде безгә Айдарның хатыны Гөлнара. – Һәм мин, ялгызыма өч бала белән авыр булыр дип, авылга – каенана янына кайтып киттем. Үзем читтән торып эшли идем, кайбер клиентларны югалтырга туры килде. Балаларны авыл мәктәбенә урнаштырдым. Чынлыкта ул көннәрдә машиналарын, булган бар мөлкәтен сатып китүчеләр күп булды. Иремнең ни өчен мондый карар кабул итүен чамалый торгансыздыр. Шулай да үзем аңлатып узыйм әле. Беренчедән, без – дини гаилә. Һәм ирләребезгә бары тик дин өчен сугышларда катнашу гына хупланыла. Икенчедән, ирем – хәрби хезмәттә булган кеше һәм ул Россия армиясенең нинди мөмкинлекләргә ия булуын бик яхшы белә иде. Шуңа күрә мин дә, әнисе дә аңа һәр яклап теләктәшлек күрсәттек.

Айдарның башка илдә юлы уңды, дип әйтергә була. Тиз арада җыенып чыгып киткәч, Казахстан чиген узганда авырлыклар тумаган, чиратлар да алай ук озын булмаган. 5–6 чакрым юлны гына җәяүләп узган. Шунысын әйтергә кирәк: ирем Казахстанда туган. Тышкы кыяфәте, холкы, темпераменты белән дә шул як халкына охшаш. Эше буенча да Кыргызстан, Үзбәкстан белән элемтәдә торды. Шуңа күрә Казахстанга киткәч тә, эш мәсьәләсендә кыенлык кичермәде, эшен шунда дәвам иттерә. Халкы да аны бик яхшы кабул итте. Гомумән, аның сүзләре буенча, казахлар россиялеләрне аңлап кабул итә, ярдәм итәргә тырыша. Казахстанда бәяләр бик арзан. Ул анда фатир арендалап тора, яшәү шартларыннан канәгать.

Билгеле, безнең тормышыбыз бик нык үзгәрде. Барысы да шәп, дип әйтү дөрес булмас иде. Үзе дә, балалар белән мин дә бик нык сагынышабыз. Әле күптән түгел генә балаларны алып, Төркиягә очтык. Ирем дә шунда килде. Бер айга якын бергә булдык. Самолетта да, отельда да безнең кебек гаиләләрнең күплегенә шаккаттым. Кемнеңдер ире генә киткән, кемдер гаиләләре белән күченергә мәҗбүр булган. Кире кайтучылар да бар. Китүчеләрнең күбесе, паникага бирелеп, аптырраганнан юлга кузгалды. Андыйларның максатлары да, планнары да юк иде. Бүген күбесе эш таба алмый. Төркиядә хәер сорашып, тамагын туйдырып йөрүче ватандашыбызны да беләм.

Алга таба планнарны беребез дә белми. Инде военкоматтан иремне эзләп килүчеләр булды. Шуңа күрә ул кайту турында уйламый да. Безне дә үз янына чакыра. Ләкин әлегә безнең анда каласыбыз килмәде, кире кайттык. Алдагысын киләчәк күрсәтер.

Үлчәү

Россиядән чыгып китәргә мәҗбүр булган тагын бер пар – Елена һәм Дима. Алар да, үзгәреш җилләре исә башлагач, озак уйлап тормаганнар, 25 сентябрьдә юлга кузгалганнар. Шушы ике ай эчендә күргәннәрен безгә Елена бәян итте.

– Безнең тормыш 21 сентябрьгә кадәр һәм аннан соңгыга бүленде. Өлешчә мобилизация башлангач, без, дүрт кеше, Казахстанга күченеп киттек. Әлеге адымыбызны тормышымның иң тәвәккәл һәм акылсыз адымы дип саныйм. Юлга без минем машинада кузгалдык. Алдан чыканга күрә, чикне 5 сәгать эчендә уздык. Бездән соң кузгалган танышларыбызга 12–15әр сәгать утырырга туры килде. Беренче тукталышыбыз Петропавловск шәһәре иде. Анда 3 көн тордык. Чикне чыккач, иң зур авырлык фатир табу булды. Бу көннәрдә бәяләр көнләп түгел, сәгатьләп үсте һәм аның чиге күренми төсле иде. Алдан килешенеп куйган бәяләрнең берничә яраксыз булуына күп тапкырлар инанырга туры килде. Бәяләр котырып артса да, тукталыр өчен урын табу бик авыр булды. Мин бик зур стресс кичердем. Ниһаять, бер бүлмәле фатирга урнаша алдык. Аннан соң без Балхаш шәһәрендә һәм Астанада туктадык. Бу калаларда безне бик яхшы кабул иттеләр. Хәзерге вакытта без Алма-Атада яшибез.

Казахстанда бәяләр арзан. Чикне чыккач, дүрт кешегә 20 мең сум (үзебезнең курс белән исәпләгәндә) өч көн фатир арендаларга, машина страховкасын алыштырырга, ашарга һәм башка вак-төяк чыгымнарга җитте. Русларга мөнәсәбәт яхшы. Әгәр үзең конфликтка кермәсәң, дорфа һәм әдәпсез булмасаң, үзеңә дә шундый ук караш. Безгә: «Сезнең йортыгызга зур кайгы килде», – дип әйтүчеләр булды.

ИНН, җирле сим-карталар һәм банк карталары алдык. Барысы да яхшы кебек, ләкин без йортыбызны, якыннарыбызны һәм өйдә калган песиебезне бик нык сагынабыз. Ике бик яхшы эш урынымнан китәргә туры килде, анысын кабул итү тагын да авыррак. Үзем эшләгән хастаханә миңа икенче гаиләм кебек иде. Сагынуны әйтеп-аңлатып бетереп булмый. Хәтта операция ясауларым төшләремә керә. Үз профессиям буенча эшкә урнашасы килә, югары белем турында дипломнарны раслатырга бирдем, җирле боерыкларны һәм тәртипләрне өйрәнәм. Әлегә мине беркем дә эшкә алмый, чөнки дипломнар расланмаган. Россия дипломнары монда берничә яраксыз. Әлегә без Казандагы фатирны арендага бирдек. Монда шуннан кергән акчага һәм азмы-күпме кулда булган запаска өметләнеп яшибез.

> Тормышымны барысын да яңадан башлау дип кабул итмим, чөнки минем һөнәрем, белемем, гаиләм, дусларым һәм теләсә кайсы вакытта кайтырга мөмкин булган йортым бар. Шулай да кайвакыт күңелдә ике төрле хисләр бураны кузгала. Бер көнне мондагы матурлыкка соклансам, икенче көнне: «Мин – берничә яраксыз кеше, эшсез, моңа кадәр булган бөтен уңышларымны, дәрәҗәләрне югалтучы, Россиядән килгән табиб кемгә кирәк?» – дип күз яше коям. Никадәр авыр булса да, безгә бирешергә ярамый.

КАЙТАМ, ДИДЕ. КАЙТАЧАК!

Соңгы вакытта тормышыбызның асты өскә килде. Кайчандыр яшәүнең ямен таба белмәсәк, тынычлыкның ни икәнен аңламаган булсак, хәзер инде бар да башкача. Әкренләп яңача яшәргә өйрәнеп киләбез. Берәүләр бүген туган көнгә сөенә, икенчеләр янәшәсендә ирләре булганга шатлана, өченчеләр исә сөйгәннәренең исән-сау яннарына кайтасына өметләнә.

Өлешчә мобилизациягә эләгүчеләр хакында күп яздык. Аларның күбесе инде махсус операция урынында, кайберләре әле дә әзерлек уза, илне сакларга китәргә үз чиратын көтүчеләр дә бар. Аларның гаиләләрендә тормыш дәвам итә. Эшкә барасы, балаларны укырга илтәсе, бакчага йөртәсе бар. Ирсез калган хатыннар ничек көн күрә? «ВТ» журналисты сөйгәннәрен махсус операциягә озаткан ханымнар белән сөйләште.

«Ирем шалтыратса, еламас та идем»

Казанда яшәүче Рамилә Антонова иренең исән-сау әйләнеп кайтуын көтә. Көтә генәме соң!.. Җомга саен мәчеткә барып дога кылдыра, көн саен үзе дә, иренең исән-сау кайтуын сорап, Аллаһы Тәгаләгә ялвара. Рамилә очрашу насыйп буласына бик ышана. Ире дә, елап утырма, начар уйларга бирешмә, мин барам да кайтам, дип киткән.

– Күңелдә борчылу бар инде ул. Киткәннән бирле иремнең бер тапкыр да тавышын ишеткәнем юк. Шалтырата алмый, – ди Рамилә.

Рамилә белән Вилданның ике баласы бар. Улары Илназ янына күптән түгел сеңлекәш тә алып кайтканнар. Инзилә әле бик кечкенә. Ә менә Илназ әтисен бик сагына икән.

– Улымның әтисен кочаклап аласы килә. Каты итеп кочар идем, сагындым, ди. Ничек сагынмыйсың инде! Үземнең дә тавышын ишетәсем килә. Көн дә шалтыратыр дип көтәм. Үземне дә әзерләп куйдым инде. Ул шалтыратса, еламас идем, – ди Рамилә.

Иремә түләнә торган акчаның тиенәнә дә кагылмыйм, Вилдан кайткач, бергә тотарбыз әле, ди.

– Тормышны алып барыр өчен үзем тырышам. Челтәр бизнесым бар. Әтиәнием, туганнарым ярдәм итеп тора. Авырлык килгәндә, мин ялгыз түгеллегемне аңладым. Янәшәмдәге һәркемгә рәхмәтлемен, – ди Рамилә.

Ире киткәч, аңа әллә ниләр язып җибәрәләр. Күңелсез хәбәрләр дә юллыйлар. Әмма ул андый кешеләрнең сүзләренә җавап та бирми. Интернетта язылган мәгълүмат йөри бит инде, ди ул.

– Паника ясарга кирәкми дип уйлыйм. Бар да – Аллаһы Тәгалә кулында. Мин иремнең әйткән сүзләренә ышанам. «Кайтам», – диде бит. Димәк, кайтачак. Начар уйлар белән башымны тутырмыйм. Исән генә булсын, – ди Рамилә. – Мин аның дуслары белән элемтәдә торам. Алар аша ярдәм җибәрәм. Исәнлеген белеп тору да җитә. Илләр тынычланыр, ирем җиңү белән кайтыр дип көтәм.

«Яшәргә өйрәнеп киләм!»

Балтач районының Норма авылында яшәүче Әлфинә Маннанова да ирен сагынып көтә. Моңа кадәр ире ышыгында гына яшәгән ханымга башта бик авыр була. Иренә повестка килүгә, икенче көнне үк Казанга алып та китәләр. Гаилә аңышмый да кала.

– Бар да тиз булды. Ирем армиядә хезмәт иткән. Снайпер булган икән. Моңарчы аның хәрби билетын ачып та караганыбыз юк иде. Махсус операциягә машина йөртүче булып китте. Өйдән чыгып китүенә 2 ай инде. 26 сентябрьдә Казанга киткән иде. Аннары 27 октябрь көнне Воронеж өлкәсенә алып киттеләр. Озак та тормаган, сугышка керткәннәр, – дип сөйли Әлфинә. – Без ике малай үстерәбез. Олысы – 3 нче, кечкенәсе 1 нче сыйныфта укый. Алар әтиләрен бик сагына. Кечесе аңлап бетермәсә дә, олысы бөтен яңалыкны белеп тора. Ул, хәрби операциядән әти ябыгып кайтыр инде, дип көтә. Ул кайткач, бөтен гаилә белән бассейнга йөреячәкбез, дип тә хыяллана. Шул балалар булмаса, нишләр идем икән?

Әлфинә, хәзер инде еламыйм, ди. Иренең әнисе дә, син көчле булганга Аллаһы Тәгалә сынау җибәргән, дип юата икән. Туганнары да ярдәм итеп тора. Әлфинә ире белән бергә эшләгән Рәшит Ильясовка, Норма җирлеге башлыгы Радик Шәрипҗановка, Балтачта яшәүче икетуган Алсу апасына рәхмәтле. Шул Алсу апасы көчле булырга өйрәтә дә икән инде. Карашыннан да аңлый икән. Алсу апасы да Ранилнең орден-медальләр тагып кайтасына ышана.

– Мин бит бер генә түләү дә түләгән кеше түгел. Ипотека кредитын да ирем каплап барды. Квартплата да, башка түләүләр дә ирем өстендә иде. Телефон аша барысын да эшләп торды. Ул киткәч, мин яшәргә өйрәндем, – ди Әлфинә. – Хәрбиләрнең балалары бушлай ашатыла, дисәләр дә, аның артыннан да үзем йөрергә туры килде. Документлар илткәч кенә бушлай ашата башладылар. Әле улларым беренче генә ай бушлай ашый. Ирем тиз киткәч, хәрби комиссариатта күп кенә документ эшләре дә эшләнми калган. Шуларның очына чыгып йөрдек. Әлегә кадәр иремә бер тиен дә акча күчмәде. Ипотекабызга да кредит каникулы бирәбез, дигәннәр иде. Уйлап карагач, аның процентлары күп җыелганын аңладым. Иремнең машинасын сатып, шул акчаны түләдек. Хәзер инде айлык сумманы кечерәйттек. Моңа кадәр акчаны ирем эшләгәч, аны түләү дә җиңел түгел. Әмма бирешергә җыенмыйм. Ничек тә булса, яшәргә кирәк.

Әлфинә ире белән сөйләшкәләп тора икән. Тик сөйләшү кыска була. Ире: «Бездә тәртип», – дип тә әйтә дә, тиз генә телефонны сүндерә икән. Әлфинә әнә шул сүзгә дә риза. Иң мөһиме – Раниле исән! Дөньялар тизрәк тынычланып, бөтен ирегетләрнең өйләренә кайтуын тели ул.

– Елап утырып эш чыкмый. Башта мин дә еладым. Аннары инде үземне кулга алдым. Ике балам бар бит. Егетләрем үсеп килә! Алар әтиләрен күреп горурланып тора. Әнә бит, безнең әти батыр, көчле, дип әйтәләр. Җиңеп кайтасына да ышаналар, – ди Әлфинә. – Мин дә өметемне өзмим. Күңел көтә. Матур көннәр әле алда күп булыр, дип яшим.

«Аллаһы Тәгалә көч бирә»



Ирләрен көтүчеләр арасында Татарстанның атказанган артисты Иркә дә бар. Аның ире Артур да – хәрби операциядә. Ул сөйләшергә җай чыккан саен хатынын, кызларын кайгырта икән. «Миңа караганда сезгә авыррак», – дип әйтә ди Артур.

– Ирем белән әллә нигә бер сөйләшәбез. Ул һаман безне кайгырта, – ди Иркә. – Әти-әни биргән тәрбиям көчле итә мине. «Ирем китте», – дип, кешегә күрсәтеп елап утырып булмый. Өйдә – балаларым, төркемемдә 13 кешем бар. Ничек тә алга таба яшәргә кирәк. Тамашачым миңа бик тә ярдәм итә. Сәхнәгә чыккач, мин аларның җылысын тоям. Бар борчулар онытыла.

«Иркәнең ире дә киткән бит әле», – дип үзен юатучылар да бар. Бик күпләр җырчының үзенә дә яза икән. Алар арасында әле яңа гына кияүгә чыккан ханымнар да, бәби көтүчеләр дә бар икән. Әнә шулар өчен ул яңа җырын чыгарган да инде. «Бары тик саубуллашу» дип аталган җыр өчен бик күпләр рәхмәт укый икән.

Иркәнең дә төрле чаклары була. Өйдә утырсам, елыйм, ди үзе.

– Кичләрен бик уйланам. Иремне сагынам. Әмма ул елап ятарга кушмады. Артурның көчле булуы, шалтыратканда да күңелне күтәрергә тырышуына шаккатам. Ул, кайтам, дип китте. Аллага шөкер, янәшәсендәге егетләр дә үзе кебек. Алар күңелсезләнеп ятмыйлар. Ял итәргә дә тырышалар. Әле менә бөтенесе бергә кушылып, гитара да алганнар. Артур, язга кайтабыз, дип вәгъдә бирә. Бик көтәбез үзен, – ди Иркә. – Кызларым әтиләрен сорый. Уртанчысы елап та ала. «Нигә башкаларның әтиләре китмәгән?» – дип тә сорыйлар. Мин төрлечә җавап бирәм. «Әтиегез – герой», – дип әйтәм. Күңелләрен күтәрәм. «Әтиегез акча җибәргән, ял итәргә кушты», – дип тә каядыр алып барам. Сабыйларым ышана. Алар янында бу темага сөйләшмәскә тырышабыз. Мин дә Артурны бик көтәм. Алла боерса, бар да яхшы булачак.

«Янымнан җибәрмәс идем»



Казанда яшәүче Люция Сәлахиеваның ике кызы да әтиләрен дүрт күз белән көтә. Сабыйлар әтиләрен бик сагыналар. «Яңа ел бәйрәменә кайтачак, бәйрәмгә бергә барабыз», – дип көтәләр икән.

– Иремне 26 сентябрь көнне алып киттеләр. Казанда бер ай булды. Кызларым сагынган саен әтиләре янына йөрттем, – ди Люция. – 5 ноябрьдә ул хәрби операциядә катнаша башлады. Шуннан соң 10 көн бернинди хәбәр булмады. Борчылмаган кая ул! Әмма ирем мине, элемтә булмас, дип кисәтеп куйган иде. «Ватсап» төркемендә башкалар ирләре, улары, туганнары белән сөйләшүләрен язган, шуннан соң мин Алмазны эзли башладым. Дуслары аша исәнлеген белдем. Аннары тынычландым. Елап утырсам, бөтенләй башым китәсен аңладым.

Люция кешеләргә заказга камыр ризыклары пешерә. Әнә шул эш аны начар уйлардан арындыра да инде. Эшләгәндә иренең кайтуын, алга таба ничек яшәүләрен күз алдына китереп хыялана икән.

– Ирем киткәч, тормышка караш та үзгәрде, кешеләрне дә аера башладым. Якын итеп йөргән дуслар юкка чыкты, гомер хәлемне белмәгән кешеләр иңен куйды. Күпләр: «Акчасы күчтеме?» – дип кызыксына. Хәтта өйгә бурычка акча биреп торуымны сорап та килделәр. Аның акчасын тотарга кулым бармый. Ипотеканы да, кредитыбызны да үзем түләп барырга җыенам. Иремә күчкән акчаның «бәя»сен аңлыйм мин. Шуңа күрә дә ирем кайтканчы аларга кагылмыйм. Ничек тотасын үзе хәл итәр, – ди Люция. – Иремне бик көтәм. Гел изге теләктә йөрим. Догалар укыйм. Алмаз үзе дә, монда дога кирәк, диде. Көрешүләр насыйп булсын, дип көтәм. Әгәр ирем исән-сау кайтса, янымнан беркая да җибәрмәс идем. Ирләрен, улларын, туганнарын көтүчеләргә сабырлык телим. Көчле булыгыз. Ничек тә яшәргә кирәк. Мин, балаларым бар, дип юанам. Бар да яхшы булыр. Алла боерса, ирләребез җиңеп кайтачак!

Гөлгенә ШИҺАПОВА

ӘДӘБИЯТТАН ПӘЙГАМБӘР КӨТӘРГӘМЕ?

Ни өчен без һаман әдәбияттан аксакал сүзе көтәбез? Укырлык нәрсә калмады, саектык дигән сүзләрдә хаклык бармы? Замана авырлыкларыннан әдәбият коткарырга тиешме? Шушы һәм башка четерекле темаларга язучы Ландыш ӘБҮДӘРОВА белән әңгәмә кордык.

:: Ландыш, «әдәбиятта олпатлар калмады, ел китабы дип бәяләрлек шәп әсәрләр инде ничәнче ел күренми» дигән фикерне дә ишетергә туры килә. Бу фикер – хакмы, әллә нахакмы?

– Олпат дигәндә, без аксакал татар язучысын күз алдына китерәбезме? Мәсәлән, дөньяда рус әдәбиятын да гел сакаллы итеп күз аллыйлар икән.

Әгәр әдәбиятта аксакалга, ягъни шәхес фигурасына ихтыяҗ бар икән (ә без монда «демиург» төшенчәсенә килеп чыгабыз) бу мине уйландыра, хәтта сискәндерә. Димәк, халык үзенә яңа пәйгамбәр көтә. Ни өчен? Нишләтмәкче була ул аны? Минә яңа демиург, аксакал, Байрон язган герой, Пушкин, Лермонтов, Некрасов, Тукай, Рәмиевләр язган пәйгамбәр, ниһаять, килде, ди. Бүгенге контекстта ул супергерой буларак кузаллана. Ул халыкка «бу – иң дөрес юл, мин сезнең өчен уйладым, сезгә уйлап торасы юк, иярергә генә кирәк» дип, юл күрсәтергә, үзе артыннан иярергә тиеш буладыр инде. Шуннан соң без тагын берничә гасыр яки берничә дистә ел шул юлдан барырбыз дип өметләнәбездер... Ләкин, ни кызганыч, ул килмәячәк. Чөнки без аны каршы алырга әзер түгел. Без бит үзгәрмәдек, алай гына да түгел, безнең үзгәрергә әллә ни теләк тә юк. Шулай булгач, нигә соң иске пәйгамбәрләргә риза түгел? Шуңа күрә дә үзебезгә уйларга кала.

Мин хәзер шигырь язмыйм инде, шулай да моннан ун еллар элек язган бер шигыремдә болай дигән идем (рифма, ритмында ялгышамдыр, хәтерләп бетермим):

«Тук йөзендә ач күзләре генә
Китап киштәсеннән
Яңа динне эзли...
Һәм пәйгамбәрнең
кабат кайтуына өмет итә.
Гайсә үзе кирәклектән түгел,
Нибарысы аннан кызык көтә».

Менә милли күтәрелеш чоры: ул чын мәгънәсендәге тектоник үзгәрешләр вакыты булган. Халык үзе үзгәрергә әзер, шуңа күрә аның Тукайлары, Исхакыйлары, Әмирханнары, Бигиевләре – алар бик күп – булган. Халык аларны олпат итеп кабул иткән. Аларның һәркайсының үз урыны бар, берсенә дә беренче, икенче, дип тамга сугылмаган. Ә бүген кем генә килеп чыкмасын, хәтта аны Тукай үзе җитәкләп алып килсә дә, иң элек аның тырнак астын тикшерәчәкләр, аннан соң шкафындагы скелетларын алып, сөякләрен берәм-берәм юачаклар да кызыксыну бетүгә, «икенчесен бирегез» диячәкләр. Мондый шартларда язучының олпатлыгын, иҗатының әдәбияттагы урынын тану мөмкин түгел. Аның әсәрләренең дә «Ел китабы» дигән марафоннан төшеп калуы гаҗәп түгел. Гәрчә бүген теләсә кайсы һәвәскәр язучы, журналист, бер әсәр авторының китабы ел китабы булып таныла ала.

Шуңа күрә язучыларга карата әйтелгән бу сүзләрне нахак дип саныйм, чөнки бүгенге язучы ул иң элек олы әдәбиятка хезмәт итә, тулаем әдәбият исә – халыкка. Шәхесләр күренмәү аерым бер халыкка гына хас түгел, ул – тулаем чор кытлыгы.

:: Өметләре акланмаган укучыны (әдәбият сөючене) очратканың бармы?

– Әдәбияттан нәрсә өмет итүенә карап инде... Калын журналда дүртенче елымны эшлим, төрлесен ишетергә туры килә. «Укырлык әйбер юк» дигәнне, гадәттә, гомумән укымый торган кеше әйтә. Шушы җөмләне тәгәлләштерүен сорасаң, үзенең нәрсә теләгәнен белмәве ачыклана.

:: Әдәбиятта хәзер төп тема нинди? Бәлки шул төп тема укучыны ялыктыра башлагандыр?

– Әдәбиятта гына түгел, тулаем сәнгатьтә соңгы елларда Икенче Бөтендөнья сугышы темасы актуальләшеп китүгә игътибар иткән идем. Холокост, тыл фаҗигаләре, сугыштагы батырлыклар, мәхәббәт һәм нәфрәт – боларның барысын да яңадан күтәреп, коллектив аң илэгенә сала башладылар. Бездә генә түгел, бөтен дөньяда шундый бер дулкын булып алды. Сугыш турында беркайчан да сугышны күрмәгән буын сөйли башлады. Җепшеклек чорыннан тамырланып килгән ГУЛАГ темасы ешайды. Бу әсәрләрнең максаты бер – «1945 елда коточкыч зур бәһа түләп яуланган Җиңү ни өчен системаның яңаруына китермәде, хәтта ки тәмугтан җиңүче булып кайтканнарны да якларлык булып үзгәрмәде?» дигән сорауга җавап эзләү. Бу теманың яңаруына дәүләт дәрәҗәсендә Бөек Җиңүне мемориальләштерү сәясәте дә сәбәп булгандыр. Ләкин артка карап, алга бару чыннан да арыта, өстәвенә алга карап, ничек яшәргә белмәгән чак.

:: Без, театр заманнан алда барырга тиеш, дип әйтергә яратабыз, ә әдәбият алда булырга тиешме?

– Без хәзер технологик яктан шундый шартларда: хәзерге заманның һәр язучысы Кол Галидән башлап, шушы көнгә кадәрге классиклар белән көндәш булырга мәҗбүр. Укучы, китап кибетенә керсә дә, интернеттан да таныш түгел авторның китабына үрелгәнче, классикага өстенлек бирә. Беренчедән, кул сузымында гына, икенчедән, һәрвакыт актуаль, һәрвакыт алда тора.

> Татар әдәбияты, милләтнең маягы буларак, болай да алдан бара, чөнки без – әдәбият сөючән халык, әдәбебез, уйлау-фикерләү рәвешебез китапка нык бәйләнгән. Безнең өчен китап – белем чыганагы, мәгърифәтле булу – милләтнең исәнлегенең төп шарты.

:: Заманча әдәбият, чыннан да, заман белән бергә атлыймы, хәзерге вазгыять, борчу, проблемалар, фаҗигаләрне язучылар бармы?

– Заманга иң сизгер әдәбият ул – кагыйдә буларак, шигърият. Элек калын журналларда да, газеталарда да «Актуаль шигърият» дигән рубрика була иде. Хәзер актуаль шигърият белән социаль челтәрләрдә танышып була. Шулай ук публицистика (ә публицистика ул – әдәби жанр) хәзерге вазгыятьне чагылдыра. Нон-фикшн жанрындагы әсәрләр күбәя. Хәтта ки прозада, олы жанрда да замана фаҗигаләрен язучылар бар. Марат абый Кәбировның «Тик син генә...» повесте, мәсәлән, 175 нче мәктәптә булган фаҗигагә альтернатив тарих буларак укыла. Глобаль проблема буларак, ялгызлык турында язучылар бар. Бу тема бигрәк тә хатын-кызлар иҗатында күтәрелә.

> Әмма бу җәһәттән миндә бер кыюсыз гына теләк бөреләнеп килә. Укучы буларак, минем фаҗигаләр, үлем, бетү турында гына укыйсым килми. Минем яшәү турында, яшәргә теләк уята торган әсәрләрне күбрәк укыйсым килә. Әйдәгез, игелек турында, матурлык турында күбрәк язык.

:: Бәлки, үлем темасы безгә Көнбатыштан килеп кергәндер? Күп язучыларда Рей Бредбери, Эркюль Пуарога ияреп язу сизелә бит.

– Кайбер идеяләр, галәмнән киләме икән инде ул, коллектив аң белән шуңа барып җитәбезме, үзеннән-үзе тегендә дә, монда да туарга мөмкин. Кеше, антенна кебек, һавадан идеяне тотып ала. Аннан соң бит күп автор, бәлки, укыган әсәрдән идея алам дип уйламыйдыр да. Үзеннән-үзе шулай килеп чыгарга мөмкин. Хәтта ки ниндидер бер идеяне алган хәлдә дә, ул бит аны милли эчтәлек белән баета. Сүз дә юк, җиңел иҗат. Шул ук вакытта Шәрык әдәбиятын алыйк. Каймалы композиция дә, тартмалы композиция дә бар. Аларга нигезләнеп, миллион әсәр иҗат ителгән. Үз вакытында Европа әдәбияты сюжет идеяләрен Шәрык әдәбиятыннан алган, хәзер, киресенчә, без Европадан алабыз. Озакламый тагын барысы да киресенчә булачак.

:: Ә иң өйрәнелмәгән чор кайсы?

– Татар әдәбиятының 1960–1980 нче еллар прозасын бөртекләп өйрәнәсе иде. Дөрес, аны өйрәнелмәгән дип булмый, хәтта әйбәт өйрәнелгән ул. Аерым язучыларның иҗатына шактый хезмәтләр багышланган. Татар әдәбиятын гыйльми дәрәҗәдә өйрәнә торган галимнәребез күп безнең, һәм аларның фидакарьлеге сокланырлык. Татар телен, әдәбиятын өйрәнү сәгатьләре көннән-көн кимегәндә, менә бетә, менә бетә дип, өстә балта эленеп торганда, әдәбият галимнәре фәнни эзләнүләрен, тикшеренүләрен дәвам иттерәләр. Галим кеше тыйнак була, ул үз исемен белсеннәр өчен хезмәт итми, ул әдәбиятны белсеннәр дип тырыша, шуңа да нинди генә шартларда фәнгә тугрылыгын саклый. ТӘһСИ, КФУның Татар әдәбияты кафедрасы галимнәре – әдәбиятыбызны alma-mater дәрәҗәсендәге гыйлем белән тәэмин итеп торучылар, бәлки, бүген аларның исемнәре танылмый да торгандыр, әмма аларның хезмәте бик зур.

Узган гасырның 60–80 нче елларына килгәндә, татар әдәбиятына гына хас акъәби образын биргән чор бит ул (мин монда Әмирхан ага Еникинең «Әйтелмәгән васыять» повестен генә күз уңында тотмыйм). Уйда, нияттә, сүздә, гамәлдә чисталык өлгесе булган акъәби образын тудырганчы, бу милли әдәбият нинди баскычлар аша эволюцион юл үткән дә туксанынчы елларга нинди багаж белән килеп кергән? Ә бит туксанынчы еллардагы милли күтәрелешне идеологик яктан формалаштыруда нәкъ шушы чорның өлеше зур булган.

:: Менә син заманча, оригиналь әсәрләр белән әдәбиятка килеп кердең, әлбәттә, тәнкыйть тә күп булгандыр. Бәлки, татар әдәбиятын әнә шул тәнкыйть авызлыклап торадыр, кузгалырга ирек бирмидер?

– Юк-юк, тәнкыйтьсез булмый! Тәнкыйтьсез әдәбият – тозсыз аш кебек. Билгеле, әдәбият сөюче укучыга. Вакыт уздыру өчен генә китап укучыга сюжет кирәк, мин андыйлар турында әйтмим. Әдәбият белән кызыксынучы укучы тәнкыйтьне эзләп ала ул.

Тик шунысы бар: тәнкыйть мәкаләсе язу – әсәр турында әсәр иҗат итү ул, тик бөтен кеше дә иҗатчы түгел. Кайвакыт әсәрне аңламаган (кая аңламаган, юньләп укымаган) килеш тәнкыйтьли башлыйлар.

:: Әгәр татар әдәбиятын чит ил әдәбияты белән чагыштырабыз икән, без кайсы яктан калышабыз һәм нинди өстенлегебез бар?

– Безнең әдәбият «әдәп» сүзеннән ераклашмавы белән өстенлекле. Кайбер жанрларда, темаларда үзебезне чик-

Блиц-сораштыру

– Талантка нинди биш төп сыйфат хас?
1. Тыштан таркау булып күренсә дә, эчке дөньясында космос.
2. Эгоцентризм. Аны үзеннән башка беркем кызыксындырмый.
3. Хакыйкатькә ихтыяҗ.
4. Ихласлык.
5. Вакытка туры килә алмау.
– Танылу сере нәрсәдә?
– Аның технологияләре бар. Ул сер түгел.
– Үзең турында китап язсаң, ул ничек аталыр иде?
– Исемен белмим, юмор һәм сарказмга бай булыр иде. Курт Воннегут: «Галим нәрсә өстендә эшләсә дә, барыбер корал килеп чыга», – дигән кебек, язучы нәрсә турында язса да, үзе турында килеп чыга.

либез. Чит ил әдәбиятыннан китап базарының формалашмавы белән калышабыз.

Мин үзебезнең язучыларны кызганам. Безнең шундый оста язучыларыбыз бар: аларның язучылыгы каләм очыннан тамып тора. Бер кешене ике-өч сәгать сөйләтеп тә гаҗәеп матур повесть тудыра алалар. Әмма алар ике-өч эштә эшләргә мәҗбүр, аларның егәрен көн дә бертөрлелек белән сугарылган «эш» суырган, багаж беткән... Дөнья көткәннән калган вакытта языштырып, Аллаһтан бирелгән талант ихтыяҗын канәгатьләндерәләр. Ә аларга тема биреп, архивларга кертеп утыртып, әсәр яздыртсаң?

> Ләкин шунысы бар: мәдәнияткә бәя халыкның тулай капиталына карап куела. Америка әдәбияты иң яшь әдәбиятлардан санала, әмма Америка язучылары танылуга кытлык кичерми. Поп-арт короле рәссам Энди Уорхолл, мәсәлән, бездә туган булса...

:: Беренче әсәрләрең белән хәзергеләре арасында 3 төп аерманы әйт әле.
– Беренчеләре феминистик рухта иде. Хәер, хәзер дә. Ул вакытта пафоста иде, хәзер онтологик проблема дәрәҗәсендә бугай. Икенчесе, тормышның төсләре – детальләрдә дә. Өченчедән, миллилегем артты бугай. Хәер, юк. Алай дисәң, ничек кенә кикрикләнергә маташсак та, без бит элгәреләребезнең җилкәсендә басып торабыз. Киләчәктә безгә таяначаклар.

:: Псевдоним белән язып карыйсы килмиме? Мәсәлән, ир кеше булып. Бәлки, алай җиңелрәктер?
– «Хатын-кыз язучыларга карата татар мохитендә караш үзгәрмәдеме, син әле дә «феминистка»мы?» – дип сорамакчы буласың инде. Бүген псевдоним белән язу ихтыяҗын күрмим, эксперимент өчен язып карасам гына. Язучылык хезмәтемдә максатым – игътибарны үз фигурама юнәлтү түгел. Укучы автор белән түгел, әсәр белән кызыксынсын. Хәзер инде фамилиямне азмы-күпме беләләр. Шуңа да матбугатта яки китап булып, әсәрләрем чыга икән, ул әдәбиятка яңа кеше килде дип түгел, яңа әсәр чыкты дип кабул ителәчәк.

Хатын-кызлар мәсьәләсенә килгәндә, мин үземне Муса Бигиев күрсәткән урында хис итәм. («Западный подход отражает пылкую страсть и наслаждение, а восточный является следствием уважения и благородства. Оба этих отношения прекрасны, но восточное более почтительно. Здесь благородная женщина по степени питаемого к ней уважения вознесена на уровень царствующей особы», – дип яза ул «Женщина в свете аятов Благородного Корана» хезмәтендә).

:: Һәм соңгысы. Имән саплы көрәкләрне саклаучы нәселләр калдымы икән әле?
– Калды. Алар бик күп. Без аларны даими рәвештә күреп торабыз. Мин бу бик йөз ел буе исән калу режимында яшәгән татар халкында яшәү генының ныклы булуына сокланам, шаккатам! Ел саен диярлек безнең татар кешеләре бөтен дөньяны таң калдыра! Бигрәк тә кызлар! Соңгы елларда гына Алинә Заһитова, Камилә Вәлиева, Аида Гарифуллина, Сәйдә Мөхәммәтҗанова – бу кызларның камиллеген бөтен дөнья әйтсә сүзен әйтергә онытып, авызларын ачып, таң калып карап тора. «Умарта» әсәрен мин әнә шуларны күздә тотып язган идем. Ләкин, ни кызганыч, саклый алмыйбыз без аларны... Безнең Дамир Йосыпов кебек ир-егетләребез бар. Һәр авылда, һәр урамда бар андый нәсел, без аларны үзебез дә беләбез, үзебезне аларга карап тәрбиялибез. Андый нәселләр – милләтнең элитасы, алар безнең милли, рухи кодларны саклый.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

ФӘНИС ЯРУЛЛИН

СӘЕР КУНАК

(ХИКӘЯ)

Бал суырткан вакытта умарталыкка кунаклар ешаюына Мөдәррис абзый күнеккән иде инде. Шуңа күрә колхоз рәисенә ияреп килгән ят кешене күргәч, ул гаҗәпләнмәде: «Бал исе борынына кергәндер», – дип ризасызлык белән уйлап кына куйды. Рәис: «Менә бу безнең атаклы умартачыбыз Мөдәррис абзый була, районда аның кадәр бал алучы юк», – дип, алып килгән кунагына умартачыны мактый башлады. Бу мактаудан Мөдәррис абзыйның чырае тагын да караңгыланыбрак китте. Чөнки белә: председатель аны мактадымы, димәк, кунакның аппетиты зурдан булачак. Димәк, ул баллы чәй эчеп кенә китмәячәк.

– Йә, йә, – диде председатель, Мөдәррис абзыйның иңеннән кагып, – шырпыларыңны кабартырга ашыкма. Әхмәт Дилүсович, – ул кунагына елмаеп карап куйды, – синең умарталыгыңны күтәреп китәргә дип килмәде. Аңа бераз саф һавада йөреп ял итәргә кирәк. Башын җилләтергә, уйларыннан арынырга...

«Башын казык башына элеп җилләтсен иде, – дип уйлап куйды Мөдәррис абзый. – Беләм мин сезне: башыгызны бушатып, савытларыгызны тутырып китәргә яратасыз. Машинагызда, мөгаен, банкаларыгыз бардыр әле, фляга ук булмаса».

Председатель тагын бер мәртәбә умартачының җилкәсеннән какты:

– Келәтеңнең берәр почмагында кадерле кунакка урын табарсың инде, – дип китеп барды.

– Мондый матур җирдә тышта куыш корып та ятарга мөмкин, – диде кунак.

Әйе, умарталык табигатьнең бик гүзәл җиренә урнашкан. Әнә умарталар торган аланны җилләрдән ышыклап утыручы, сабый кулыдай йомшак яфраклы юкәләр. Әнә тезелешеп мәктәпкә баручы үсмер кызлар төсле ак каеннар, әнә кышын да катмый торган зәңгәр чишмә.

Мөдәррис абзый күптән искәреп килә: матурлыкны кешеләр тизрәк яулап алырга, үзенеке итәргә телиләр. Бигрәк тә кулларында көч һәм власть булган бәндәләр нык тырыша. Умарталыкның иң гөрләгән чагында зәңгәр чишмә буендагы каенлыкка бер вагон-йорт китереп куйдылар. Кышның салкын көннәрендә ул вагон-йортның мичен Мөдәррис абзый ягып торырга тиеш булды. Кайчагында һич көтмәгәндә-уйламаганда урман аланы өстендә вертолет пытырдый башлый. Иң элек ул, чебеш эзләгән тилгәндәй, әйләнә-тирәне бер урый, аннары карлар очырып төшеп утыра. Аның эченнән мылтыклы кешеләр чыга. Мөдәррис абзый белә: болар – олы түрәләр. Алар килдеме – урмандагы тынлык иң ерак почмакларга кереп поса. Ә төлкедер, куяндыр ише мәхлук җаннар ерак почмакларга качып та котыла алмый: ядрәнең тәпие озын, әллә кая качсаң да, куып тота.

Ә бераздан Мөдәррис абзый ягып җылыткан вагон-өйдә шау-шулы мәҗлес башлана. Ниндидер, Мөдәррис абзыйның төшенә дә кермәгән ят әчемлекләр табынга менеп кунаклый. Ризыклар тезелә. Берәрсе видеомагнитофонны кабызып җибәрә. Экранда шәрә кызлар пәйда була.

Ашап-эчеп, кәеф-сафа корганнан соң түрәләр вертолетларына төяләп кайтып китәләр. Күп вакыт үзләре аткан куян-бүреләрне дә вагон-йортта ташлап калдыралар.

– Алып китәрлек булмагач, нигә җан кыеп йөриләрдер, – дип сукрана Мөдәррис абзый.

– Аларга кәҗәсе түгел, мәзәге кыйммәт, – ди колхоз рәисе. – Куян кирәклектән йөриләр дип беләсеңме әллә син аларны.

Мөдәррис абзыйга бу тормыш мәңге шулай үзгәрешсез барыр, түрәләр сунарга вертолет белән һәрвакыт килеп-китеп йөрерләр кебек тоела иде. Әмма кинәт кенә дөньялар болганды. Көннәрдән бер көнне теге вагон-йорт та үзеннән-үзе янып юкка чыкты. Шуннан бирле умартачылыкка килүче кунаклар сирәгәйде. Килсәләр дә, район тирәсеннән генә киләләр иде.

Ә бу кунак район кешесенә охшамаган. Үзе бик йомык. Күп сөйләшми. Мөдәррис абзыйның:

– Бал белән чәй эчмисезме? – дигән соравына:

– Балга минем – аллергия. Бер кашык бал капсам да, бөтен тәнем кызарып чыга, – дип табынга утырмады.

– Алай, алай, – диде Мөдәррис абзый һәм эченнән: «Әгәр кодрәтемнән килсә, бөтен начальствога шул аллергия дигән нәмәстәкәйне бирер идем. Колхоз балын күбрәк капкан саен ныграк кызарсыннар иде».

– Ә сез үз эшегезне карагыз, – диде Әхмәт Дилүсович, умартачының сабырсызланып китәргә ашыгуын, ләкин үзен ташлап китәргә батырчылыгы гына җитми торуын күреп. – Мин бераз урманнарны әйләнеп киләм. Гомумән, мине юк дип уйлагыз.

– Ярый алайса, – диде Мөдәррис абзый җиңел сулап. – Бәлки, чынлап та бу бәндә башын җилләтергә апчыккандыр. Кыяфәтенә караганда түрәгә охшаган. Әмма үзен тотышы, тыйнаклыгы, сабырлыгы ничектер сәеррәк иде.

Һәм Мөдәррис абзый кунагын сиздермичә күзәтә башлады. Кем бу? Нишләп йөри? Чакырып китермәсәң, ашарга-эчәргә дә килми. Берәр җиргә барып утыра да уйга чума. Нәрсә турында уйлана, җанын нәрсә талкый – һич аңлармын димә. Инде умарталыкта яши башлавына атнага якын вакыт үтте. Ә Мөдәррис абзый аның исеменнән башка берни белми әле. Кайсы көнне ул урманга мылтыгын күтәреп чыгып китә, ләкин берни дә атмый. Мөдәррис абзый аның бидоны, банкалары юклыгын күргәч, ничектер, җиңел сулап куйды. Бал ашамавы чындыр, күрәсең. Әнә бит чәй эчкәндә хәтта балның савытын да читкәрәк этеп куя. Исе борынга керсә, төчкертә башлый, ди. Мөдәррис абзый гаҗәпләнгәннән-гаҗәпләнә: бал ашарга яратмагач, ни өчен соң аны председатель монда китереп куйды икән? Эчендә берәр хәсрәте бардыр. Мөгаен, шулайдыр. Ә бәлки... Ә бәлки әле ул берәр олы урыннан төшерелгән түрәдер. Әйе, әйе, нәкъ шулай. Бөтен кыяфәте шул турыда сөйли ләбаса. Хәзер бит түрәләр очып кына тора.

Мөдәррис абзый үзенең бу ачышына сөенеп куйды һәм кунагын тагын да ныграк күзәтә башлады. Беренчедән, дип нәтиҗә чыгарды ул күңеленнән, Әхмәт Дилүсович дигәнебез кеше сүзен тыңлый белми, тыңлаган төсле итеп баш кагып утыра гына. Мөдәррис абзый кайчакларда юри сүзен иң кызык җирдә өзә дә, бераздан: «Кайда туктаган идем әле мин?» – дип сорап куя һәм аңгәмәдәшенең берни тыңламаганына төшенә. Димәк, боерырга гына өйрәнгән. Кешене тыңларга өйрәнеп җитмәгән. Икенчедән, өстәл янында утырган чакларында сәер кунак үзе дә сизмәстән кулы белән капшанып нидер эзләнә башлый. Башта Мөдәррис абзый аның бу гадәтен нәрсәгә юрарга белми аптыраган иде, уйлана торгач, анысына да җавап тапты: түрәләр бит гадәттә үзләренең секретарьларын кнопкага басып кына чакыралар. Монда да ул, онытылып китеп, кемнедер чакырырга, кемгәдер боерык бирергә омтылып куйгалый бугай.

Ә инде Әхмәт Дилүсовичның урыныннан төшерелгән кеше икәнлеген аңлар өчен әллә ни зирәклек тә кирәкми иде. Әнә ич, председатель китерде дә онытты үзен. Эшли торган башлыкларны онытмыйлар алар. Аларга карата ай-һай сизгер булалар. Мөдәррис абзый, кунагының кем икәнлегенә төшенгәч, ничектер тынычланып калды. Әхмәт Дилүсовичны ул чын-чынлап кызгана ук башлады. Ул яраткан ризыкларны пешерергә тырышты. Кунак бәрәңгене шашлык кебек итеп турамы-турамы белән тимерчыбыкка тезеп учакта кыздырып ашарга ярата иде. Мөдәррис абзыйның үзенә дә бу аш ошап киткәнлектән, кич житә башладымы, чишмә буенда учак ягып, бәрәңге шашлыгы әзерләргә тотына ул. Әхмәт Дилүсович, коры чыбык-чабыклар җыя. Менә бер мәлне бәрәңге әрчелеп бетә, учак чырт-чырт янарга тотына. Картның нәкъ шушы вакытта урман аланында сәер кунагы белән бәрәңге пешереп ятканлыгын белеп алган Хәерниса түти яңа гына сепараттан чыккан каймагын әзерләп куя. Учакта кыздырылган бәрәңгене каймакка мана-мана сүзсез генә ашау башлана.

Ул арада инде ут өстендә кура җиләге яфраклары, мәтрүшкә салган чәй кайнап чыга. Маңгайдагы тирләрне тастымал почмагы белән сөртә-сөртә озаклап чәй эчелә. Мондый вакытларда кунакның да кәефе күтәрелеп китә. Ул Мөдәррис абзыйдан фронтта йөргән чаклары турында сораштыра башлый. Ә фронтта булган кешенең ашарына бирмәсәң бирмә – бары тик сорашсын, бары тик игътибар белән тыңла гына. Мөдәррис абзыйның сүзгә әллә ни маһирлыгы юк-югын, әмма сугыш вакыйгаларын сөйли башласа, теләсә кемне авызына карата ала ул.

Дәвамы бар >

БЕЗДӘН СЕЗГӘ – 3 БҮЛӘК

1 **ЯЗЫЛ!**
2023 елның беренче яртыеллыгына **«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»** газетасына языл

2 **КВИТАНЦИЯ КҮЧЕРМӘСЕН БЕЗГӘ ҖИБӘР!**

89179270040
info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт.

3 **БҮЛӘККӘ**
1. Суыткыч.
2. Микродулкынлы мич.
3. Мультиварка.

П2435
жомга саны
512 сум 70 тиен

П2409
атнага дүрт тапкыр чыга
1143 сум 96 тиен

Акция 2022 елның 26 октябреннән башлап 2023 елның 20 гыйнварына кадәр дәвам итә.
Акцияне оештыручы ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
Тулырак: vatantat.ru

16+

реклама

Әз-мәз мәзәк

– Сез инде никадәр вакыт ашамыйча яшисез, Тибет монахларыннан дәресләр алдыгызмы әллә?
– Юк, ипотека алдым.

* * *

– Эпиляция авырттырамы ул?
– Кайда эшләттерүеңә карап.
– Апаста.
– Авырттыра.

* * *

– Сез безнең сырхауханәдә инде бер булган идегез бугай, фамилиягезне әйтегез әле.
– Садриев.
– Гайморит?
– Фәрит.

* * *

Инде бөтенләй дә чара калмагач, адәм баласы, гадәттә, акыл белән эш итә башлый.

* * *

– Реформалар кирәк безгә...
– Марш эшләргә, ялкаулар!!!

* * *

Бар шундый эстрада йолдызлары: алар гитарага автограф куйгач, бу гитараның бәясе арзанаеп та китәргә мөмкин.

СОЦЧЕЛТӘРЛӘР СҮЗЛЕГЕ

- **Аккаунт** – кешенең социаль челтәрдәге бите.
- **Контент** – эчтәлекле текст, фото, видео яки башка мәгълүмат.
- **Пост** – кеше элеп куйган контент.
- **Репост** – башка кеше постын үзеңә күчереп элу, цитаталау.
- **Лайк** – постка куелган хуплау билгесе.
- **Мэм** – «канатлы» булып киткән контент.
- **Коммент** – башка кеше тарафыннан постка карата язылган фикер.
- **Хейт** – авторга карата начар ният белән язылган коммент.
- **Троллинг** – авторны котырту нияте белән язылган коммент.
- **Чат** – кешеләрнең онлайн аралашу урыны.
- **Онлайн** – интернеттагы тормыш, интернеттагы халәт.
- **Офлайн** – интернеттан тыш гадәти тормыш, күзгә-күз аралашу.



Сканворд җаваплары

Горизонталь: тилебәрән, чара, Мәйсәрә, багана, ро, ел, Алинә, Би, умач, ук, бире, Панамера, иннек, Ра, смузи, ки, Картуф, яулык, әл, ял, бу, балта, Ив, Ася, Төмәнәк, каноэ, иза, сакура, Шәвәли.

Вертикаль: ияк, аким, Баламишкин, арба, Саз, Ульяна, таба, пестә, Акмулла, энә, Лима, уф, Өнсә, байрак, ия, ал, Сол, Убер, Әлки, Илмира, әкрен, ара, кыя, Әбри, әләкче, чикләвек.

Беләсең килсә...

1 Иволга кошы татарча ничек була?
а) шәүләгән;
б) боҗыр;
в) шонкар.

2 Милләттәшебез академик Роальд Сәгъдиев АКШ Президенты оныгына өйләнгән. Сүз кайсы Илбашы турында?
а) Дуайт Эйзенхауэр;
б) Франклин Рузвельт;
в) Джон Кеннеди.

3 Кызыл проспект, әйтерсең линейка белән сызылган. Дөньяда бу иң озын туры урам санала. Аның озынлыгы – 7 чакрым. Ул кайсы шәһәрдә урнашкан?
а) Астана;
б) Новосибирск;
в) Екатеринбург.

4 Фидель Кастро 1963 елда Мәскәүгә килгәч, ничек йөргән?
а) бер бармакта ике балдак белән;
б) бер кесәдә ике пистолет белән;
в) бер кулда ике сәгать белән.

Җаваплар: 1. а); 2. а); 3. б); 4. в).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 15337 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 374

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+